| Сәламәтлек саклау | 395 | 09 | 00 | | | 26 144 879,7 |
| Амбулатория ярдәме | 395 | 09 | 02 | | | 700 737,6 |
| Социаль ярдәм | 395 | 09 | 02 | 505 00 00 | | 121 789,6 |
| Стационар учреждениеләрдәге ятим балаларга һәм авыр тормыш хәлендә калган балаларга диспансеризация үткәрү | 395 | 09 | 02 | 505 21 01 | | 5 513,6 |
| Социаль түләүләр | 395 | 09 | 02 | 505 21 01 | 005 | 5 513,6 |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Эшләүче гражданнарга өстәмә диспансеризация үткәрү | 395 | 09 | 02 | 505 24 00 | | 116 276,0 |
| Социаль түләүләр | 395 | 09 | 02 | 505 24 00 | 005 | 116 276,0 |
| Кире кайтарылмый һәм түләттерелми торган башка акчалар | 395 | 09 | 02 | 520 00 00 | | 578 948,0 |
| Участок табиб-терапевтлары, участок табиб-педиатрлары, гомуми практика табиблары (гаилә табиблары), участок табиб-терапевтларының, участок табиб-педиатрларының участок шәфкать туташлары, гомуми практика табибларының (гаилә табибларының) шәфкать туташлары тарафыннан өстәмә медицина ярдәмен күрсәтүне финанс белән тәэмин итү | 395 | 09 | 02 | 520 21 00 | | 578 948,0 |
| Социаль түләүләр | 395 | 09 | 02 | 520 21 00 | 005 | 578 948,0 |
| Ашыгыч медицина ярдәме | 395 | 09 | 04 | | | 1 264 605,7 |
| Сәламәтлек саклау учреждениеләрен мәҗбүри медицина иминияте системасы аша күбесенчә бер каналлы финанслауны гамәлгә ашыру | 395 | 09 | 04 | 505 33 00 | | 1 264 605,7 |
| Социаль түләүләр | 395 | 09 | 04 | 505 33 00 | 005 | 1 264 605,7 |
| Шифаханә-савыктыру ярдәме | 395 | 09 | 05 | | | 118 438,3 |
| Сәламәтлек саклау учреждениеләрен мәҗбүри медицина иминияте системасы аша күбесенчә бер каналлы финанслауны гамәлгә ашыру | 395 | 09 | 05 | 505 33 00 | | 118 438,3 |
| Социаль түләүләр | 395 | 09 | 05 | 505 33 00 | 005 | 118 438,3 |
| Сәламәтлек саклау өлкәсендәге башка мәсьәләләр | 395 | 09 | 09 | | | 24 061 098,1 |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Россия Федерациясе субъектларының сәламәтлек саклау өлкәсен модернизацияләү буенча региональ программаларны һәм дәүләт учреждениеләрен модернизацияләү чараларын гамәлгә ашыру | 395 | 09 | 09 | 096 00 00 | | 1 306 052,2 |
| Россия Федерациясе субъектларының сәламәтлек саклау өлкәсен модернизацияләү программаларын медицина ярдәме стандартларын кертү, амбулатор медицина ярдәменнән һәркем файдалана алуны арттыру өлешендә гамәлгә ашыру | 395 | 09 | 09 | 096 03 00 | | 1 306 052,2 |
| Башка чыгымнар | 395 | 09 | 09 | 096 03 00 | 013 | 1 306 052,2 |
| Медицина ярдәменең югары технологияле төрләре | 395 | 09 | 09 | 470 02 00 | | 1 830 470,4 |
| Югары технологияле медицина ярдәме күрсәтү | 395 | 09 | 09 | 470 02 02 | | 1 830 470,4 |
| Социаль түләүләр | 395 | 09 | 09 | 470 02 02 | 005 | 1 830 470,4 |
| «Россия Федерациясендә мәҗбүри медицина иминияте турында» 2010 елның 29 ноябрендәге 326-ФЗ номерлы Федераль закон | 395 | 09 | 09 | 505 17 00 | | 18 441 368,8 |
| Мәҗбүри медицина иминиятенең база программасы кысаларында территориаль мәҗбүри медицина иминияте программасын үтәү | 395 | 09 | 09 | 505 17 02 | | 18 382 548,6 |
| Социаль түләүләр | 395 | 09 | 09 | 505 17 02 | 005 | 18 206 548,6 |
| Башка чыгымнар | 395 | 09 | 09 | 505 17 02 | 013 | 176 000,0 |
| Бер каналлы финанслау кысаларында территориаль мәҗбүри медицина иминияте программасы чараларын гамәлгә ашыру | 395 | 09 | 09 | 505 17 06 | | 58 820,2 |
| Социаль түләүләр | 395 | 09 | 09 | 505 17 06 | 005 | 58 820,2 |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Сәламәтлек саклау учреждениеләрен мәҗбүри медицина иминияте системасы аша күбесенчә бер каналлы финанслауны тормышка ашыру | 395 | 09 | 09 | 505 33 00 | | 2 483 206,7 |
| Социаль түләүләр | 395 | 09 | 09 | 505 33 00 | 005 | 2 483 206,7 |
| Социаль сәясәт | 395 | 10 | 00 | | | 82 800,0 |
| Халыкны социаль тәэмин итү | 395 | 10 | 03 | | | 82 800,0 |
| Социаль ярдәм | 395 | 10 | 03 | 505 00 00 | | 82 800,0 |
| Хезмәт ветераннарына һәм тыл хезмәтчәннәренә социаль ярдәм чараларын тәэмин итү | 395 | 10 | 03 | 505 55 20 | | 81 419,5 |
| Хезмәт ветераннарына социаль ярдәм чараларын тәэмин итү | 395 | 10 | 03 | 505 55 21 | | 80 920,5 |
| Социаль түләүләр | 395 | 10 | 03 | 505 55 21 | 005 | 80 920,5 |
| Тыл хезмәтчәннәренә социаль ярдәм чараларын тәэмин итү | 395 | 10 | 03 | 505 55 22 | | 499,0 |
| Социаль түләүләр | 395 | 10 | 03 | 505 55 22 | 005 | 499,0 |
| Реабилитацияләнгән затларга һәм сәяси репрессияләрдән зыян күргән дип танылган затларга социаль ярдәм чараларын тәэмин итү | 395 | 10 | 03 | 505 55 32 | | 806,0 |
| Социаль түләүләр | 395 | 10 | 03 | 505 55 32 | 005 | 806,0 |
| Социаль ярдәмнең башка төрләрен күрсәтү | 395 | 10 | 03 | 505 85 01 | | 574,5 |
| Социаль түләүләр | 395 | 10 | 03 | 505 85 01 | 005 | 574,5 |
| Россия Федерациясе субъектлары һәм муниципаль берәмлекләр бюджетларына гомуми характердагы бюджетара трансфертлар | 395 | 14 | 00 | | | 4 345 226,8 |
| Гомуми характердагы бүтән бюджетара трансфертлар | 395 | 14 | 03 | | | 4 345 226,8 |

| | | | | | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| Россия Федерациясе субъектларының сәламәтлек саклау өлкәсен модернизацияләү буенча региональ программаларны һәм дәүләт учреждениеләрен модернизацияләү чараларын гамәлгә ашыру | 395 | 14 | 03 | 096 00 00 | | 3 960 067,0 |
| Россия Федерациясе субъектларының сәламәтлек саклау өлкәсен модернизацияләү программаларын медицина учреждениеләренең матди-техник базасын ныгыту өлешендә гамәлгә ашыру | 395 | 14 | 03 | 096 01 00 | | 3 960 067,0 |
| Башка чыгымнар | 395 | 14 | 03 | 096 01 00 | 013 | 3 960 067,0 |
| Бердәй үрнәктәге мәҗбүри медицина иминияте полисларына күчү максатларында Россия Федерациясе субъектларының сәламәтлек саклау өлкәсен модернизацияләү программаларын сәламәтлек саклауга заманча мәгълүмат системаларын кертү өлешендә гамәлгә ашыру | 395 | 14 | 03 | 096 02 00 | | 200 159,8 |
| Башка чыгымнар | 395 | 14 | 03 | 096 02 00 | 013 | 200 159,8 |
| «Россия Федерациясендә мәҗбүри медицина иминияте турында» 2010 елның 29 ноябрендәге 326-ФЗ номерлы Федераль закон | 395 | 14 | 03 | 505 17 00 | | 185 000,0 |
| Медицина хезмәткәрләренә бер тапкыр бирелә торган компенсация түләүләре | 395 | 14 | 03 | 505 17 03 | | 185 000,0 |
| Башка чыгымнар | 395 | 14 | 03 | 505 17 03 | 013 | 185 000,0 |
| Барлык чыгымнар | 395 | | | | | 30 727 603,0»; |

8) 8 нче кушымта исемен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2013 һәм 2014 еллар план чорына Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджетының бюджет ассигнованиеләрен бюджетлар чыгымнары классификациясенең бүлекләре, бүлекчәләре, максатчан статьялары һәм чыгымнар төрләре буенча бүлү».

**2 статья**

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

2. Әлеге Законның 1 статьясындагы 4 пунктның гамәли көче 2012 елның 1 декабреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә кагыла.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 елның 25 декабре
№ 90-ТРЗ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 1883. Татарстан Республикасында гражданнарның җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар уздыру хокукларын гамәлгә ашыру шартларын тәэмин итү турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2012 елның 24 декабрендә
кабул ителде

1 статья. **Әлеге Законның җайга салу предметы**

Әлеге Закон «Җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар турында» 2004 елның 19 июнендәге 54-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – Федераль закон) нигезендә Россия Федерациясе гражданнарының Татарстан Республикасында җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар (алга таба – гавами чаралар) уздыруда катнашуга конституциячел хокукларын гамәлгә ашыру шартларын тәэмин итүгә юнәлдерелә.

2 статья. **Әлеге Законда кулланыла торган төшенчәләр**

1. Әлеге Законда төшенчәләр Федераль закондагы мәгънәсендә кулланыла.

2. Транспорт инфраструктурасы объектлары – трамвай һәм эчке су юлларын, контакт линияләрен, автомобиль юлларын, тоннельләрне, эстакадаларны, күперләрне, вокзалларны, тимер юл һәм автобус станцияләрен, метрополитенны, елга портларын, порт чараларын, гидротехник корылмаларны, аэродромнарны, аэропортларны, элемтә, навигация һәм транспорт чаралары хәрәкәтенә идарә итү системалары объектларын, шулай ук транспорт комплексының эшләвен тәэмин итүче бүтән биналарны, корылмаларны, җайланмаларны һәм җиһазларны үз эченә ала торган технологик комплекс ул.

3 статья. **Гавами чаралар уздыру турында хәбәрнамә бирү тәртибе**

1. Гавами чара уздыру турындагы хәбәрнамә территориясендә гавами чара уздыру планлаштырыла торган муниципаль берәмлек – шәһәр яисә авыл җирлеге, шәһәр округы администрациясенә язма рәвештә бирелә.

2. Әгәр гавами чараны берничә җирлек территориясендә уздыру планлаштырылса, гавами чара уздыру турындагы хәбәрнамә муниципаль район администрациясенә бирелә.

3. Әгәр гавами чараны берничә муниципаль район, шәһәр округы территориясендә уздыру планлаштырылса, гавами чара уздыру турындагы хәбәрнамә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләт тапшырган башкарма хакимият органына бирелә.

4. Муниципаль берәмлекләр администрацияләрендә һәм әлеге статьяның 3 өлешендә күрсәтелгән органда гавами чаралар уздыру турындагы хәбәрнамәләрне кабул итү өчен җаваплы вазыйфаи затлар һәм (яисә) структур бүлекчәләр билгеләнә.

4 статья. **Гавами чаралар уздыру урыннарын билгеләү тәртибе**

1. Иҗтимагый әһәмияттәге мәсьәләләр турында күмәк фикер алышу һәм җәмәгатьчелек фикерләрен белдерү өчен, шулай ук башлыча иҗтимагый-сәяси характердагы актуаль проблемаларга кагылышлы җәмәгатьчелек фикерен гавами белдерү өчен гражданнарның күпләп җыелуы өчен махсус бирелгән яисә җайлаштырылган бердәм урыннарны (алга таба – махсус бирелгән

урыннар) Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләт тапшырган орган билгели.

2. Махсус бирелгән урыннар билгеләнгәннән соң, гавами чаралар, кагыйдә буларак, әлеге урыннарда уздырыла. Гавами чараларны махсус бирелгән урыннардан читтә уздыру бары тик Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты вәкаләт тапшырган орган яисә гавами чаралар уздыру турында хәбәрнамә илтеп бирелгән җирле үзидарә органы (алга таба – вәкаләтле орган) белән килештергәннән соң гына Федераль законда һәм әлеге Законда каралган тәртиптә рөхсәт ителә.

5 статья. **Махсус бирелгән урыннардан файдалану тәртибе**

1. Гавами чараны махсус бирелгән урыннарда уздырганда, оештыручы гавами чараны уздыруны Федераль закон һәм әлеге Закон таләпләре нигезендә тәэмин итәргә тиеш.

2. Башлыча иҗтимагый-сәяси характердагы актуаль проблемаларга кагылышлы җәмәгатьчелек фикерен гавами белдерү өчен гражданнарның күпләп җыелуын оештыручы әлеге гавами чараны уздыру өчен махсус бирелгән урыннан Федераль законның 7 статьясындагы 1 өлешендә билгеләнгән срокларда файдаланырга ниятләгән очракта, бу хакта вәкаләтле органга хәбәр итә.

3. Федераль законда каралган нигезләр булганда, вәкаләтле орган, хәбәрнамә алган көннән соң килүче эш көненнән дә соңга калмыйча, махсус бирелгән урында гавами чара уздыруны килештерүдән баш тарта.

4. Махсус бирелгән урыннардан файдалану чиратлылыгы, тиешле мәгълүмат (хәбәрнамә) алу вакытыннан чыгып, вәкаләтле орган тарафыннан билгеләнә.

5. Махсус бирелгән урыннарда гавами чаралар уздыру турында гавами чараларны оештыручылар тарафыннан бирелгән хәбәрнамә хакындагы мәгълүмат, гавами чараларны уздыру датасын, вакытын һәм урынын күрсәтеп, хәбәрнамә алынган көнне вәкаләтле органның «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендәге сайтында урнаштырыла.

6 статья. **Гавами чаралар уздырганда махсус бирелгән урыннар тулуның иң чик нормалары**

Федераль закон нигезендә махсус бирелгән урыннар тулуның түбәндәге иң чик нормалары билгеләнә:

1) гавами чара уздыру урынында тамашачылар өчен стационар урыннар белән җиһазландырылган бина тулуның иң чик нормасы – тамашачылар өчен стационар урыннар саныннан артык түгел;

2) гавами чара уздыру урынында тамашачылар өчен стационар урыннар белән җиһазландырылмаган бина тулуның иң чик нормасы 1 кв. метрга бер кешедән артык түгел йә бинаның (корылманың) техник паспорты нигезендә;

3) мәйданнарда, скверларда, паркларда территория тулуның иң чик нормасы 1,25 кв. метрга бер кешедән артык түгел;

4) тротуарларда, административ (әлеге Законның 12 статьясындагы 3 пунктында күрсәтелгән урыннардан гайре) һәм сәүдә үзәкләре, мәдәният-күңел ачу учреждениеләре һәм базарлар янындагы мәйданчыкларда территория тулуның иң чик нормасы – 3 кв. метрга бер кешедән артык түгел;

5) гавами чара уздыру урынында транспорт инфраструктурасы объекты территориясе тулуның иң чик нормасын исәпләп чыгарганда гавами чара уздыру урынында транспорт инфраструктурасы объекты территориясенең икедән береннән артыграк булмаган өлеше (юлның транспорт чарасы йөрер өчен берничә өлеше булганда) файдаланыла. Гавами чара уздыру урынында транспорт инфраструктурасы объекты территориясенең икенче өлеше транспорт хәрәкәте, шул исәптән гомуми файдаланудагы транспорт хәрәкәте, һәм гавами чарада катнашмаучы гражданнар хәрәкәте өчен файдаланыла.

7 статья. **Иҗтимагый әһәмиятле мәсьәләләр турында күмәк фикер алышуда катнашучы затларның иң чик саны**

1. Иҗтимагый әһәмиятле мәсьәләләр турында күмәк фикер алышуда катнашучы затларның иң чик саны 150 кеше тәшкил итә.

2. Иҗтимагый әһәмиятле мәсьәләләр турында күмәк фикер алышу уздыру турында хәбәрнамә таләп ителми.

3. Махсус бирелгән бер үк урында бер үк вакытта әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән бердән артыграк гавами чара уздырыла алмый.

8 статья. **Пикет уздырганда затлар арасындагы мөмкин булган минималь ара**

Бер катнашучы сыйфатында пикет уздыручы затлар арасындагы мөмкин булган минималь ара 30 метрдан ким була алмый.

9 статья. **Тарихи һәм мәдәни ядкарьләр булган объектлар территорияләрендә гавами чара уздыру тәртибе**

Тарихи һәм мәдәни ядкарьләр булган объектлар территорияләрендә гавами чара уздыру тәртибе, мондый объектларның үзенчәлекләрен һәм Федераль закон таләпләрен исәпкә алып, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнә.

10 статья. **Гомуми файдаланудагы транспорт өчен кулланыла торган транспорт инфраструктурасы объектларында гавами чара уздыру тәртибе**

1. Гомуми файдаланудагы транспорт өчен кулланыла торган транспорт инфраструктурасы объектларында (алга таба – транспорт инфраструктурасы объектлары) гавами чара уздыру Россия Федерациясе законнары таләпләрен үтәп гамәлгә ашырылырга тиеш.

2. Транспорт инфраструктурасы объектларында гавами чараны оештыручы гавами чара (җыелыштан һәм бер катнашучы тарафыннан уздырыла торган пикеттан гайре) уздыру турындагы хәбәрнамәне Федераль законда билгеләнгән срокларда вәкаләтле органга язма рәвештә җибәрә.

3. Вәкаләтле орган, транспорт инфраструктурасы объектларында гавами чара уздырылу турында хәбәрнамә алганнан соң – аны теркәү көнендә, ә хәбәрнамә 16 сәгатьтән соң кергән очракта, киләсе эш көненең беренче яртысында хәбәрнамәнең күчермәсен Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең транспорт һәм юллар хуҗалыгы өлкәсендә вәкаләтле органына җибәрә.

4. Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең транспорт һәм юллар хуҗалыгы өлкәсендә вәкаләтле органы, киләсе эш көненнән дә соңга калмыйча, вәкаләтле органга транспорт инфраструктурасы объектында гавами чара уздыру мөмкинлеге турында дәлилләнгән бәяләмә белән бергә, шул исәптән транспорт инфраструктурасы субъекты фикерен исәпкә алып, рәсми җавап җибәрә.

5. Транспорт инфраструктурасы объектында гавами чара уздыру турында уңай карар кабул ителгән очракта, вәкаләтле ор-

ган, гавами чараны оештыручыга шушы гавами чараны уздыруда ярдәм итү максатларында, вәкаләтле вәкил билгели. Вәкаләтле вәкил билгеләп куюю язма күрсәтмә белән рәсмиләштерелә. Вәкаләтле вәкил билгеләп кую турындагы күрсәтмәне вәкаләтле орган өч эш көне эчендә гавами чараны оештыручыга җибәрә.

6. Транспорт инфраструктурасы объектларында гавами чара уздыру барышында транспорт инфраструктурасы объектларына зыян китерү куркынычы яный торган гамәлләр кылу тыела.

7. Транспорт инфраструктурасы объектларында гавами чара уздыруның билгеләнгән тәртибен транспорт чараларына зыян китерерлек яисә аларны юкка чыгарырлык итеп бозулар очракларында, гавами чараны оештыручылар китерелгән зыянны Россия Федерациясе законнары нигезендә түләргә тиеш.

8. Гавами чараларны транспорт инфраструктурасы объектлары территориясендә транспорт чараларын кулланып оештырганда һәм уздырганда, вәкаләтле орган бер оешкан транспорт колоннасы составында хәрәкәт итә алган транспорт чараларының иң чик санын, транспорт чараларының категорияләрен исәпкә алып, гавами чараның һәр категориясе өчен конкрет билгели. Бу чакта бер оешкан транспорт колоннасы составындагы транспорт чараларының максималь саны түбәндәгеләрдән артык була алмый:

1) «A» категориясе өчен 35 берәмлектән;
2) «B» категориясе өчен 30 берәмлектән;
3) «C» категориясе өчен 25 берәмлектән;
4) «D» категориясе өчен 20 берәмлектән;
5) «E» категориясе өчен 15 берәмлектән.

9. Бер оешкан транспорт колоннасы составында төрле категориядәге транспорт чаралары кулланылганда, аларның максималь саны әлеге статья таләпләрен исәпкә алып билгеләнә.

10. Гавами чараларны транспорт инфраструктурасы объектлары территориясендә махсус техника (транспорт чаралары категориясенә карамаган) кулланып оештырганда һәм уздырганда тәртип вәкаләтле орган тарафыннан һәр чара өчен конкрет билгеләнә.

11. Гавами чаралар уздырганда транспорт чаралары түбәндәге урыннарда кулланыла алмый:

1) барлык механик транспорт чараларының яисә гавами чарада кулланыла торган транспорт чаралары категорияләренең хәрәкәте тыелган юллар участокларында;

2) маршрутлы транспорт чаралары хәрәкәте өчен аерып куелган юллар участокларында;

3) юлларга техник хезмәтләр күрсәтелә һәм ремонтлау башкарыла торган юллар участокларында;

4) тарихи һәм мәдәни ядкарьләр булган объектлар территорияләрендә, саклау зоналарында, шулай ук, транспорт иминлеген һәм юл хәрәкәте иминлеген тәэмин итү буенча федераль законнарда һәм бүтән норматив хокукый актларда каралган таләпләрне исәпкә алып, бүтән урыннарда.

11 статья. **Транспорт инфраструктурасы объектларында гавами чара уздыру урынын һәм (яисә) вакытын үзгәртү**

1. Татарстан Республикасы башкарма хакимиятенең транспорт һәм юллар хуҗалыгы өлкәсендәге вәкаләтле органының транспорт инфраструктурасы объектларында гавами чара уздыруга каршы килә торган хәлләр турындагы бәяләмәсе түбәндәге очракларда бирелә:

1) транспорт инфраструктурасы объекты авария хәлендә булса һәм аның территориясендә гавами чара уздыру гавами чарада катнашучыларның сәламәтлегенә һәм иминлегенә куркыныч тудырса;

2) гавами чара планлаштырыла торган мизгелгә транспорт инфраструктурасы объектында ремонт эшләре башкарылса;

3) гавами чара уздыру гражданнарның транспорт инфраструктурасы объектыннан файдалануына каршылык (чикләү) тудырса яисә транспорт инфраструктурасы объектларында транспорт чаралары хәрәкәтен тулысынча (өлешчә) туктатуны таләп итсә.

2. Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән бәяләмә гавами чара уздыру урынын һәм (яисә) вакытын үзгәртү турындагы нигезләнгән тәкъдимне Федераль законда билгеләнгән срокларда вәкаләтле орган тарафыннан гавами чараны оештыручыга җиткерү өчен нигез була.

12 статья. **Гавами чаралар уздыру тыела торган урыннар**

Кеше һәм граждан хокукларын һәм ирекләрен яклау, законлылыкны, хокук тәртибен һәм иҗтимагый иминлекне тәэмин итү максатларында, шул исәптән гавами чаралар уздыру яшәешне тәэмин итү, транспорт йә социаль инфраструктура, элемтә объектларының эшләвен бозуга китерерлек, җәяүлеләрнең һәм (яисә) транспорт чараларының хәрәкәтенә яисә гражданнарның торак урыннарына йә транспорт яки социаль инфраструктура объектларына керүенә тоткарлык тудырса, җыелышларны, митинг-

ларны, урам йөрешләрен, демонстрацияләрне түбәндәге урыннарда уздыру Федераль закон нигезендә тыела:

1) яшәешне тәэмин итү объектларыннан һәм хәрби объектлардан 500 метрдан якынрак урнашкан;

2) тимер юл вокзалларыннан һәм платформаларыннан, автобус һәм елга вокзалларыннан, аэропортлардан 200 метрдан якынрак урнашкан;

3) дәүләт хакимияте, прокуратура, консуллык органнары, мәгариф, сәламәтлек саклау учреждениеләре били торган биналардан һәм гыйбадәтханә корылмаларыннан 50 метрдан якынрак урнашкан.

13 статья. **Татарстан Республикасының аерым законнарының үз көчләрен югалтуын тану**

Түбәндәгеләрне үз көчләрен югалткан дип танырга:

1) «Татарстан Республикасында җыелышлар, митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар уздыру турында хәбәрнамә бирү тәртибе хакында» 2006 елның 16 гыйнварындагы 1-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2006, № 1);

2) «Татарстан Республикасында транспорт инфраструктурасы объектларында гавами чара уздыру тәртибе турында» 2011 елның 19 мартындагы 4-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законын (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2011, № 3).

14 статья. **Әлеге Законның үз көченә керүе**

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты үзенең норматив хокукый актларын әлеге Законга туры китерергә, шулай ук әлеге Законда каралган Татарстан Республикасы норматив хокукый актларының кабул ителүен тәэмин итәргә тиеш.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 елның 25 декабре
№ 91-ТРЗ

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

### 1884. Татарстан Республикасы Президентын чакыртып алу тәртибе турында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2012 елның 24 декабрендә
кабул ителде

1 бүлек. **Гомуми нигезләмәләр**

1 статья. **Әлеге Законның җайга салу предметы**

1. Әлеге Закон Татарстан Республикасы Президентын чакыртып алуны (алга таба – чакыртып алу) оештыру һәм уздыру тәртибен билгели.

2. Чакыртып алу «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» 1999 елның 6 октябрендәге 184-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон), «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 елның 12 июнендәге 67-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон), башка федераль законнар, Татарстан Республикасы Конституциясе, әлеге Закон нигезендә уздырыла.

2 статья. **Чакыртып алу хокукы**

1. Чакыртып алу хокукы турыдан-туры демократияне гамәлгә ашыру рәвешләренең берсе, шулай ук Татарстан Республикасы Президентының законнар белән беркетелгән үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыруын Россия Федерациясе гражданнары тарафыннан тикшереп тору чараларының берсе була.

2. Чакыртып алу буенча тавыш бирүне уздыру инициативасы Татарстан Республикасы Президенты вазыйфасына керешкән көннән кимендә бер ел узгач күрсәтелергә мөмкин.

3 статья. **Төп терминнар һәм төшенчәләр**

1. Әлеге Законда кулланыла торган төп терминнар һәм төшенчәләр, әгәр әлеге Законда башкасы каралмаган булса, «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закондагы мәгънәләрендә кулланыла.

2. Әлеге Закон максатлары өчен түбәндәге терминнар һәм төшенчәләр кулланыла:

1) чакыртып алу мәсьәләләре буенча агитация – чакыртып алу кампаниясе чорында гамәлгә ашырыла торган һәм сайлаучыларда – чакыртып алу буенча тавыш бирүне уздыру инициативасын имзалар кәгазьләренә имзалар кую юлы белән хуплау йә мондый хуплаудан баш тарту, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларда чакыртып алу буенча тавыш бирү йә тавыш бирүдән баш тарту, чакыртып алуны хуплау яисә аңа каршы тавыш бирү теләген уяту максаты булган яисә уята торган эшчәнлек;

2) яшәү урыны адресы – Россия Федерациясе чикләрендә тору урыны буенча һәм яшәү урыны буенча Россия Федерациясе гражданнарын теркәүне исәпкә алу органнарында яшәү урыны буенча Россия Федерациясе гражданы теркәлгән һәм паспортта яисә граждан паспортын алыштыра торган документта гражданның яшәү урыны буенча теркәлүе турында тамга булган адрес (Россия Федерациясе субъектының, районның, шәһәрнең, башка торак пунктның, урамның исеме, йорт һәм фатир номеры);

3) сайлаучы – Татарстан Республикасы Президентын сайлауларда актив сайлау хокукына ия Россия Федерациясе гражданы;

4) чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның башка төркеме – чакыртып алу мәсьәләләре буенча агитация үткәрү максатларында әлеге Законда билгеләнгән тәртиптә һәм срокка төзелә торган чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар төркеме;

5) инициатив төркем – чакыртып алу буенча тавыш бирүне уздыру буенча чакыртып алу буенча тавыш бирүне уздыру инициативасын гамәлгә ашыру максатларында әлеге Законда билгеләнгән тәртиптә һәм срокка төзелә торган инициатив төркем;

6) чакыртып алу кампаниясе – чакыртып алу буенча тавыш бирүне әзерләү һәм уздыру буенча чакыртып алу буенча тавыш бирүне уздыру буенча инициатив төркем теркәлгән көннән башлап Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан Татарстан Республикасы Дәүләт Советына чакыртып алуны әзерләүгә һәм уздыруга бүлеп бирелгән Татарстан Республикасы

бюджеты акчаларын тоту турында хисап бирелгән көнгә кадәрге йә чакыртып алу буенча тавыш бирүне уздыру инициативасын гамәлгә ашыру процедуралары законда каралган нигезләрдә туктатылган көнгә кадәрге чорда башкарыла торган эшчәнлек;

7) чакыртып алу – чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашу хокукына ия Россия Федерациясе гражданнарының Татарстан Республикасы Президентының вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турындагы мәсьәлә буенча федераль законнар, Татарстан Республикасы Конституциясе, әлеге Закон нигезендә гамәлгә ашырыла торган турыдан-туры ихтыяр белдерү рәвеше;

8) чакыртып алынучы зат – үзенә карата чакыртып алу буенча тавыш бирүне уздыру инициативасы күрсәтелгән Татарстан Республикасы Президенты;

9) чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучы – чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашу хокукына ия Россия Федерациясе гражданы.

4 статья. **Чакыртып алу буенча тавыш бирүне уздыру принциплары**

1. Россия Федерациясе гражданы чакыртып алу буенча тавыш бирүдә, яшерен тавыш биреп, гомуми тигез һәм турыдан-туры ихтыяр белдерү нигезендә катнаша.

2. Чакыртып алу буенча тавыш бирүдә Россия Федерациясе гражданының катнашуы ирекле һәм ихтыярый. Россия Федерациясе гражданына беркем дә аны чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашуга яисә катнашмауга мәҗбүр итү йә аның ирекле ихтыяр белдерүенә тоткарлык ясау максатында йогынты ясарга хокуклы түгел.

3. Чит ил гражданнарының, гражданлыгы булмаган затларның, чит ил юридик затларының, халыкара оешмаларның һәм халыкара иҗтимагый хәрәкәтләрнең чакыртып алу буенча тавыш бирүне әзерләүгә һәм уздыруга ярдәм итә йә тоткарлык тудыра торган эшчәнлекне гамәлгә ашыруда катнашуы рөхсәт ителми.

4. Россия Федерациясе гражданнары чакыртып алу буенча тавыш бирүдә, шулай ук чакыртып алуга бәйле башка гамәлләрдә бертигез нигезләрдә катнашалар.

5. Россия Федерациясе гражданы чакыртып алуны хуплап яисә чакыртып алуга каршы үзе тавыш бирә.

6. Чакыртып алу буенча тавыш бирү, гражданның ихтыяр белдерүен ничек тә булса тикшереп торуны булдырмаслык итеп, яшерен башкарыла.

7. Чакыртып алу буенча тавыш бирүне әзерләгәндә һәм уздырганда, тавышларны санаганда, тавыш бирү йомгакларын билгеләгәндә, чакыртып алу буенча тавыш бирү нәтиҗәләрен ачыклаганда комиссияләр эшчәнлеге ачык һәм хәбәрдар була.

8. Чакыртып алу буенча тавыш бирүне әзерләүне һәм уздыруны гамәлгә ашыручы комиссияләр (алга таба шулай ук – чакыртып алу комиссияләре) эшчәнлегенә дәүләт хакимияте органнарының, җирле үзидарә органнарының, оешмаларның, вазыйфаи затларның, башка гражданнарның тыкшынуы рөхсәт ителми.

9. Чакыртып алу буенча тавыш бирү бюллетеньнәре, тавыш бирү нәтиҗәләре турындагы беркетмәләр һәм күрсәткечләр, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә кабул ителгән карар, дәүләт хакимияте органнарының чакыртып алу буенча тавыш бирүне уздыруга кагылышлы документлары – Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә, ә кирәк очракларда халык оешып яши торган территориядә кулланыла торган телләрдә төзелә (бастырып чыгарыла).

10. Срокларны исәпләп чыгару тәртибе «Татарстан Республикасы референдумы турында» 2003 елның 9 августындагы 33-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының $8^1$ статьясы нигезендә билгеләнә.

5 статья. **Россия Федерациясе гражданнарының чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашу хокукы**

1. Яшәү урыны Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан, тавыш бирү көненә 18 яше тулган, суд тарафыннан хокуктан файдалануга сәләтсез дип танылмаган, суд карары белән иректән мәхрүм итү урыннарында тормый торган Россия Федерациясе гражданы чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашырга хокуклы.

2. Яшәү урыны Татарстан Республикасы территориясендә урнашкан, чакыртып алу буенча тавыш бирүне уздыру инициативасын күрсәткән, чакыртып алу буенча тавыш бирүне уздыру инициативасын хуплап имзалар кәгазендә имза куйган көнгә 18 яше тулган Россия Федерациясе гражданы шушы инициативаны хуплауда катнашырга, имза кәгазендә үз имзасын куярга хокуклы.

3. 18 яше тулган Россия Федерациясе гражданы чакыртып алу мәсьәләләре буенча агитациядә катнашырга, чакыртып алу буенча тавыш бирүне уздыру инициативасын хуплап имзалар

җыярга, шулай ук чакыртып алу буенча тавыш бирүне әзерләү һәм уздыру буенча башка законлы гамәлләрдә катнашырга хокуклы.

4. Россия Федерациясе гражданы, җенесенә, расасына, милләтенә, теленә, чыгышына, мөлкәти һәм вазыйфаи хәленә, дингә мөнәсәбәтенә, инануларына, нинди иҗтимагый берләшмәләргә каравына, шулай ук башка шартларга бәйсез рәвештә, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашырга хокуклы.

5. Суд тарафыннан хокуктан файдалануга сәләтсез дип танылган яисә суд карары белән irектән мәхрүм итү урыннарында тора торган гражданнар чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашырга хокуклы түгел.

6 статья. **Чакыртып алынучы затның закон белән гарантияләнгән хокуклары**

1. Чакыртып алынучы затның чакыртып алу өчен нигез буларак күрсәтелә торган шартларга карата аңлатмалар бирү мөмкинлеге бар. Чакыртып алуны гамәлгә ашыруның барлык этапларында чакыртып алынучы судта намусын һәм абруен, граждан хокукларын һәм ирекләрен яклау хокукыннан файдаланырга мөмкин.

2. Чакыртып алынучы затның чакыртып алу инициативасын күрсәтү барышында, шулай ук агитация чорында чакыртып алу өчен нигез буларак күрсәтелә торган шартларга карата аңлатмалар бирү хокукын гамәлгә ашыру рәвешләре әлеге Законда билгеләнә.

7 статья. **Чакыртып алу кампаниясе барышында вазыйфаи яисә хезмәт урыны өстенлекләреннән файдалануны булдырмау**

1. Дәүләт яисә сайланулы муниципаль вазыйфаларны биләүче йә дәүләт яисә муниципаль хезмәттәге, йә барлык милек рәвешләрендәге оешмаларның, сәяси партияләрдән тыш, идарә органнары әгъзалары (идарә итүнең югары органы җыен булган оешмаларда – бу оешмалар эшчәнлегенә җитәкчелекне гамәлгә ашыручы органнары әгъзалары) булган затлар чакыртып алу буенча тавыш бирүне уздыру инициативасын күрсәтү һәм хуплау, чакыртып алу буенча тавыш бирүнең теге яисә бу нәтиҗәсенә ирешү максатларында үзләренең вазыйфаи яисә хезмәт урыны өстенлекләреннән файдаланырга хокуклы түгел.

2. Әлеге Законда вазыйфаи яисә хезмәт урыны өстенлекләреннән файдалану дигәндә түбәндәгечә аңларга кирәк:

1) үз буйсынуындагы яисә хезмәттә башкача бәйле булган затларны, дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрләрне хезмәт (эш) вакытында чакыртып алу буенча тавыш бирүне уздыру инициативасын күрсәтүгә һәм хуплауга, чакыртып алу буенча тавыш бирүнең теге яисә бу нәтиҗәсенә ирешүгә ярдәм итә торган эшчәнлеккә җәлеп итү;

2) дәүләт органнары яисә җирле үзидарә органнары, барлык милек рәвешләрендәге оешмалар били торган биналардан, сәяси партияләр били торган биналардан тыш, чакыртып алу буенча тавыш бирүне уздыру инициативасын күрсәтүгә һәм хуплауга, чакыртып алу буенча тавыш бирүнең теге яисә бу нәтиҗәсенә ирешүгә ярдәм итә торган эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен файдалану, әгәр күрсәтелгән биналарны чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның башка төркемнәренә шундый ук шартларда бирү гарантияләнмәгән булса;

3) дәүләт органнарының, җирле үзидарә органнарының, дәүләт һәм муниципаль учреждениеләрнең, барлык милек рәвешләрендәге оешмаларның эшчәнлеген тәэмин итә торган телефон элемтәсеннән, факсимиль элемтәдән һәм элемтәнең башка төрләреннән, оештыру техникасыннан һәм мәгълүмат хезмәтләреннән, сәяси партияләрнең эшчәнлеген тәэмин итә торган шундый ук элемтә төрләреннән, оештыру техникасыннан һәм мәгълүмат хезмәтләреннән тыш, чакыртып алу мәсьәләләре буенча агитация үткәрү өчен файдалану, әгәр алардан файдалану чакыртып алу буенча тавыш бирүнең тиешле фондыннан түләнмәгән булса;

4) дәүләт яисә муниципаль милектәге, оешмалар милкендәге транспорт чараларыннан, сәяси партияләр милкендәге транспорт чараларыннан тыш, чакыртып алу буенча тавыш бирүне уздыру инициативасын күрсәтүгә һәм хуплауга, чакыртып алу буенча тавыш бирүнең теге яисә бу нәтиҗәсенә ирешүгә ярдәм итә торган эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен түләүсез яисә ташламалы шартларда файдалану. Әлеге нигезләмә күрсәтелгән транспорт чараларыннан дәүләт саклавы турында Россия Федерациясе законнары нигезендә файдаланучы затларга кагылмый;

5) дәүләт яисә сайланулы муниципаль вазыйфаларны биләүче, йә дәүләт яисә муниципаль хезмәттәге, йә җирле администрация башлыклары булып торучы, йә барлык милек рәвешләрендәге оешмаларның, сәяси партияләрдән тыш, идарә органнары әгъзалары (идарә итүнең югары органы җыен булган оешмаларда – бу оешмалар эшчәнлегенә җитәкчелекне гамәлгә ашыручы органнары әгъзалары) булып торучы затлар тарафыннан хезмәт (тиешле бюджет акчалары, тиешле оешма акчалары исәбеннән түләнә торган) командировкалары барышында сайлау-

чылар имзаларын җыю, чакыртып алу мәсьәләләре буенча агитация үткәрү;

6) сайлаучылар имзаларын җыю, чакыртып алу мәсьәләләре буенча агитация үткәрү максатларында дәүләт һәм муниципаль массакүләм мәгълүмат чараларыннан файдалану (файдалануны тәэмин итү), әгәр чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның башка төркемнәренә шул максатлар өчен әлеге Закон нигезендә шундый ук файдалану гарантияләнмәгән булса;

7) дәүләт һәм (яисә) муниципаль органнар, барлык милек рәвешләрендәге оешмалар тарафыннан, сәяси партияләрдән тыш, оештырыла торган гавами чараны үткәргәндә чакыртып алу кампаниясе чорында агитация белән чыгу.

2 бүлек. **Чакыртып алу нигезләре**

8 статья. **Чакыртып алу нигезләре**

1. Чакыртып алу түбәндәге нигезләрнең берсе буенча мөмкин:

1) Татарстан Республикасы Президенты Россия Федерациясе законнарын һәм (яисә) Татарстан Республикасы законнарын бозса, бозу факты тиешле суд белән билгеләнгән булса;

2) Татарстан Республикасы Президенты үз вазыйфаларын мөһим сәбәпләрсез тупас рәвештә берничә мәртәбә үтәмәсә, бу тиешле суд белән билгеләнгән булса.

2. «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль закон нигезендә әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән фактларны билгеләү турындагы гариза белән Татарстан Республикасы Югары Судына сәяси партияләр, аларның региональ бүлекчәләре, башка иҗтимагый берләшмәләр, шулай ук кимендә 100 кешедән торган, Татарстан Республикасы территориясендә яшәүче һәм Татарстан Республикасы Президентын сайлауларда актив сайлау хокукына ия Россия Федерациясе гражданнары төркеме мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

3 бүлек. **Чакыртып алу буенча тавыш бирүне уздыру инициативасын гамәлгә ашыру тәртибе**

9 статья. **Чакыртып алу буенча тавыш бирүне уздыру инициативасын гамәлгә ашыру тәртибе**

1. Чакыртып алу буенча тавыш бирүне уздыру инициативасын гамәлгә ашыру максатларында сайлаучылар инициатив төркем төзиләр, аңа кимендә 20 әгъза керергә тиеш.

2. Чакыртып алу буенча тавыш бирүне уздыру инициативасы күрсәтелгән көн итеп чакыртып алу буенча тавыш бирүне уздыру инициативасын күрсәтү турында инициатив төркемнең карары кабул ителә торган җыелыш үткәрелгән көн санала.

3. Инициатив төркем җыелышын үткәрү датасы, урыны һәм вакыты турында аны үткәрү көненә кадәр 10 көннән дә соңга калмыйча язма рәвештә Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенә, шулай ук чакыртып алынучыга хәбәр ителергә тиеш, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе инициатив төркем мөрәҗәгать иткән көннән башлап чакыртып алу комиссиясе буларак эш итә.

4. Инициатив төркемнең чакыртып алу буенча тавыш бирүне уздыру инициативасын күрсәтү турындагы карары кабул ителә торган җыелышы Татарстан Республикасы территориясендә үткәрелә.

5. Инициатив төркем җыелышында Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе вәкиле, шулай ук чакыртып алынучы зат яисә аның вәкиле катнашырга хокуклы.

6. Инициатив төркем җыелышында катнашучы Россия Федерациясе гражданнары чакыртып алынучы затның яисә аның вәкиленең әлеге статьяның 5 өлешендә каралган хокукын гамәлгә ашыруларын чикләргә хокуклы түгел.

7. Инициатив төркем төзү турындагы тәкъдим хупланган очракта, инициатив төркем җыелышы түбәндәге карарларны кабул итә:

1) чакыртып алу буенча тавыш бирүне уздыру инициативасын күрсәтү һәм инициатив төркем төзү турында;

2) инициатив төркем әгъзалары арасыннан инициатив төркем исеменнән эш итәргә вәкаләтле затларны – инициатив төркемнең вәкаләтле вәкилләрен, шул исәптән финанс мәсьәләләре буенча, билгеләп кую турында;

3) инициатив төркемнең бер яисә берничә вәкаләтле вәкиленә төркем исеменнән ышанычнамәләр тапшыру хокукын бирү турында.

8. Инициатив төркем җыелышының карарлары аның беркетмәсендә чагылдырыла, ул җыелышта рәислек итүче һәм җыелышның секретаре тарафыннан имзалана.

9. Әгәр инициатив төркем җыелышының карары өчен җыелышта катнашучыларның яртысыннан күбрәге, әмма инициатив төркем әгъзаларының әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән минималь саныннан кимрәк булмаган өлеше хуплап тавыш бирсә, ул кабул ителгән дип санала.

10. Инициатив төркемнең вәкаләтле вәкилләре инициатив төркем җыелышын үткәргәннән соң өч айдан да соңга калмыйча инициатив төркемне теркәү турындагы үтенечнамә белән Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенә мөрәҗәгать итәләр, анда Татарстан Республикасы Президентын чакыртып алуның нигезе (нигезләре) күрсәтелергә, ул (алар) тиешле суд карары (суд карарлары) белән, суд карарын кабул итү датасы һәм эшнең (эшләрнең) номеры күрсәтелеп, расланган булырга тиеш. Инициатив төркемнең үтенечнамәсендә шулай ук инициатив төркемнең һәр әгъзасының һәм аның исеменнән эш йөртергә вәкаләтле затларның – инициатив төркемнең вәкаләтле вәкилләренең, шул исәптән финанс мәсьәләләре буенча, фамилиясе, исеме, атасының исеме, туу датасы һәм урыны, паспортының яисә граждан паспортын алыштыручы документының сериясе, номеры һәм бирелү датасы, аны биргән органның исеме яисә коды, шулай ук яшәү урыны адресы күрсәтелгән булырга тиеш. Инициатив төркемнең үтенечнамәсе инициатив төркемнең барлык әгъзалары тарафыннан имзаланырга тиеш.

11. Инициатив төркемне теркәү турындагы үтенечнамәгә түбәндәгеләр өстәлеп бирелергә тиеш:

1) инициатив төркем җыелышының беркетмәсе, анда җыелышны уздыру датасы һәм урыны күрсәтелгән булырга тиеш, әлеге статьяның 7 өлешендә күрсәтелгән мәсьәләләр буенча тавыш бирү нәтиҗәләре;

2) инициатив төркемнең финанс мәсьәләләре буенча вәкаләтле вәкилләренә нотариаль таныкланып рәсмиләштерелгән таныклыклар һәм инициатив төркемнең финанс мәсьәләләре буенча вәкаләтле вәкилләре булырга ризалык бирү турында әлеге затларның гаризалары.

12. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе инициатив төркемне теркәү турында үтенечнамә алган көннән башлап 15 көн эчендә үтенечнамәнең һәм аңа өстәлеп бирелгән документларның әлеге Законда каралган таләпләргә туры килүен тикшерә һәм түбәндәге карарларның берсен кабул итә:

1) инициатив төркемне һәм аның вәкаләтле вәкилләрен теркәү турында, бу чакта инициатив төркемгә теркәү таныклыгы бирелә, аның рәвеше Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнә. Инициатив төркемнең теркәү таныклыгы инициатив төркемне теркәү турында карар кабул ителгән көннән башлап чакыртып алу буенча тавыш бирү нәтиҗәләре рәсми басылып чыккан көнгә кадәр гамәлдә була. Инициатив төркемгә тапшырылган теркәү таныклыгында чакыртып алу бу-

енча тавыш бирүне уздыру инициативасын хуплап имзалар җыю срогы тәмамлана торган дата һәм әлеге Законның 10 статьясындагы 1 өлеше нигезендә инициатив төркем җыярга тиешле сайлаучылар имзаларының саны (абсолют санда) күрсәтелә;

2) инициатив төркемне теркәүдән баш тарту турында.

13. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең инициатив төркемне теркәү яисә аны теркәүдән баш тарту турындагы карары массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгарылырга тиеш.

14. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең инициатив төркемне теркәү турындагы мәсьәлә карала торган утырышына катгый тәртиптә инициатив төркемнең вәкаләтле вәкиле һәм чакыртып алынучы зат чакырылалар.

15. Инициатив төркемне һәм аның вәкаләтле вәкилләрен теркәүдән баш тарту өчен түбәндәгеләр нигез була:

1) әлеге Законның 8 статьясындагы 1 өлеше таләпләре үтәлмәү;

2) чакыртып алу буенча тавыш бирүне уздыру инициативасын күрсәткәндә инициатив төркем тарафыннан әлеге статьяның 3, 4, 6 – 9 өлешләренең таләпләре үтәлмәү;

3) инициатив төркем тарафыннан тапшырылган документларның әлеге статьяның 10, 11 өлешләре таләпләренә туры килмәве;

4) әлеге Законның 15 статьясы нигезләмәләре үтәлмәү.

16. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең инициатив төркемне теркәүдән баш тарту турындагы карарында инициатив төркемне теркәүдән баш тартуның нигезләре күрсәтелә. Мондый карар инициатив төркемгә тапшырыла, шуннан соң чакыртып алуны уздыру инициативасын гамәлгә ашыру процедуралары туктатыла.

17. Инициатив төркемне теркәүдән баш тартуга карата «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 75 статьясында билгеләнгән тәртиптә шикаять бирелергә мөмкин.

18. Инициатив төркем чакыртып алу буенча тавыш бирүне билгеләү турында карар рәсми басылып чыккан көнгә кадәр үз инициативасын составына керә торган әгъзаларының яртысыннан күбрәгенең уңай тавыш бирү нәтиҗәсе белән җыелыш беркетмәсен Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенә тапшыру юлы белән кире алырга хокуклы. Тапшырылган документларны карау нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы

Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан чакыртып алу буенча тавыш бирүне уздыру инициативасын гамәлгә ашыру процедураларын туктату турында карар кабул итә.

10 статья. **Чакыртып алу буенча тавыш бирүне уздыру инициативасын күрсәтүне хуплап имзалар җыю**

1. Инициатив төркем «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 16 статьясындагы 10 пункты нигезендә Татарстан Республикасы территориясендә теркәлгән сайлаучылар санынннан 25 процент күләмендә чакыртып алу буенча тавыш бирүне уздыру инициативасын хуплап сайлаучылар имзаларын җыярга тиеш.

2. Чакыртып алу буенча тавыш бирүне уздыру инициативасын хуплап имзалар җыю инициатив төркем теркәлгән көннең иртәгесеннән башлап 45 көн эчендә башкарыла. Имзалар кәгазьләрен әзерләү өчен түләнгән көннән башлап та имзалар җыелырга мөмкин.

3. Чакыртып алу буенча тавыш бирүне уздыру инициативасын хуплап имзалар җыю хокукына имзалар җыю вакытына 18 яше тулган һәм суд тарафыннан хокуктан файдалануга сәләтсез дип танылмаган Россия Федерациясе гражданы ия. Инициатив төркемнең финанс мәсьәләләре буенча вәкаләтле вәкиле сайлаучылар имзаларын җыюны гамәлгә ашыручы зат белән имзалар җыю турында шартнамә төзергә мөмкин. Бу эш өчен түләү чакыртып алу буенча тавыш бирү фонды акчалары исәбеннән генә гамәлгә ашырыла.

4. Дәүләт хакимияте органнарының, җирле үзидарә органнарының, барлык милек рәвешләрендәге оешмаларның идарә органнарының, комиссияләрнең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзаларының чакыртып алу буенча тавыш бирүне уздыру инициативасын хуплап имзалар җыюда катнашуы, шулай ук имзалар җыю барышында сайлаучыларны мәҗбүр итү һәм имзалар куйган өчен аларны бүләкләү рөхсәт ителми. Эш урыннарында, уку урынында, хезмәт хакы, пенсияләр, пособиеләр, стипендияләр бирү, башка социаль түләүләр башкару барышында һәм урыннарында, шулай ук хәйрия ярдәме күрсәткәндә имзалар җыю тыела. Әлеге өлеш нигезләмәләрен бозып җыелган имзалар гамәлгә яраксыз була.

5. Имзалар кәгазьләре әлеге Законга 1 кушымтадагы рәвеш буенча әзерләнә һәм тутырыла.

6. Имзалар кәгазьләре чакыртып алу буенча тавыш бирү фонды акчалары исәбеннән әзерләнергә тиеш. Имза кәгазендә чакыртып алу буенча тавыш бирү фондының имзалар кәгазьләрен әзерләгән өчен түләү башкарылган махсус счетының номеры күрсәтелә.

7. Сайлаучы имза кәгазендә үз имзасын, аны кую датасын, шулай ук үз фамилиясен, исемен, атасының исемен, туган елын (18 яшьтә – өстәмә рәвештә туган көнен һәм аен), яшәү урыны адресын, паспортының яисә граждан паспортын алыштыра торган документының сериясен, номерын күрсәтә. Имза кәгазендә үз имзасын һәм аны кую датасын күрсәтә торган сайлаучы турындагы белешмәләр имза кәгазенә сайлаучы үтенече буенча имзалар җыюны гамәлгә ашыручы зат тарафыннан кертелергә мөмкин. Күрсәтелгән белешмәләр бары тик кулдан язылa, бу чакта карандаш куллану рөхсәт ителми. Сайлаучы имзасын һәм аны кую датасын шәхсән үзе куя. Сайлаучы чакыртып алу буенча тавыш бирүне уздыруның бер үк инициативасын хуплап бары тик бер генә мәртәбә имза куярга хокуклы.

8. Һәр имза кәгазе имзалар җыюны гамәлгә ашыручы затның имзасы белән таныкланган булырга тиеш. Имза кәгазен таныклаганда имзалар җыюны гамәлгә ашыручы зат үзенең фамилиясен, исемен һәм атасының исемен, туу датасын, яшәү урыны адресын, паспортының яисә граждан паспортын алыштыра торган документының сериясен, номерын һәм аны бирү датасын, аны биргән органның исемен яисә кодын шәхсән үзе язып куя, шулай ук үз имзасын һәм аны кую датасын куя.

9. һәр имза кәгазе инициатив төркемнең вәкаләтле вәкиле тарафыннан таныкланырга тиеш. Имза кәгазен таныклаганда инициатив төркемнең вәкаләтле вәкиле үз фамилиясе, исеме һәм атасының исеме янына үз имзасын һәм аны кую датасын шәхсән үзе куя.

10. Чакыртып алу буенча тавыш бирүне уздыру инициативасын хуплап имзалар җыйганда имза кәгазенең алгы ягын да, арткы ягын да тутыру рөхсәт ителә. Мондый чакта арткы ягы имзаларның бердәм номеры белән алгы якның дәвамы булып тора, ә таныклау язмалары имза кәгазенең арткы ягында сайлаучы куйган соңгы имзадан соң кертелә.

### 11 статья. **Имзалар кәгазьләрен Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенә тапшыру**

1. Чакыртып алу буенча тавыш бирүне уздыру инициативасын хуплап имзалар җыю тәмамланганнан соң инициатив төркем җыелган имзаларның гомуми санын исәпләп чыгара һәм чакыр-

тып алу буенча тавыш бирүне уздыру инициативасын хуплап имзалар җыю йомгаклары турында ике нөсхәдә Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнгән рәвештә беркетмә төзи. Беркетмәнең һәр нөсхәсе инициатив төркемнең вәкаләтле вәкиле тарафыннан шәхсән имзалана.

2. Имзалар кәгазьләре инициатив төркемнең вәкаләтле вәкиле тарафыннан Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенә брошюра итеп тегелгән һәм номерланган килеш чакыртып алу буенча тавыш бирүне уздыру инициативасын хуплап имзалар җыю срогы төгәлләнә торган көндә җирле вакыт белән 18 сәгатькә кадәр тапшырыла. Имзалар кәгазьләре белән бергә Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенә ике нөсхәдә кәгазьдә язылган килеш һәм машинадан укыла торган рәвештә имзалар җыю йомгаклары турындагы беркетмә, шулай ук имзалар кәгазьләрен әзерләү өчен түләү датасын раслый торган документ тапшырыла.

3. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенә тапшырыла торган имзалар саны чакыртып алу буенча тавыш бирүне уздыру инициативасын хуплау өчен әлеге Законның 10 статьясындагы 1 өлешендә билгеләнгән кирәкле саннан артыграк булырга мөмкин, әмма ул 10 проценттан да күбрәк була алмый.

4. Документларны кабул итеп алганда Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе инициатив төркемнең вәкаләтле вәкиленә тапшырылган документларның кабул ителүен раслый торган (аларның исемлеген күрсәтеп) документ бирә, анда кабул итеп алу датасы һәм вакыты күрсәтелә. Бу документта шулай ук кабул итеп алынган имзалар кәгазьләренең саны һәм сайлаучылар имзаларының игълан ителгән саны күрсәтелә. Мондый чакта Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе имзалар кәгазьләре белән һәр папканы үз мөһере (махсус штампы) белән таныклый, тапшырылган имзалар кәгазьләре санының имзалар җыю йомгаклары турындагы беркетмәдә күрсәтелгән санга туры килүен тикшерә. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе инициатив төркемнең вәкаләтле вәкиленә инициатив төркем урнашкан бинага кереп йөрү мөмкинлеген чикләргә яисә аңа, әгәр әлеге статьяның 2 өлешендә күрсәтелгән срок узганчы документлар китереп җиткерелгән булса, документларны кабул итүдән баш тартырга хокуклы түгел.

5. Әгәр чакыртып алу буенча тавыш бирүне уздыруның инициатив төркеме әлеге статьяның 2 өлешендә күрсәтелгән срок уза торган көндә җирле вакыт белән 18 сәгатькә кадәр әлеге статьяның 2 өлешендә күрсәтелгән гамәлләрне башкармаса, Та-

тарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе чакыртып алу буенча тавыш бирүне уздыру инициативасын гамәлгә ашыру процедураларын туктату турында карар кабул итә, ул региональ дәүләт вакытлы матбугат басмасының кимендә берсендә кабул ителгән көннән биш көннән дә соңга калмыйча бастырып чыгарыла һәм инициатив төркемгә җиткерелә.

12 статья. **Чакыртып алу буенча тавыш бирү инициативасын күрсәтүне хуплап җыелган имзаларга тикшерү үткәрү тәртибе**

1. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе имзалар кәгазьләрен һәм әлеге Законның 11 статьясында күрсәтелгән документларны кабул итеп алган көннән 15 көн эчендә чакыртып алу буенча тавыш бирүне уздыру инициативасын хуплап имзалар җыю, имзалар кәгазьләрен тутыру тәртибенең үтәлешен, имзалар кәгазьләрендәге сайлаучылар турында белешмәләрнең һәм аларның имзаларының дөреслеген, шулай ук инициатив төркем тарафыннан үз эшчәнлеген финанслау тәртибенең һәм Татарстан Республикасы Президентын чакыртып алу мәсьәләләре буенча агитация үткәрү кагыйдәләренең үтәлешен тикшерә.

2. Чакыртып алу буенча тавыш бирүне уздыру инициативасын хуплап имзалар җыю, имзалар кәгазьләрен тутыру тәртибенең үтәлешен, имзалар кәгазьләрендәге сайлаучылар турындагы белешмәләрнең һәм аларның имзаларының дөреслеген тикшерү өчен Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе үз карары белән Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе әгъзаларыннан, үз аппараты хезмәткәрләреннән эшче төркемнәр төзергә мөмкин. Тикшерүгә түбәнгерәк комиссияләрнең әгъзалары, эчке эшләр органнары, юстиция учреждениеләре, хәрби комиссариатлар, Россия Федерациясе чикләрендә тору урыны һәм яшәү урыны буенча Россия Федерациясе гражданнарын теркәүне исәпкә алу органнары, башка дәүләт органнары белгечләреннән экспертлар, шулай ук башка затлар «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 28 статьясындагы 19 пункты нигезендә җәлеп ителә алалар. Экспертларның бәяләмәләре имзалар кәгазьләрендәге сайлаучылар турында белешмәләрне һәм аларның имзаларын дөрес түгел һәм (яисә) гамәлгә яраксыз дип тану өчен нигез булырга мөмкин. Экспертларның бәяләмәләре имзалар кәгазьләрен

тикшерү ведомостьларында яисә башка документта язма рәвештә бәян ителә.

3. Имзалар кәгазьләрендәге белешмәләрнең дөреслеген билгеләү өчен «Сайлаулар» Россия Федерациясе Дәүләт автоматлаштырылган системасы (алга таба – «Сайлаулар» ДАС), сайлаучылар, референдумда катнашучылар регистрын да кертеп, кулланыла.

4. Чакыртып алу буенча тавыш бирүне уздыру инициативасын гамәлгә ашыру өчен кирәкле имзаларның һәм имзалар кәгазьләрендә шуларга туры килә торган сайлаучылар турындагы белешмәләрнең кимендә 20 проценты тикшерелергә тиеш.

5. Аралап тикшерү өчен имзалар кәгазьләре очраклы сайлап алу (шобага салу) юлы белән алына. Очраклы аралап алуны уздыру процедурасы Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнә. Шобага салуны уздырганда һәм имзалар кәгазьләрен тикшергәндә инициатив төркемнең вәкаләтле вәкилләре катнашырга хокуклы. Очраклы аралап алуны (шобага салуны) уздыру процедурасы Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнә. Шобага салу инициатив төркемнең вәкаләтле вәкиленә имзалар кәгазьләрен кабул итеп алуны раслый торган документ тапшырылганнан соң Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең үзендә башкарыла. Тикшерү өчен аралап алынган барлык сайлаучылар имзалары һәм имзалар кәгазьләрендә шуларга туры килә торган сайлаучылар турындагы белешмәләр тикшерелергә тиеш.

6. Тикшерү нәтиҗәләре буенча сайлаучы имзасы дөрес йә дөрес түгел һәм (яисә) гамәлгә яраксыз дип танылырга мөмкин.

7. Әгәр сайлаучылар имзаларын тикшергәндә бер үк сайлаучының берничә имзасы барлыгы ачыкланса, бер генә имза дөрес дип таныла, ә калган имзалар гамәлгә яраксыз дип санала.

8. Бер зат исеменнән бүтән зат куйган имза әлеге статьяның 2 өлеше нигезендә сайлаучылар имзаларын тикшерү буенча эшкә җәлеп ителгән экспертның язма бәяләмәсе нигезендә дөрес түгел дип таныла.

9. Түбәндәге имзалар гамәлгә яраксыз дип таныла:

1) имзалар җыю чорыннан тыш, шул исәптән имзалар кәгазьләрен әзерләү өчен түләү көненә кадәр җыелган сайлаучылар имзалары;

2) Россия Федерациясе гражданнары булмаган затларның, яшәү урыннары Россия Федерациясе территориясендә урнашмаган затларның, имза куйган көнгә 18 яшь тулмаган затларның, суд тарафыннан хокуктан файдалануга сәләтсез дип танылган

затларның яисә суд карары белән иректән мәхрүм итү урыннарындагы затларның имзалары;

3) имзалар кәгазендә дөреслеккә туры килми торган белешмәләр күрсәткән сайлаучыларның имзалары. Бу очракта имза бары тик Россия Федерациясе чикләрендә тору урыны һәм яшәү урыны буенча Россия Федерациясе гражданнарын теркәүне гамәлгә ашыручы органның рәсми белешмәсе булганда йә әлеге статьяның 2 өлеше нигезендә имзалар тикшерү эшенә җәлеп ителгән эксперт бәяләмәсе булганда гына гамәлгә яраксыз дип танылырга мөмкин;

4) әлеге Закон нигезендә таләп ителә торган белешмәләрнең кайберләрен күрсәтмәгән һәм (яисә) имзалар кәгазендә сайлаучы куйган дата шәхсән аның тарафыннан күрсәтелмәгән сайлаучыларның имзалары;

5) имзалар кәгазенә белешмәләр кулдан язып кертелмәгән яисә карандаш белән кертелгән сайлаучыларның имзалары;

6) имзалар кәгазендәге имзаларның куелу датасына алдан махсус искәртмичә төзәтмәләр керткән сайлаучылар имзалары, шулай ук имзаларның куелу датасын шәхсән үзләре төзәтмәгән сайлаучыларның имзалары – әлеге статьяның 7 өлеше нигезендә тикшерүгә җәлеп ителгән экспертның язма бәяләмәсе нигезендә;

7) сайлаучылар турындагы тиешле белешмәләргә төзәтмәләр керткән сайлаучыларның имзалары, әгәр бу төзәтмәләр сайлаучылар белән яисә имзалар җыюны гамәлгә ашыручы зат белән махсус килештерелмәгән булса;

8) әгәр имзалар кәгазе имзалар җыюны гамәлгә ашырган затның, инициатив төркемнең вәкаләтле вәкиленең шәхсән үз имзалары белән таныкланмаган булса, йә бу имзаларның берәрсе дөрес булмаса, йә имзалар кәгазе имзалар җыю вакытына 18 яше тулмаган имзалар җыюны гамәлгә ашыручы зат тарафыннан танылган булса һәм (яисә) күрсәтелгән зат суд тарафыннан хокуктан файдаланурга сәләтсез дип танылган булса, йә имзалар кәгазен таныклау даталарының берәрсе күрсәтелмәгән булса яисә шәхсән үз кулы белән язылмаган булса, йә имзалар җыюны башкарган зат турындагы белешмәләрдә һәм (яисә) имзалар җыюны гамәлгә ашыручы зат, инициатив төркемнең вәкаләтле вәкиле куйган имзаның датасында имзалар җыюны гамәлгә ашыручы тиешле зат белән, инициатив төркемнең вәкаләтле вәкиле белән алдан махсус килештерелмичә кертелгән төзәтмәләр булса, йә имзалар җыюны гамәлгә ашырган зат турындагы, чакыртып алу буенча тавыш бирүне уздыруның инициатив төркеменең вәкаләтле вәкиле турындагы белешмәләр имзалар кәгазендә тулысынча

күрсәтелмәгән яисә дөреслеккә туры килми торган булса, йә имзалар җыюны гамәлгә ашыручы зат турындагы белешмәләр аның шәхсән үзе тарафыннан кертелмәгән булса, имзалар кәгазендәге барлык сайлаучыларның имзалары;

9) рәвеше әлеге Законга беренче кушымтага туры килми торган, һәм (яисә) әлеге Законның 10 статьясындагы 7 өлешендә каралган таләпләр үтәлмәгән килеш, һәм (яисә) әлеге Законның 10 статьясындагы 8 өлешендә каралган белешмәләр кертелмәгән имзалар кәгазендәге сайлаучыларның барлык имзалары;

10) әлеге Законның 10 статьясындагы 5 өлешендә каралган таләпләрне бозып җыелган сайлаучылар имзалары;

11) имзалар кәгазенә кул куйган сайлаучылар турындагы белешмәләрне алар үзләре һәм шушы имзалар кәгазенә кертелгән имзаларны җыюны гамәлгә ашыручы зат шәхсән үзе кертмәгән булса, шул сайлаучыларның имзалары – әлеге статьяның 2 өлеше нигезендә имзалар тикшерү эшенә җәлеп ителгән экспертның язма бәяләмәсе нигезендә;

12) имзалар җыюны гамәлгә ашыручы зат, инициатив төркемнең вәкаләтле вәкиле тарафыннан имзалар кәгазе таныкланган көннән соң имзалар кәгазенә имзалары кертелгән сайлаучыларның имзалары;

13) әгәр имзалар җыюны гамәлгә ашыручы затның таныклау язмасы чакыртып алу буенча тавыш бирүне уздыруның инициатив төркеменең вәкаләтле вәкиленең таныклау язмасы кертелгәннән соң кертелгән булса, имзалар кәгазендәге сайлаучыларның барлык имзалары.

10. Чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның имзаларына тикшерү үткәргәндә, шул исәптән тикшерү өчен имзаларны аралап алганда, чакыртып алу буенча тавыш бирүне билгеләү өчен кирәкле санда чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар имзаларын тапшырган инициатив төркемнең вәкаләтле вәкилләре катнашырга хокуклы. Тиешле тикшерү, аның вакыты һәм үткәрү урыны турында чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар турында Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе инициатив төркемнең вәкаләтле вәкилләренә мәгълүмат бирергә тиеш.

11. Имзалар кәгазендәге сайлаучы турында белешмәләрдәге сүзләрне һәм даталарны шушы белешмәләрне бер мәгънәдә генә кабул итү өчен тоткарлык тудырмаслык итеп кыскарту сайлаучының имзасын гамәлгә яраксыз дип тану өчен нигез була алмый. Чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучы имзасының дөреслеген сораштыру ысулы белән билгеләү тыела.

12. Имзалар кәгазендә булган, әмма имзалар кәгазьләрен таныклаучы затлар тарафыннан төшереп калдырылган (сызылган) сайлаучылар имзалары һәм шуларга туры килә торган сайлаучы турында белешмәләр, әгәр бу Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан имзалар кәгазьләре кабул ителгәнче имзалар кәгазендә яисә имзалар җыю йомгаклары турындагы беркетмәдә махсус килештерелгән булса, тикшерелми һәм исәпкә алынмый.

13. Имзалар кәгазендә әлеге Законда каралган таләпләргә туры килми торган итеп тутырылган юл (юллар) ачыкланганда, әлеге статьяның 9 өлешендәге 8, 9 һәм 13 пунктларында каралган очраклардан тыш, шушы юлдагы (юллардагы) имза гына исәпкә алынмый.

14. Имзалар кәгазен төзегәндә сайлаучы яисә имзалар кәгазен таныклаучы зат тарафыннан махсус килештерелгән төзәтмәләр һәм төзәтелгән урыннар сайлаучы имзасын гамәлгә яраксыз дип тану өчен нигез була алмый, әгәр аның дөрес булмавы яисә гамәлгә яраксызлыгы әлеге статьяның 9 өлешендәге 8, 9 һәм 13 пунктлары нигезендә билгеләнмәгән булса.

15. Имзалар кәгазьләрен тикшерү тәмамлангач, йомгаклау беркетмәсе төзелә, анда игълан ителгән имзаларның саны, тапшырылган имзаларның саны һәм чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның тикшерелгән имзалары саны, шулай ук дөрес түгел һәм (яисә) гамәлгә яраксыз дип танылган имзаларның, аларны шулай дип тануның нигезләрен (сәбәпләрен) күрсәтеп, саны күрсәтелә.

16. Әгәр Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан уздырылган имзалар кәгазьләрен тикшерү әлеге статьяның 9 өлешендәге 3 пунктында каралган нәтиҗәләргә китерсә, шулай ук сайлаучыларның дөрес имзаларының саны чакыртып алу буенча тавыш бирүне билгеләү өчен җитәрлек булмаса йә дөрес булмаган һәм (яисә) гамәлгә яраксыз имзаларның саны тикшерү өчен аралап алынган имзаларның гомуми санынннан 10 процент һәм аннан күбрәк булса, инициатив төркемнең вәкаләтле вәкиле Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясендә йомгаклау беркетмәсенең күчермәсе белән бергә имзалар кәгазьләрен тикшерү ведомостьларының таныкланган күчермәләрен алырга хокуклы, аларда чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның имзаларын дөрес түгел дип тану һәм (яисә) гамәлгә яраксыз дип тану нигезләре (сәбәпләре), папканың, имзалар кәгазенең номерлары һәм һәр шундый имза булган имзалар кәгазендәге юллар күрсәтелә, шулай ук тиешле имзаларны дөрес

түгел һәм (яисә) гамәлгә яраксыз дип тану өчен нигез булган рәсми документларның күчермәләрен алырга хокуклы.

17. Йомгаклау беркетмәсе Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең чакыртып алу буенча тавыш бирүне уздыру инициативасын күрсәтү нәтиҗәләре турындагы карарына өстәлеп куела. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан шундый карар кабул ителгәннән соң беркетмәгә үзгәрешләр кертү рөхсәт ителми. Йомгаклау беркетмәсенең күчермәсе инициатив төркемнең вәкаләтле вәкиленә Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең чакыртып алу буенча тавыш бирүне уздыру инициативасын күрсәтү нәтиҗәләре турындагы мәсьәлә каралырга тиешле утырышына кадәр ике тәүлектән дә соңга калмыйча тапшырыла.

13 статья. **Чакыртып алу буенча тавыш бирүне уздыру инициативасын күрсәтү нәтиҗәләре турында Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан карар кабул итү**

1. Әлеге Законның 12 статьясы нигезендә уздырылган тикшерү йомгаклары буенча Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе чакыртып алу буенча тавыш бирүне уздыру инициативасын күрсәтү нәтиҗәләре турында карар кабул итә. Чакыртып алынучы затка һәм инициатив төркемгә Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан имзаларны тикшерү нәтиҗәләре һәм чакыртып алу буенча тавыш бирүне уздыру инициативасын күрсәтү нәтиҗәләре турындагы мәсьәләләр каралачак утырышын уздыру датасы, урыны һәм вакыты турында вакытында хәбәр ителергә тиеш.

2. Чакыртып алу буенча тавыш бирүне уздырудан баш тарту нигезләре түбәндәгеләр була:

1) чакыртып алу буенча тавыш бирүне билгеләү өчен тапшырылган документлар арасында чакыртып алу буенча тавыш бирүне билгеләү өчен әлеге Закон нигезендә кирәкле документлар булмау;

2) чакыртып алу буенча тавыш бирүне билгеләү өчен тапшырылган имзалар арасында әлеге Закон нигезендә имзалар җыю тыелган урыннарда җыелган имзаларның саны 10 проценттан күбрәк булу;

3) чакыртып алу буенча тавыш бирүне билгеләү өчен тапшырылган дөрес имзаларның саны җитәрлек булмау йә тикшерү өчен аралап алынган имзаларның гомуми саныннан дөрес булма-

ган һәм (яисә) гамәлгә яраксыз имзаларның саны 10 проценттан һәм аннан күбрәк булуы ачыклану;

4) инициатив төркем тарафыннан чакыртып алу буенча тавыш бирү фонды төзелмәү. Чакыртып алу буенча тавыш бирү фондында акчаларның булмавы чакыртып алу буенча тавыш бирүне уздырудан баш тарту өчен нигез була алмый;

5) чакыртып алу буенча тавыш бирүне уздыру инициативасын күрсәтү, имзалар җыюны оештыру буенча үз эшчәнлеген, шулай ук чакыртып алу буенча тавыш бирүнең билгеле бер нәтиҗәсенә ирешүгә юнәлдерелгән эшчәнлекне финанслаганда, чакыртып алу буенча тавыш бирү фонды акчаларыннан тыш, инициатив төркем тарафыннан чакыртып алу буенча тавыш бирү фонды акчаларын тотуның әлеге Законда билгеләнгән иң чик күләменнән 5 проценттан артыграк башка акчаларны тоту;

6) чакыртып алу буенча тавыш бирүне уздыру инициативасын күрсәтү, имзалар җыюны оештыру буенча үз эшчәнлеген, шулай ук чакыртып алу буенча тавыш бирүнең билгеле бер нәтиҗәсенә ирешүгә юнәлдерелгән эшчәнлекне финанслаганда, инициатив төркем тарафыннан чакыртып алу буенча тавыш бирү фонды акчаларын тотуның әлеге Законда билгеләнгән иң чик күләмен 5 проценттан арттырып җибәрү;

7) «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 56 статьясындагы 1 яисә $1^1$ пунктында каралган чикләүләрнең инициатив төркем тарафыннан үтәлмәү факты суд карары белән билгеләнү;

8) инициатив төркем әгъзасының яисә вәкаләтле вәкиленең үз вазыйфаи яисә хезмәт урыны өстенлекләреннән берничә мәртәбә файдалануы.

3. Чакыртып алу комиссиясе тарафыннан чакыртып алу буенча тавыш бирүне уздыру инициативасын карау һәм аның тарафыннан карар кабул итү срогы чакыртып алу инициаторлары тарафыннан чакыртып алу комиссиясенә барлык кирәкле документлар, шул исәптән имзалар кәгазьләре тапшырылган көннән башлап 15 көннән артмаска тиеш.

4. Әгәр сайлаучыларның дөрес имзалары саны чакыртып алу буенча тавыш бирүне билгеләү өчен җитәрлек булса һәм шул ук вакытта дөрес булмаган һәм (яисә) гамәлгә яраксыз имзаларның саны тикшерү өчен аралап алынган имзаларның гомуми санынnан 10 проценттан да кимрәк булса, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе аны чакыртып алу буенча тавыш бирүне уздыру инициативасын күрсәтү нәтиҗәләре турындагы үз карарында

күрсәтә. Әлеге статьяның 3 өлешендә күрсәтелгән срокта Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе имзалар кәгазьләрен, беркетмә нөсхәсен һәм үз карарының күчермәсен Татарстан Республикасы Дәүләт Советына җибәрә. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе карарының күчермәсе шулай ук чакыртып алынучы затка һәм инициатив төркемгә җибәрелә.

5. Чакыртып алу буенча тавыш бирүне уздырудан баш тарткан очракта Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе чакыртып алу буенча тавыш бирүне уздыру инициативасын күрсәтү нәтиҗәләре турында үз карарын кабул иткән мизгелдән бер тәүлек эчендә инициатив төркемнең вәкаләтле вәкиленә, баш тартуның нигезләрен бәян итеп, тиешле карар күчермәсен тапшырырга тиеш. Әгәр сайлаучыларның дөрес имзалары саны чакыртып алу буенча тавыш бирүне билгеләү өчен җитәрлек булмаса йә дөрес булмаган һәм (яисә) гамәлгә яраксыз имзаларның саны тикшерү өчен аралап алынган имзаларның гомуми саныннан 10 процент һәм аннан күбрәк тәшкил итсә, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе аны чакыртып алу буенча тавыш бирүне уздыру инициативасын күрсәтү нәтиҗәләре турындагы үз карарында күрсәтә. Мондый карар кабул ителгәннән соң чакыртып алу буенча тавыш бирүне уздыру инициативасын гамәлгә ашыру процедуралары туктатыла. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе карарының күчермәсе шулай ук чакыртып алынган затка һәм инициатив төркемгә җибәрелә.

6. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең әлеге статьяның 4 йә 5 өлеше нигезендә кабул ителгән карары күчермәләре ул кабул ителгән көннән башлап өч көннән дә соңга калмыйча массакүләм мәгълүмат чараларына тапшырыла, шулай ук «Интернет» гомуми файдаланудагы мәгълүмат- телекоммуникация челтәрендә урнаштырыла.

7. Инициатив төркем әлеге статьяның 6 өлешендә күрсәтелгән карар күчермәсен алганнан соң бу карарга карата «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 75 статьясында билгеләнгән тәртиптә шикаять белдерергә хокуклы.

8. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан чакыртып алу буенча тавыш бирүдән баш тарту турында карар кабул ителгән очракта, тиешле инициатив төркем әгъзалары бу карар кабул ителгән көннән ике ел эчендә Татарстан Республикасы Президенты вазыйфасын биләүче шул ук затны чакыртып

алу буенча тавыш бирүне уздыру инициативасы белән кабат чыга алмый.

4 бүлек. **Чакыртып алу буенча тавыш бирүне билгеләү**

14 статья. **Чакыртып алу буенча тавыш бирүне билгеләү**

1. Чакыртып алу буенча тавыш бирүне билгеләү турындагы карар Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан кабул ителә.

2. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы чакыртып алу буенча тавыш бирүне билгеләү турында йә мондый тавыш бирүне билгеләүдән баш тарту турындагы карарны Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясеннән чакыртып алу буенча тавыш бирүне билгеләү өчен кирәкле документлар кергән көннән 15 көн эчендә кабул итә.

3. Татарстан Республикасы Дәүләт Советы Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясеннән чакыртып алу буенча тавыш бирүне билгеләү өчен кирәкле документлар кергән көннән башлап өч көннән дә соңга калмыйча бу хакта Россия Федерациясе Президентына хәбәр итә.

4. Чакыртып алу буенча тавыш бирү, әлеге Законның 8 статьясында каралган чакыртып алу нигезләренең кимендә берсе, кирәк санда дөрес һәм (яисә) гамәлгә яраклы имзалар булганда, шулай ук чакыртып алу буенча тавыш бирүне уздыру инициативасын күрсәтү процедурасы һәм тапшырылган документлар әлеге Закон таләпләренә туры килгәндә, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан билгеләнә. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе чакыртып алу буенча тавыш бирүне уздыру инициативасын Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан карау нәтиҗәләре турында чакыртып алынучы затка һәм инициатив төркемгә хәбәр итәргә тиеш.

5. Чакыртып алу буенча тавыш бирү Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан чакыртып алу буенча тавыш бирүне билгеләү турында карар кабул ителгән көннән башлап 60 көннән дә соңга калмыйча уздырылырга тиеш.

6. Чакыртып алу буенча тавыш бирү бары тик ял көненә генә билгеләнергә мөмкин. Чакыртып алу буенча тавыш бирүне бәйрәм алды көненә һәм эш көне булмаган бәйрәм көненә, эш көне булмаган бәйрәм көненең иртәгесенә, шулай ук билгеләнгән тәртиптә эш көне дип игълан ителгән ял көненә билгеләү рөхсәт ителми.

7. Чакыртып алу буенча тавыш бирүне билгеләү турындагы карар кабул ителгән көннән биш көннән дә соңга калмыйча массакүләм мәгълүмат чараларында рәсми бастырып чыгарылырга тиеш.

8. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе Татарстан Республикасы Президентына һәм аны чакыртып алу инициаторларына чакыртып алу буенча тавыш бирүне уздыру инициативасын Татарстан Республикасы Дәүләт Советы тарафыннан карау нәтиҗәләре турында хәбәр итәргә тиеш.

15 статья. **Чакыртып алуны билгеләүне һәм уздыруны юкка чыгара торган шартлар**

1. Чакыртып алу түбәндәге очракларда билгеләнми һәм уздырылмый:

1) Россия Федерациясе территориясендә йә Татарстан Республикасы территориясендә кертелгән хәрби яисә гадәттән тыш хәл шартларында, шулай ук хәрби яисә гадәттән тыш хәл бетерелгәннән соң өч ай эчендә;

2) Татарстан Республикасы Президентының вәкаләтләре «Россия Федерациясе субъектлары дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнарын оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 19 статьясында каралган башка нигезләр буенча вакытыннан алда туктатылган очракта.

2. Чакыртып алу буенча тавыш бирүне билгеләү турындагы карар рәсми басылып чыккан көннән чакыртып алу буенча тавыш бирү нәтиҗәләре рәсми басылып чыккан көнгә кадәрге чорда чакыртып алу буенча тавыш бирү билгеләнгән нигез (нигезләр) буенча чакыртып алу инициативасы күрсәтелә алмый.

3. Әгәр тавыш бирү нәтиҗәләре буенча Татарстан Республикасы Президенты чакыртып алынмаса, чакыртып алу буенча тавыш бирү нәтиҗәләре рәсми басылып чыккан көннән ике ел эчендә шул ук нигезләр буенча кабат чакыртып алу уздырылмый.

5 бүлек. **Чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның башка төркемнәре**

16 статья. **Чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның башка төркемнәре**

1. Чакыртып алу мәсьәләләре буенча агитацияне гамәлгә ашыру өчен инициатив төркем теркәлгәннән соң, әмма чакыртып алу буенча тавыш бирү көненә кадәр 40 көннән дә соңга калмый-

ча, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның башка төркемнәре төзелергә һәм Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясендә теркәлергә мөмкин.

2. Чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның башка төркеменә кимендә 20 сайлаучы (чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучы) керергә тиеш.

3. Сайлаучы (чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучы) чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның бары тик бер генә башка төркеменә керергә мөмкин. Инициатив төркемгә керә торган сайлаучы (чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучы) чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның башка төркеменә керә алмый.

4. Чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның башка төркемен төзү турындагы карар чакыртып алынучы зат, сәяси партия, аның региональ бүлекчәсе, сайлаучылар (чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар) тарафыннан кабул ителергә мөмкин.

5. Сәяси партия, аның региональ бүлекчәсе тарафыннан чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның башка төркемен төзү турындагы карар сәяси партия съездында, сәяси партиянең региональ бүлекчәсе конференциясендә (гомуми җыелышында) кабул ителә, шул ук вакытта сәяси партия съездында, сәяси партиянең региональ бүлекчәсе конференциясендә (гомуми җыелышында) чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның башка төркеменең персональ составы билгеләнә.

6. Чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның башка төркемен төзү турында карар сайлаучылар (чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар) тарафыннан кимендә 100 сайлаучы (чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучы) катнашырга тиеш булган җыелышта кабул ителә, бу чакта җыелышта чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның башка төркеменең персональ составы билгеләнә.

7. Әлеге статьяның 5 һәм 6 өлешләрендә күрсәтелгән сәяси партия съездында, сәяси партиянең региональ бүлекчәсе конференциясендә (гомуми җыелышында), сайлаучылар (чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар) җыелышында чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның башка төркеменең финанс мәсьәләләре буенча вәкаләтле вәкилләре, шулай ук бүтән мәсьәләләр буенча күрсәтелгән төркем исеменнән эш итәргә вәкаләтле затлар билгеләнеп куелырга тиеш.

8. Чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның чакыртып алынучы зат тарафыннан төзелгән башка төркемен теркәү өчен чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның башка төркеменең вәкаләтле вәкиле Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенә чакыртып алынучы затның чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның башка төркемен төзү турында, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның башка төркемен төзү максаты һәм аның персональ составы, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның башка төркеме әгъзаларыннан чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларың башка төркеме исеменнән эш итәргә вәкаләтле затлары – чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларың башка төркеменең вәкаләтле вәкилләре, шул исәптән финанс мәсьәләләре буенча вәкилләре, күрсәтелгән һәм чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларың башка төркеменең бер яисә берничә вәкаләтле вәкиленә төркем исеменнән ышанычнамәләр тапшыру хокукын бирү турында карарының билгеләнгән тәртиптә таныкланган күчермәсен тапшыра.

9. Чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның сәяси партия, аның региональ бүлекчәсе тарафыннан төзелгән башка төркемен теркәү өчен чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның башка төркеменең вәкаләтле вәкиле Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенә сәяси партия съездының, сәяси партиянең региональ бүлекчәсе конференциясенең (гомуми җыелышының) чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның башка төркемен төзү турында һәм аны төзүнең максаты күрсәтелгән карарын, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның башка төркеме әгъзаларыннан чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларың башка төркеме исеменнән эш итәргә вәкаләтле затларын – чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларың башка төркеменең вәкаләтле вәкилләрен, шул исәптән финанс мәсьәләләре буенча, билгеләп кую турында һәм чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларың башка төркеменең бер яисә берничә вәкаләтле вәкиленә төркем исеменнән ышанычнамәләр тапшыру хокукын бирү турында карарларны үз эченә ала торган беркетмәсен (беркетмәсеннән өземтәсен) тапшыра.

10. Чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның сайлаучылар (чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар) тарафыннан төзелгән башка төркемен теркәү өчен аның вәкаләтле вәкиле Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенә чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның башка

төркемен төзү турындагы карарны үз эченә ала торган, аны төзү максаты күрсәтелгән сайлаучылар (чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар) җыелышы беркетмәсен, шулай ук күрсәтелгән җыелышта катнашучыларны теркәү беркетмәсен, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның башка төркеме әгъзалары арасыннан чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның башка төркеме исеменнән эш итәргә вәкаләтле затларын – чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның башка төркеменең вәкаләтле вәкилләрен, шул исәптән финанс мәсьәләләре буенча, билгеләп кую һәм чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның башка төркеменең бер яисә берничә вәкаләтле вәкиленә төркем исеменнән ышанычнамәләр тапшыру хокукын бирү турында карарлар тапшыра.

11. Чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның башка төркемен теркәү өчен аның вәкаләтле вәкиле әлеге статьяның 8, 9 яисә 10 өлешләрендә күрсәтелгән документлар белән бергә шулай ук Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенә түбәндәгеләрне тапшыра:

1) чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның башка төркемен теркәү турында чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның башка төркеменең барлык әгъзалары тарафыннан имзаланган үтенечнамәне. Чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның башка төркеме үтенечнамәсендә шулай ук чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның башка төркеменең һәр әгъзасының һәм аның исеменнән эш итәргә вәкаләтле затларның – чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның башка төркеменең вәкаләтле вәкилләренең, шул исәптән финанс мәсьәләләре буенча, фамилиясе, исеме, атасының исеме, туу датасы һәм урыны, паспортының яисә гражданин паспортын алыштыра торган документының сериясе, номеры һәм бирелү датасы, аны биргән органның исеме яисә коды, шулай ук яшәү урыны адресы күрсәтелергә тиеш. Чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның башка төркеме әгъзаларының имзалары нотариаль таныкланган булырга тиеш;

2) чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның башка төркеменең финанс мәсьәләләре буенча вәкаләтле вәкилләренә рәсмиләштерелгән нотариаль таныкланган ышанычнамәләрне һәм финанс мәсьәләләре буенча вәкаләтле вәкилләр булырга ризалык бирү турында шушы затларның гаризаларын.

12. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның башка төркемен теркәү турындагы үтенечнамә һәм әлеге статьяның 8 –

11 өлешләрендә күрсәтелгән башка документлар кергән көннән башлап биш көннән дә соңга калмыйча чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның башка төркемен теркәү турында, шулай ук аның вәкаләтле вәкилләрен теркәү турында карар кабул итә һәм аңа теркәү таныклыгын тапшыра йә чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның башка төркемен теркәүдән баш тарту турында карар кабул итә. Кабул ителгән карар турында Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе чакыртып алынучы затка һәм инициатив төркемгә язма рәвештә хәбәр итә.

13. Әлеге Законның инициатив төркемнең аны, аның әгъзаларын һәм вәкаләтләрен теркәгәннән соңгы эшчәнлеген җайга сала торган нигезләмәләре чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның башка төркемнәренә, аларның әгъзаларына һәм вәкаләтле вәкилләренә кагыла.

## 6 бүлек. **Чакыртып алу буенча тавыш бирүне әзерләүне һәм уздыруны гамәлгә ашыручы комиссияләр**

### 17 статья. **Чакыртып алу буенча тавыш бирүне әзерләүне һәм уздыруны гамәлгә ашыручы комиссияләрнең системасы һәм статусы**

1. Чакыртып алу буенча тавыш бирүне әзерләүне һәм уздыруны түбәндәгеләр гамәлгә ашыра:

чакыртып алу буенча Үзәк комиссия буларак эш итүче Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе;

чакыртып алу буенча комиссияләр буларак эш итүче территория (район, шәһәр, шәһәрләрдәге район) сайлау комиссияләре (алга таба шулай ук –территория комиссияләре);

чакыртып алу буенча участок комиссияләре (алга таба шулай ук – участок комиссияләре).

2. Чакыртып алу комиссияләре чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашу хокукын гамәлгә ашыруны һәм яклауны тәэмин итәләр, чакыртып алу буенча тавыш бирүне әзерләүне һәм уздыруны гамәлгә ашыралар.

3. Комиссияләрнең вәкаләтләре һәм эшчәнлек тәртибе «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон, Татарстан Республикасы Конституциясе, әлеге Закон, Татарстан Республикасы Сайлау кодексы белән билгеләнә.

4. Югарырак комиссиянең үз компетенциясе чикләрендә кабул иткән карарларын түбәнгерәк комиссияләр өчен үтәү мәҗбүри.

5. Комиссияләр чакыртып алу кампаниясе чорында законны чакыртып алу буенча тавыш бирүне әзерләүгә һәм уздыруга кагылышлы өлешендәге бозулар турында үзләренә кергән мөрәҗәгатьләрне үз компетенциясе чикләрендә карарга, шул мөрәҗәгатьләр буенча тикшерү үткәрергә һәм мөрәҗәгатьләрне җибәргән затларга биш көн эчендә, әмма тавыш бирү көненә кадәр кимендә бер көн кала, ә тавыш бирү көнендә яисә тавыш бирү көненең иртәгесендә кергән мөрәҗәгатьләр буенча кичекмәстән язма җаваплар бирергә тиеш. Әгәр күрсәтелгән мөрәҗәгатьләрдәге фактлар өстәмә тикшерүне таләп итсә, алар буенча карарлар 10 көннән дә соңга калмыйча кабул ителә. Әгәр мөрәҗәгатьтә инициатив төркем, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның башка төркемнәре тарафыннан законны чакыртып алу буенча тавыш бирүне әзерләүгә һәм уздыруга кагылышлы өлешендә бозу фактлары булса, инициатив төркемгә, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның башка төркеменә шундый мөрәҗәгать керү турында кичекмәстән хәбәр ителергә тиеш. Чакыртып алынучы зат, инициатив төркем, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның башка төркеме яисә аларның вәкаләтле вәкилләре мөрәҗәгатьнең асылы буенча аңлатмалар бирергә хокуклы.

6. Инициатив төркем, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның башка төркемнәре тарафыннан «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон, әлеге Закон бозылган очракта, комиссия шушы инициатив төркемгә, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның башка төркеменә кисәтү чыгарырга хокуклы, ул массакүләм мәгълүмат чаралары аша йә башка ысул белән чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларга җиткерелә.

7. Комиссия, шул исәптән әлеге статьяның 5 өлешендә күрсәтелгән мөрәҗәгатьләргә бәйле рәвештә дә, тиешле тикшерүләр үткәрү турындагы һәм федераль законнарны, әлеге Законны чакыртып алу буенча тавыш бирүне әзерләүне һәм уздыруны җайга салу өлешендә бозуларга чик кую турындагы күрсәтмәләр белән хокук саклау органнарына, башкарма хакимият органнарына мөрәҗәгать итәргә хокуклы, алар «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон нигезендә биш көн эчендә бу хокук бозуларга чик кую буенча законда билгеләнгән чараларны күрергә, күрсәтмә тавыш бирү көненә кадәр биш көн кала һәм аннан азрак көн кала алынса – тавыш бирү көне алдындагы көннән дә соңга калмыйча, ә күрсәтмә тавыш бирү көненә кадәрге көндә,

тавыш бирү көнендә һәм тавыш бирү көненең иртәгесендә алынса, чараларны кичекмәстән күрергә тиеш. Мондый чакта күрсәтелгән органнар мөрәҗәгать иткән комиссиягә кичекмәстән хәбәр итәләр. Әгәр күрсәтмәдәге фактлар өстәмә тикшерүне таләп итсә, күрсәтелгән чаралар 10 көннән дә соңга калмыйча күрелә.

8. Комиссияләр сайлаучыларга (чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларга) чакыртып алу гамәлләрен башкару сроклары һәм тәртибе турында, инициатив төркем, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның башка төркемнәре, чакыртып алу кампаниясенең барышы турында мәгълүмат бирүне тәэмин итәләр.

9. Комиссиянең законга каршы килә торган йә үз компетенциясе чикләрен арттырып кабул ителгән карары югарырак комиссия яисә суд тарафыннан юкка чыгарылырга тиеш. Мондый чакта югарырак комиссия мәсьәләнең асылы буенча карар кабул итәргә яисә карары юкка чыгарылган түбәнгерәк комиссиягә кабат карау өчен тиешле материаллар җибәрергә хокуклы. Әгәр түбәнгерәк комиссия мәсьәләне кабат карамаса, әлеге мәсьәләнең асылы буенча карарны югарырак комиссия кабул итәргә хокуклы.

10. Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, дәүләт һәм муниципаль учреждениеләр, шулай ук аларның вазыйфаи затлары чакыртып алу комиссияләренә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыруда ярдәм итәргә, аерым алганда, түләүсез нигездә кирәкле биналар бирергә, шул исәптән чакыртып алу буенча тавыш бирү документациясен архивка тапшырганчы йә әлеге Законда билгеләнгән саклау сроклары тәмамлангач юкка чыгарганчы аны саклау өчен, бирелә торган биналарны һәм күрсәтелгән документацияне саклауны тәэмин итәргә, шулай ук түләүсез нигездә транспорт чаралары, элемтә чаралары, техник җайланмалар бирергә тиеш.

11. Устав (җыелма) капиталында Россия Федерациясе, Россия Федерациясе субъектлары һәм (яисә) муниципаль берәмлекләр өлеше (кертеме) чакыртып алу буенча тавыш бирүне билгеләү турындагы карар рәсми басылып чыккан көнгә 30 проценттан артыграк булмаган оешмалар, аларның вазыйфаи затлары комиссияләргә үз вәкаләтләрен гамәлгә ашыруда ярдәм итәргә, аерым алганда, транспорт чаралары, элемтә чаралары, техник җайланмалар, бина бирергә тиеш.

12. Теле- һәм (яисә) радиотапшыруларны гамәлгә ашыручы дәүләт һәм муниципаль оешмалар, дәүләт һәм муниципаль вакытлы матбугат басмалары редакцияләре чакыртып алу комиссияләренә «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Фе-

дераль законда, әлеге Законда Россия Федерациясе субъектының референдум комиссияләренә эфир вакыты бирү өчен билгеләнгән тәртиптә чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларга мәгълүмат бирү өчен түләүсез эфир вакытын һәм комиссияләрнең карарларын бастырып чыгару һәм башка мәгълүмат урнаштыру өчен матбугат мәйданын бирергә тиеш. Мондый чакта телерадиотапшырулар оешмаларының һәм вакытлы матбугат басмалары редакцияләренең чыгымнары бу оешмаларның һәм редакцияләрнең эшчәнлек нәтиҗәләренә кертелә.

13. Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары, иҗтимагый берләшмәләр, барлык милек рәвешләрендәге оешмалар, шул исәптән теле- һәм (яисә) радиотапшыруларны гамәлгә ашыручы оешмалар (алга таба шулай ук – телерадиотапшырулар оешмалары), вакытлы матбугат басмалары редакцияләре, шулай ук күрсәтелгән органнарның һәм оешмаларның вазыйфаи затлары чакыртып алу комиссияләренә кирәкле белешмәләрне һәм материалларны тапшырырга, комиссияләрнең мөрәҗәгатьләренә биш көн эчендә җавап бирергә, әгәр мөрәҗәгать тавыш бирү көненә кадәр биш көн һәм аннан азрак көн кала алынса – тавыш бирү көне алдындагы көннән дә соңга калмыйча, ә мөрәҗәгать тавыш бирү көнендә яисә тавыш биргән көннең иртәгесендә алынса, кичекмәстән җавап бирергә тиеш. Күрсәтелгән белешмәләр һәм материаллар чакыртып алу комиссияләренә түләүсез бирелә.

18 статья. **Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясен төзү тәртибе һәм аның вәкаләтләре**

1. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон, Татарстан Республикасы Конституциясе һәм Татарстан Республикасы Сайлау кодексы нигезендә төзелә.

2. Чакыртып алу буенча тавыш бирүне әзерләгәндә һәм уздырганда Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе:

1) Татарстан Республикасы территориясендә чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашуга гражданнар хокукы үтәлешен тикшереп тора;

2) әлеге Законны куллану мәсьәләләре буенча инструкцияләр һәм башка норматив актлар чыгара;

3) чакыртып алу буенча түбәнгерәк комиссияләрнең эшчәнлегенә җитәкчелек итә, аларга хокукый, методик, оештыру-техник ярдәм күрсәтә;

4) инициатив төркемне, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның башка төркемнәрен терки;

5) чакыртып алу буенча тавыш бирү өчен бюллетень рәвешен һәм текстын, шулай ук чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның исемлегенең һәм чакыртып алу буенча тавыш бирүне әзерләүгә һәм уздыруга бәйле башка документларның рәвешен раслый;

6) чакыртып алу буенча тавыш бирү өчен бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларын әзерләүне тәэмин итә һәм аларны территория комиссияләренә тапшыра;

7) чакыртып алу буенча түбәнгерәк комиссияләрнең мөһерләре үрнәкләрен раслый;

8) чакыртып алу буенча тавыш бирүне әзерләүне һәм уздыруны, чакыртып алу комиссияләренең эшчәнлеген финанс белән тәэмин итүгә Татарстан Республикасы бюджетыннан бүлеп бирелгән чараларны бүлә, әлеге чараларны максатчан файдалануны тикшереп тора;

9) чакыртып алу буенча түбәнгерәк комиссияләрнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләрне (гаризаларны) карый һәм әлеге шикаятьләр (гаризалар) буенча дәлилләнгән карарлар кабул итә;

10) чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларны мондый тавыш бирүне әзерләү һәм уздыру турындагы мәгълүмат белән тәэмин итә;

11) чакыртып алу комиссияләрен биналар, транспорт чаралары һәм элемтә чаралары белән тәэмин итүне тикшереп тора, чакыртып алу буенча тавыш бирүне матди-техник тәэмин итүнең бүтән мәсьәләләрен карый;

12) чакыртып алу буенча тавыш бирүне әзерләүгә һәм уздыруга бәйле мәсьәләләр буенча дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары белән хезмәттәшлек итә;

13) федераль законнарда, әлеге Законда, Татарстан Республикасының башка законнарында билгеләнгән бүтән вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

19 статья. **Территория комиссияләрен төзү тәртибе һәм аларның вәкаләтләре**

1. Территория комиссияләре «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон һәм Татарстан Республикасы Сайлау кодексы нигезендә төзелә.

2. Территория комиссиясе:

1) чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашуга гражданнар хокукы үтәлүне тиешле территориядә тикшереп тора;

2) участок комиссияләрен төзи һәм аларның рәисләрен билгеләп куя;

3) участок комиссияләре эшчәнлеген җайга сала, аларга хокукый, методик, оештыру-техник ярдәм күрсәтә;

4) участок комиссияләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаятьләрне (гаризаларны) карый һәм әлеге шикаятьләр (гаризалар) буенча дәлилләнгән карарлар кабул итә;

5) чакыртып алу буенча агитация уздыруның билгеләнгән тәртибе үтәлүне тиешле территориядә тикшереп тора;

6) чакыртып алу буенча тавыш бирү бюллетеньнәрен һәм чакыртып алу буенча тавыш бирүне әзерләүгә һәм уздыруга бәйле башка документларны илтеп җиткерүне оештыра;

7) чакыртып алу буенча тавыш бирүне әзерләүгә һәм уздыруга бәйле мәсьәләләр буенча дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары белән хезмәттәшлек итә;

8) федераль законнарда, әлеге Законда, Татарстан Республикасының башка законнарында билгеләнгән бүтән вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

20 статья. **Участок комиссияләре төзү тәртибе һәм аларның вәкаләтләре**

1. Участок комиссияләре «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон нигезендә «Татарстан Республикасы референдумы турында» Татарстан Республикасы Законында Татарстан Республикасы референдумы участок комиссияләрен төзү өчен билгеләнгән тәртиптә төзелә.

2. Участок комиссиясе:

1) халыкка участок комиссиясенең адресы һәм телефон номеры, аның эш вакыты, шулай ук тавыш бирү көне, вакыты һәм урыны турында хәбәр итә;

2) тавыш бирүдә катнашучылар исемлеген төгәлләштерә, тавыш бирүдә катнашучыларны әлеге исемлек белән таныштыра, әлеге исемлектәге хаталар һәм төгәлсезлекләр турындагы гаризаларны карый һәм аңа тиешле үзгәрешләрне кертү турындагы мәсьәләләрне хәл итә;

3) тавыш бирү урыннарын, тавыш бирү әрҗәләрен һәм башка җайланмаларны әзерләүне тәэмин итә;

4) тавыш бирү турында тавыш бирүдә катнашучыларга мәгълүмат җиткерүне тәэмин итә;

5) участок территориясендә чакыртып алу буенча агитация уздыруның билгеләнгән тәртибен үтәүне тикшереп тора;

6) бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларын бирә;

7) тавыш бирү көнендә участокта тавыш бирүне оештыра;

8) тавышларны саный, участокта тавыш бирү йомгакларын билгели, тавыш бирү йомгаклары турында беркетмә төзи һәм аны территория комиссиясенә тапшыра;

9) участокта тавыш бирү йомгакларын игълан итә һәм тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәнең таныкланган күчермәләрен тавыш бирүнең барышын күзәтүне гамәлгә ашыручы затларга бирә;

10) әлеге Законны, башка законнарны бозуга карата шикаятьләрне (гаризаларны) үз вәкаләтләре чикләрендә карый һәм әлеге шикаятьләр (гаризалар) буенча дәлилләнгән карарлар кабул итә;

11) чакыртып алу буенча тавыш бирүне әзерләүгә һәм уздыруга бәйле документларны саклауны һәм чакыртып алу буенча югарырак комиссияләргә тапшыруны тәэмин итә;

12) әлеге Закон нигезендә башка вәкаләтләрне гамәлгә ашыра.

21 статья. **Комиссияләр әгъзалары статусы**

Комиссияләрнең хәлиткеч тавыш хокукына ия, шулай ук киңәш бирү тавышы хокукына ия әгъзалары статусы «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 29 статьясы белән билгеләнә.

22 статья. **Комиссияләр эшчәнлегендә хәбәрдарлык**

1. Теләсә кайсы комиссиянең барлык утырышларында, шулай ук тиешле участок комиссиясе, территория комиссиясе тарафыннан чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның исемлекләре, чакыртып алу буенча тавыш бирү бюллетеньнәре, бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары, тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәләр һәм җыелма таблицалар белән эшләгәндә югарырак комиссияләрнең әгъзалары һәм аларның аппаратлары хезмәткәрләре, инициатив төркемнең, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның башка төркемнәренең әгъзалары яисә вәкаләтле вәкилләре катнашырга хокуклы. Тиешле комиссия утырышларында һәм ул алда санап үтелгән документ-

лар белән эшләгәндә катнашу өчен әлеге затларга өстәмә рөхсәт алу таләп ителми. Тиешле комиссия әлеге затларның утырышларга һәм чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар тавышларын саный һәм алда санап үтелгән документлар белән эшли торган урыннарга ирекле керү мөмкинлеген тәэмин итәргә тиеш. Комиссиянең барлык утырышларында һәм ул алда санап үтелгән документлар белән эшләгәндә, шулай ук чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар тавышларын санаганда массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре дә катнашырга хокуклы.

2. Чакыртып алу комиссияләренең чакыртып алу буенча тавыш бирүне әзерләүгә һәм уздыруга турыдан-туры бәйле карарлары дәүләт яисә муниципаль вакытлы матбугат басмаларында бастырып чыгарыла йә чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларга башка юл белән җиткерелә, шулай ук бүтән массакүләм мәгълүмат чараларына закон белән билгеләнгән күләмдә һәм срокларда тапшырыла.

3. Участок комиссиясе тавыш бирү көнендә эш башлаган мизгелдән һәм чакыртып алу буенча югарырак комиссиянең тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәне кабул итеп алуы турындагы хәбәр алынганчы, шулай ук чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар тавышларын кабат санаганда тавыш бирү участокларында әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән затлар, шулай ук күзәтүчеләр, чит ил (халыкара) күзәтүчеләр катнашырга хокуклы.

4. Тиешле комиссия комиссия утырышларын уздыру һәм әлеге статьяның 1 өлешендә санап үтелгән документлар белән эшләү вакыты турында турыдан-туры югарырак комиссиягә, инициатив төркемгә, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның башка төркеменә хәбәр итүне тәэмин итә.

5. Чакыртып алу кампаниясе чорында Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең теләсә кайсы утырышында чакыртып алынучы зат яисә аның вәкиле катнашырга хокуклы. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе чакыртып алынучы затка яисә аның вәкиленә үз утырышларын уздыру вакыты турында хәбәр итүне тәэмин итә.

6. Шикаятьләрне (гаризаларны) караганда комиссияләр утырышларында гариза бирүчеләр, каралучы мәсьәләнең асылы буенча аңлатмалар бирергә һәм дәлилләр тапшырырга мөмкин булган кызыксынучы яклар вәкилләре катнашырга хокуклы. Шикаятьләрне (гаризаларны) караганда комиссияләр утырышларында чакыртып алынучы зат яисә аның вәкиле катнашырга хокуклы.

7. Комиссияләр инициатив төркемне, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның башка төркемнәрен теркәү йомгаклары, чакыртып алу буенча тавыш бирү йомгаклары һәм тавыш бирү нәтиҗәләре турындагы мәгълүматны гражданнарга җиткерә.

8. Күзәтүчеләр, массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре бүтән комиссияләрдә шушы комиссияләр чакыртып алу буенча тавыш бирү йомгакларын, тавыш бирү нәтиҗәләрен билгеләгәндә, тавыш бирү йомгаклары, чакыртып алу буенча тавыш бирү нәтиҗәләре турындагы беркетмәләрне төзегәндә, шулай ук чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар тавышларын кабат санаганда катнашырга хокуклы.

9. Комиссиянең барлык әгъзаларына, әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән бүтән затларга һәм күзәтүчеләргә хәрби частьтә, ябык административ-территориаль берәмлектә, хастаханәдә, шифаханәдә, ял йортында, шик белдерелүчеләрне һәм гаепләнүчеләрне сак астында тота торган урында яисә вакытлыча торуның башка урынында оештырылган чакыртып алу буенча тавыш бирү участогында төзелгән участок комиссиясе урынына, шулай ук шушы участокта тавыш бирү урынына һәм чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның тавышларын санау урынына керү тәэмин ителергә тиеш.

10. Күзәтүчеләрне инициатив төркем, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның һәрбер бүтән төркеме, Россия Федерациясе субъекты дәрәҗәсендә яисә Россия Федерациясе дәрәҗәсендә төзелгән һәм теркәлгән иҗтимагый берләшмә билгеләп куярга хокуклы. Россия Федерациясе гражданы күзәтүче булырга мөмкин. Сайланулы вазыйфаи затлар, депутатлар, җирле администрацияләр башлыклары, аларга турыдан-туры буйсынудагы затлар, судьялар, прокурорлар, комиссияләрнең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзалары күзәтүчеләр була алмый.

11. Күзәтүче вәкаләтләре инициатив төркем, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның бүтән төркеме, әлеге күзәтүче мәнфәгатьләрен чагылдыра торган иҗтимагый берләшмә тарафыннан бирелгән юлламада язма рәвештә таныкланырга тиеш. Юлламада күзәтүченең фамилиясе, исеме, атасының исеме, яшәү урынының адресы, телефон номеры (әгәр булса), чакыртып алу буенча тавыш бирү участогы номеры, ул җибәрелә торган комиссия исеме (территория, участок) күрсәтелә, шулай ук әлеге статьяның 10 өлешендә каралган чикләүләрнең булмавы турында язма ясала. Күзәтүче турында нинди дә булса өстәмә белешмәләр күрсәтү һәм мөһер сугу таләп ителми. Юллама

күзәтүченең шәхесен таныклый торган документ күрсәткәндә генә гамәлгә яраклы була. Күзәтүче җибәрү турында алдан хәбәр итү таләп ителми.

12. Әлеге статьяның 11 өлешендә күрсәтелгән юллама участок комиссиясенә – әлеге статьяның 3 өлешендә каралган чорда, ә бүтән комиссиягә участокларда тавыш бирү башланган мизгелдән алып чакыртып алу буенча тавыш бирү йомгаклары турында, чакыртып алу буенча тавыш бирү нәтиҗәләре турында, шул исәптән чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар тавышларын кабат санау нәтиҗәләре турында, беркетмә төзү эше тәмамланганчы күрсәтелергә мөмкин.

13. Инициатив төркем, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның бүтән төркеме, иҗтимагый берләшмә һәр участок комиссиясенә берничә күзәтүче билгеләп куярга мөмкин, алар тавыш бирүне уздыруны һәм тавыш бирү бинасында чакыртып алу буенча башка гамәлләрне чиратлап күзәтергә хокуклы. Күзәтүче вәкаләтләрен бер үк вакытта комиссия бинасында, тавыш бирү бинасында инициатив төркем, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның бүтән төркеме, иҗтимагый берләшмә мәнфәгатьләрен чагылдыручы ике һәм аннан да күбрәк күзәтүче башкару рөхсәт ителми. Комиссия бинасында, тавыш бирү бинасында күзәтүчеләрнең булуына, тавыш бирүне уздыруны, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар тавышларын санауны, чакыртып алу буенча тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәләрне төзүне күзәтүгә кагылышлы, шулай ук шушы беркетмәләрнең күчермәләрен бирүгә кагылышлы «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законда күрсәтелгәннәрдән бүтәнрәк чикләүләр билгеләү рөхсәт ителми.

14. Күзәтүче түбәндәгеләргә хокуклы:

1) чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлекләре, бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларын бирү реестры, комиссиядәге бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары, тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш бирү турындагы гаризалар (мөрәҗәгатьләр) реестры белән танышырга;

2) чакыртып алу буенча тавыш бирүнең тиешле участогының тавыш бирү бинасында әлеге статьяның 3 өлешендә күрсәтелгән чорда теләсә кайсы вакытта булырга;

3) чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларга чакыртып алу буенча тавыш бирү бюллетеньнәре бирүне күзәтергә;

4) чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш биргәндә катнашырга;

5) чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлекләренә кертелгән чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның санын, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларга бирелгән чакыртып алу буенча тавыш бирү бюллетеньнәрен, файдаланылган бюллетеньнәрне санауны күзәтергә; чакыртып алу буенча тавыш бирү участогында чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның бюллетеньнәрдәге тамгалары күренеп торырлык ераклыкта һәм шартларда чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар тавышларын санауны күзәтергә; чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар тавышларын санаганда тутырылган яисә тутырылмаган теләсә кайсы бюллетень белән танышырга; комиссиянең тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәне һәм әлеге статьяның 3 өлешендә күрсәтелгән чорда башка документларны төзүен күзәтергә;

6) тиешле комиссия рәисенә, ә ул булмаганда – аны алмаштыручы затка тавыш бирүне оештыру мәсьәләләре буенча тәкъдимнәр һәм искәрмәләр белән мөрәҗәгать итәргә;

7) күзәтүче җибәрелгән комиссиянең беркетмәсе белән һәм түбәнгерәк комиссияләрнең чакыртып алу буенча тавыш бирү йомгаклары турындагы, тавыш бирү нәтиҗәләре турындагы беркетмәләре белән һәм беркетмәләргә кушып бирелгән документлар белән танышырга, тиешле комиссиядән күрсәтелгән беркетмәләрнең таныкланган күчермәләрен алырга;

8) үзе җибәрелгән комиссиянең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата турыдан-туры югарырак комиссиягә яисә судка шикаять белдерергә;

9) тиешле комиссияләрдә чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның тавышларын кабат санаганда катнашырга.

15. Күзәтүче түбәндәгеләргә хокуксыз:

1) чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларга чакыртып алу буенча тавыш бирү бюллетеньнәре бирергә;

2) чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучы өчен, шул исәптән аның үтенече буенча, чакыртып алу буенча тавыш бирү бюллетеньнәре алганда имза салырга;

3) чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучы өчен, шул исәптән аның үтенече буенча, чакыртып алу буенча тавыш бирү бюллетеньнәрен тутырырга;

4) тавыш бирү яшеренлеген бозарлык гамәлләр кылырга;

5) комиссиянең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзалары бюллетеньнәрне санаганда турыдан-туры катнашырга;

6) чакыртып алу комиссиясе эшенә комачауларлык гамәлләр кылырга;

7) катнашучылар арасында чакыртып алу мәсьәләләре буенча агитация алып барырга;

8) тиешле комиссия карарлар кабул иткәндә катнашырга.

16. Чакыртып алуны әзерләүне һәм уздыруны мәгълүмати чагылдыруда катнашучы массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре түбәндәгеләргә хокуклы:

1) комиссияләр утырышларында катнашырга;

2) тавыш бирү йомгаклары турында участок комиссиясе беркетмәсе, шулай ук чакыртып алу буенча тавыш бирү йомгаклары турында, тавыш бирү нәтиҗәләре турында башка комиссияләрнең беркетмәләре белән, шул исәптән кабат төзелгәннәре белән дә, танышырга;

3) тиешле комиссиядән әлеге өлешнең 2 пунктында күрсәтелгән беркетмәләрнең һәм аларга кушып бирелгән документларның күчермәләрен алырга;

4) агитация гамәлләрендә катнашырга, аларны үткәрүне массакүләм мәгълүмат чараларында чагылдырырга;

5) тавыш бирү көнендә, алдан тавыш бирү көннәрендә тавыш бирү бинасында булырга, шулай ук фотога һәм видеога төшерүне алып барырга.

17. Комиссия беркетмәләренең һәм бүтән документларының күчермәләре комиссия рәисе, йә аның урынбасары, йә комиссия секретаре тарафыннан таныклана. Бу чакта таныклана торган документта әлеге затлар «Дөрес» яисә «Күчермә дөрес» дигән язма ясый, имза сала, үз фамилиясен һәм инициалларын, таныклау датасын һәм вакытын күрсәтә һәм комиссия мөһерен суга.

18. Чит ил (халыкара) күзәтүчеләре Россия Федерациясенә керүгә Россия Федерациясе субъекты референдумын уздырганда Россия Федерациясенә керүгә рөхсәт алу өчен «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон белән билгеләнгән тәртиптә рөхсәт алалар. Чит ил (халыкара) күзәтүчеләре Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең чакыруы булганда Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан аккредитацияләнәләр. Чит ил (халыкара) күзәтүчеләренең эшчәнлеге «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу

хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон белән билгеләнгән тәртиптә җайга салына.

19. Участок комиссияләрендә чакыртып алу буенча тавыш биргәндә һәм тавышларны санаганда шунда булган комиссияләрнең киңәш бирү тавышы хокукына ия әгъзалары, күзәтүчеләр, массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләре, үзенең статусын, фамилиясен, исемен һәм атасының исемен күрсәтеп, чакыртып алу мәсьәләләре буенча агитация чагылышлары булмаган күкрәк тамгалары йөртергә хокуклы. Иҗтимагый берләшмә тарафыннан билгеләп куелган күзәтүченең күкрәк тамгасында шулай ук әлеге иҗтимагый берләшмәнең атамасы күрсәтелә. Комиссияләрнең киңәш бирү тавышы хокукына ия әгъзаларының, күзәтүчеләрнең күкрәк тамгалары рәвешләре Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнә.

23 статья. **Чакыртып алу комиссияләренең эшчәнлеген оештыру**

Чакыртып алу комиссияләренең эшчәнлеге Россия Федерациясе субъекты референдум комиссияләренең эшчәнлеген оештыру өчен «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 28 статьясы белән билгеләнгән таләпләр нигезендә оештырыла.

7 бүлек. **Чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларны теркәү (исәпкә алу), чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлекләрен төзү, чакыртып алу буенча тавыш бирү участокларын төзү**

24 статья. **Чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларны теркәү (исәпкә алу)**

1. Чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның барысы да теркәлергә (исәпкә алынырга) тиеш.

2. Чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларны теркәү (исәпкә алу) Россия Федерациясе субъекты референдумында катнашучыларны теркәү (исәпкә алу) өчен «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон белән билгеләнгән тәртиптә гамәлгә ашырыла.

3. Чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучы үзе турында документлаштырылган мәгълүматны (шәхси белешмәләрне), шул исәптән машинадан укыла торган саклагычларда-

гы мәгълүматны, тоткарлыксыз алырга, мондый мәгълүматның тулылыгын һәм дөреслеген тәэмин итү максатларында аны төгәлләштерергә хокуклы, шулай ук бу мәгълүматны кем һәм нинди максатларда куллануны яисә кулланганны, аны кем кемгә тапшырганны белергә хокуклы.

25 статья. **Чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның исемлекләрен төзү**

1. Чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның хокукларын гамәлгә ашыру максатларында, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларны теркәүнең (исәпкә алуның) дәүләт системасыннан файдаланып алынган һәм әлеге статьяның 4 өлеше нигезендә тапшырыла торган белешмәләр нигезендә чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлекләре тиешле территория комиссияләре тарафыннан төзелә.

2. Тавыш бирү участокларында чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлекләренә тавыш бирү көненә чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашу хокукына ия булган гражданнар кертелә.

3. Конкрет тавыш бирү участогында чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегенә гражданны кертү өчен нигез әлеге участок территориясендә аның яшәү урыны булу факты, законнарда каралган очракларда – әлеге участок территориясендә аның вакытлыча тору урыны булу факты (гражданның чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашу хокукы булганда) йә бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары булудан гыйбарәт. Чакыртып алу буенча тавыш бирүнең билгеле бер участогы территориясендә гражданның яшәү урыны булу йә аның вакытлыча тору урыны булу факты Россия Федерациясе чикләрендә тору урыны һәм яшәү урыны буенча Россия Федерациясе гражданнарын теркәп исәпкә алу органнары тарафыннан Россия Федерациясе законнары нигезендә билгеләнә.

4. Чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар турындагы белешмәләрне муниципаль районның, шәһәр округының җирле администрациясе башлыгы төзи һәм төгәлләштерә. Чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар – хәрби частьтәге хәрби хезмәткәрләр, аларның гаилә әгъзалары һәм чакыртып алу буенча тавыш бирүдә башка катнашучылар турындагы белешмәләрне, әгәр алар хәрби часть биләмәләре территориясендә яшәсәләр йә аларның хәрби хезмәт үтү урыны буенча билгеләнгән тәртиптә хәрби частьтә теркәлгән булсалар, хәрби часть коман-

диры төзи һәм төгәлләштерә. Әлеге белешмәләр шуңа вәкаләтле орган яисә вәкаләтле вазыйфаи зат тарафыннан территория комиссияләренә җибәрелә.

5. Тавыш бирү көненә шифаханәләрдәге, профилакторийлардагы, ял йортларындагы, хастаханәләрдәге, бүтән стационар дәвалау-профилактикалау учреждениеләрендәге һәм бүтән вакытлыча булу урыннарындагы чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлекләре әлеге учреждениеләр җитәкчеләре тарафыннан тапшырыла торган күрсәткечләр нигезендә тору урыны буенча төзелә.

6. Көндез укып, тулай торакта яшәүче студентлар һәм аспирантлар тулай торак урнашкан урын буенча чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегенә кертеләләр.

7. Чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлеге тиешле территория комиссиясе тарафыннан, шул исәптән «Сайлаулар» ДАСны кулланып, шуңа вәкаләтле орган яисә вәкаләтле вазыйфаи зат тарафыннан билгеләнгән рәвеш буенча тапшырыла торган күрсәткечләр нигезендә чакыртып алу буенча тавыш бирүнең һәр участогы буенча аерым-аерым төзелә.

8. Чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар турында белешмәләр тапшыручы затлар шушы белешмәләрнең дөреслеге һәм тулылыгы өчен, шулай ук аларны үз вакытында тапшыру өчен җаваплы була.

9. Граждан чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегенә бер генә тавыш бирү участогында кертелә. Чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлекләренә гражданны төрле тавыш бирү участокларында кертү факты территория комиссиясе тарафыннан ачыкланганда тиешле территория комиссиясе, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлекләре участок комиссияләренә тапшырылганчы, әлеге исемлекләрдәге хаталарны һәм төгәлсезлекләрне бетерү эшен уздыра.

10. Чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлеге ике нөсхәдә төзелә. Чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегенә кертелә торган чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар турындагы белешмәләр алфавит тәртибендә яисә бүтән тәртиптә (торак пунктлар, урамнар, йортлар, фатирлар буенча) урнаштырыла. Исемлектә чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучының фамилиясе, исеме, атасының исеме, туган елы (18 яшьтә булса – өстәмә рәвештә туган көне һәм ае), яшәү урынының адресы күрсәтелә. Чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегендә чакыртып алу буенча

тавыш бирүнең һәр бюллетенен алганын раслап, үз паспортының яисә паспортын алмаштыручы документының сериясен һәм номерын күрсәтеп, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыга имза салу өчен, шулай ук чакыртып алу буенча тавыш бирүнең суммар күрсәткечләрен кертү өчен һәм чакыртып алу буенча тавыш бирү бюллетенен биргән участок комиссиясе әгъзасына имза салу өчен урын күз алдында тотылырга тиеш.

11. Чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегенең беренче нөсхәсенә исемлекне төзегән комиссия рәисе һәм секретаре имза сала. Хәрби часть территориясендә төзелгән чакыртып алу буенча тавыш бирү участокларында чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегенә участок комиссиясе рәисе һәм секретаре имза сала. Чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлеге тиешенчә территория комиссиясенең һәм (яисә) участок комиссиясенең мөһерләре белән таныклана. Чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегенең икенче нөсхәсен әзерләү һәм аннан файдалану, аны тиешле участок комиссиясенә тапшыру, таныклау һәм төгәлләштерү тәртибе һәм сроклары Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнә.

12. Тиешле территория комиссиясе чакыртып алу буенча тавыш бирүнең конкрет участогының чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегенең беренче нөсхәсен тавыш бирү көненә кадәр 20 көннән дә соңга калмыйча акт буенча участок комиссияләренә тапшыра. Участок комиссиясе чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегенең беренче нөсхәсен аерым китапларга бүлергә хокуклы. Һәр шундый китап тавыш бирү көненнән алдагы көннән дә соңга калмыйча брошюралар итеп тегелергә тиеш, ул тиешле участок комиссиясенең мөһере һәм аның рәисенең имзасы белән раслана.

13. Участок комиссиясе комиссияләрнең чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларны теркәүче (исәпкә алучы) җирле үзидарә органнары, учреждениеләр һәм оешмалар белән үзара хезмәттәшлекне оештыруның билгеләнгән тәртибе нигезендә чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлеген төгәлләштерә. Тикшерелгән һәм төгәлләштерелгән чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлеге тавыш бирү көненнән алдагы көннән дә соңга калмыйча участок комиссиясе рәисе һәм секретаре тарафыннан имзалана һәм участок комиссиясе мөһере белән таныклана.

14. Чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлеге тавыш бирү көненә 20 көн кала участок комиссиясе та-

рафыннан чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларга танышу һәм өстәмә төгәлләштерү өчен бирелә.

15. Чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашу хокукына ия гражданин үзен чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегенә кертү турында, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегенә үзе хакында кертелгән белешмәләрдә нинди дә булса хата яисә төгәлсезлек турындагы гариза белән участок комиссиясенә мөрәҗәгать итәргә хокуклы. Мөрәҗәгать алынган мизгелдән 24 сәгать эчендә, ә тавыш бирү көнендә ике сәгать эчендә, әмма тавыш бирү тәмамланган мизгелдән дә соңга калмыйча участок комиссиясе гариза бирүче хәбәр иткән белешмәләрне һәм тапшырылган документларны тикшерергә һәм йә хатаны яисә төгәлсезлекне бетерергә, йә, гаризаны кире кагуның сәбәпләрен күрсәтеп, гаризаны кире кагу турында карар кабул итәргә тиеш, әлеге карарның таныкланган күчермәсе мөрәҗәгать итүчегә тапшырыла. Гражданны чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегенә кертү турындагы гаризаны кире кагу хакында участок комиссиясе карарына югарырак комиссиягә яисә судка (участок комиссиясе урнашкан урын буенча) шикаять белдерелергә мөмкин, алар исә «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон нигезендә шикаятьне (гаризаны) – өч көн эчендә, ә тавыш бирүгә өч көн һәм аннан да кимрәк көн калганда һәм тавыш бирү көнендә кичекмәстән карарга тиеш. Шикаятьне (гаризаны) канәгатьләндерү турында карар кабул ителгән очракта, участок комиссиясе чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегенә кичекмәстән төзәтү кертә. Гражданны чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегеннән төшереп калдыру, аңа әлеге статьяның 11 өлешендә каралган тәртиптә тиешле комиссияләр рәисләре һәм секретарьлары имза салганнан соң һәм ул әлеге комиссияләрнең мөһерләре белән таныкланганнан соң, бары тик рәсми документлар нигезендә генә башкарыла, шул исәптән чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыны башка чакыртып алу буенча тавыш бирү участогында чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегенә кертү турында югарырак комиссиягә хәбәр иткәннән соң, шулай ук чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыга бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы бирелгән очракта гамәлгә ашырыла. Бу чакта чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегендә, шулай ук «Сайлаулар» ДАСның белешмәләр базасында гражданны исемлектән төшереп калдыру датасы, шулай

ук аның сәбәбе күрсәтелә. Чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегендә язу участок комиссиясе рәисе имзасы белән таныклана, ә бүтән чакыртып алу буенча тавыш бирү участогында тавыш бирү таныклыгы бирелгәндә бүтән чакыртып алу буенча тавыш бирү участогында тавыш бирү таныклыгын биргән комиссия әгъзасы имзасы белән таныклана. Һәр граждан Россия Федерациясе гражданы паспортын алу һәм аны алмаштыру, Россия Федерациясе гражданнарын яшәү урыны буенча теркәү һәм теркәү исәбеннән төшерү, Россия Федерациясе гражданы паспортын билгеләнгән тәртипне бозып бирү фактлары турындагы белешмәләрне, тиешле участокта чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегенә кертелгән чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларга кагылышлы түбәндәге шәхси күрсәткечләрне күрсәткән килеш: фамилиясен, исемен, атасының исемен, туган датасын, туган урынын, җенесен, гражданлыгын, яшәү урынының адресын, шәхесен таныклаучы документ төрен, шушы документның сериясен һәм номерын, документ биргән органның атамасын яисә кодын, документ бирү датасын, участок комиссиясенә хәбәр итәргә хокуклы.

16. Вакытлыча булу урыннарындагы, өзлексез эш циклында эшләүче оешмаларда һәм эш көне (сменасы) озынлыгын кыскартып тору мөмкин булмаган аерым төр эшләрдә эшләүче чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар шулай ук хәрби часть урнашкан җирдән читтә булган хәрби хезмәткәрләр арасыннан чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар тавыш бирү көненә кадәр өч көннән дә соңга калмыйча участок комиссиясенә шәхсән бирелгән язма гариза буенча участок комиссиясе карары белән аларның вакытлыча булу урынындагы участокта чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегенә кертелергә мөмкин. Бу хактагы мәгълүмат әлеге чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучы чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегенә яшәү урыны буенча кертелгән участок комиссиясенә тиешле территория комиссиясе аша кичекмәстән тапшырыла. Участок комиссиясе «Аерым тамгалар» графасында «____ номерлы участокта чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегенә кертелде» дигән тамга ясый, чакыртып алу буенча тавыш бирү участогы номерын күрсәтә.

17. Тавыш бирү тәмамланганнан соң һәм чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар тавышларын санау башланганнан соң, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлекләренә нинди дә булса үзгәрешләр кертү тыела.

18. Чакыртып алу буенча тавыш бирү нәтиҗәләре рәсми басылып чыкканнан соң, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлекләрендәге чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар турындагы мәгълүмат сайлаучылар, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар регистрындагы чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар турындагы белешмәләрне төгәлләштерү өчен файдаланылырга мөмкин.

26 статья. **Чакыртып алу буенча тавыш бирү участокларын төзү**

1. Тавыш бирүне уздыру һәм чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның тавышларын санау өчен чакыртып алу буенча тавыш бирү участоклары төзелә. Чакыртып алу буенча тавыш бирү участоклары «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон таләпләре нигезендә Татарстан Республикасы территориясендә төзелгән сайлау участоклары, референдум участоклары белән бердәй була.

2. Чакыртып алу буенча тавыш бирү участоклары «Татарстан Республикасы референдумы турында» Татарстан Республикасы Законы белән Татарстан Республикасы референдум участокларын төзү өчен билгеләнгән тәртиптә төзелә.

3. Чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар вакытлыча булу урыннарында (хастаханәләрдә, шифаханәләрдә, ял йортларында, шик белдерелүче һәм гаепләнүче затларны сак астында тоту урыннарында һәм башка вакытлыча булу урыннарында) чакыртып алу буенча тавыш бирү участоклары – законда каралган комиссия тарафыннан ул билгеләгән срокка тавыш бирү көненнән 30 көннән дә соңга калмыйча, ә аерым очракларда тавыш бирү көненә кадәр өч көннән дә соңга калмыйча югарырак комиссия белән килештереп төзелергә мөмкин.

4. Хәрби хезмәткәрләр чакыртып алу буенча тавыш бирүнең бердәм участокларында тавыш бирәләр. Искәрмә буларак, чакыртып алу буенча тавыш бирү участокларын торак пунктлардан аерымланган, ерак урыннарда урнашкан хәрби частьләр территорияләрендә төзү рөхсәт ителә. Бу очракларда чакыртып алу буенча тавыш бирү участоклары – әлеге статьяның 3 өлешендә билгеләнгән срокка, ә аерым очракларда тавыш бирү көненә кадәр биш көннән дә соңга калмыйча тиешле территория комиссиясе карары буенча хәрби частьләр командирлары тарафыннан төзелә.

5. Чакыртып алу буенча тавыш бирү участоклары исемлекләре, чикләрен (әгәр чакыртып алу буенча тавыш бирү участогы торак пункт территориясенең бер өлешендә урнашкан булса) йә торак пунктлар исемлеген (әгәр чакыртып алу буенча тавыш бирү участогы бер яисә берничә торак пункт территориясендә урнашкан булса), участок комиссияләренең номерларын һәм тавыш бирү урыннарын күрсәтеп, тавыш бирү көненә кадәр 40 көннән дә соңга калмыйча муниципаль район, шәһәр округы җирле администрациясе башлыгы тарафыннан бастырып чыгарылырга тиеш. Әлеге статьяның 2 өлешендә билгеләнгән сроктан соң төзелгән чакыртып алу буенча тавыш бирү участоклары турындагы мәгълүмат муниципаль район, шәһәр округы җирле администрациясе башлыгы тарафыннан бастырып чыгарылырга (игълан ителергә), шулай ук тиешле участоклар төзелгән көннән ике көннән дә соңга калмыйча чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар вакытлыча тору урыннарының администрациясе тарафыннан чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларга җиткерелергә тиеш.

8 бүлек. **Чакыртып алу кампаниясен мәгълүмат белән тәэмин итү**

27 статья. **Чакыртып алу кампаниясен мәгълүмат белән тәэмин итү**

Чакыртып алу кампаниясен мәгълүмат белән тәэмин итүгә чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларга чакыртып алу мәсьәләләре буенча мәгълүмат җиткерү һәм агитация кертелә, ул чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның үз ихтыярларын аңлы рәвештә белдерүләренә, чакыртып алу кампаниясенең хәбәрдар булуына ярдәм күрсәтә.

28 статья. **Чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларга мәгълүмат җиткерү**

1. Чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларга мәгълүмат җиткерүне дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары, комиссияләр, массакүләм мәгълүмат чараларын чыгаруны гамәлгә ашыручы оешмалар, физик һәм юридик затлар «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль закон, әлеге Закон нигезендә гамәлгә ашыралар.

2. Массакүләм мәгълүмат чараларында урнаштырыла торган яисә башка төрле ысул белән таратыла торган мәгълүмат ма-

териаллары объектив, дөрес булырга тиеш, чакыртып алынучы затның хокукларын, инициатив төркемнең, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның бүтән төркемнәренең хокуклары тигезлеген бозмаска тиеш.

3. Чакыртып алу буенча тавыш бирүне әзерләү һәм уздыру барышы турында, Татарстан Республикасы Президентын чакыртып алу тәртибе хакындагы законнар турында мәгълүматны чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларга җиткерүне, шул исәптән массакүләм мәгълүмат чаралары аша да, комиссияләр гамәлгә ашыра. Комиссия шулай ук инвалид булган чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларга мәгълүмат җиткерү буенча кирәкле гамәлләрне тормышка ашыра.

4. Массакүләм мәгълүмат чараларын чыгаруны гамәлгә ашыручы оешмаларның чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларга мәгълүмат җиткерү эшчәнлеге ирекле башкарыла.

5. Мәгълүмати теле- һәм радиопрограммаларда, вакытлы матбугат басмаларындагы публикацияләрдә инициатив төркем, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның бүтән төркемнәре эшчәнлеге турындагы хәбәрләр бары тик аерым мәгълүмат блогы белән, комментарийларсыз гына бирелергә тиеш. Аларда чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның нинди дә булса төркеменә өстенлек бирелмәскә тиеш, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның нинди дә булса төркеменә, инициатив төркемгә, шул исәптән аларның эшчәнлеген яктырту вакыты, мондый хәбәрләргә бирелгән матбугат мәйданының күләме буенча да, дискриминация (хокукларын киметү) булмаска тиеш.

6. Чакыртып алынучы зат чакыртып алу нигезләре сыйфатында күрсәтелә торган хәлләр буенча чакыртып алу кампаниясенең барлык чоры дәвамында ирекле, үзе мөстәкыйль билгели торган рәвештә аңлатмалар бирергә хокуклы.

7. Әлеге хәлләр буенча чакыртып алынучы зат тарафыннан бирелә торган, хуплап яисә каршы тавыш бирүгә чакыра торган өндәмәләре булмаган интервью, бүтән гавами чыгыш агитация материаллары булмый.

8. Чакыртып алу кампаниясен мәгълүмати тәэмин итү эшчәнлегендә Россия Федерациясе законнары нигезендә катнашучы журналист, башка иҗади хезмәткәр, массакүләм мәгълүмат чараларын чыгаруны гамәлгә ашыручы оешманың вазыйфаи заты чакыртып алу кампаниясе чорында һәм шушы чакыртып алу кампаниясе беткәннән соң бер ел дәвамында эш бирүче инициативасы буенча эштән азат ителә алмый яисә үзләренең ризалыгыннан

башка бүтән эшкә күчерелә алмый, моңа хезмәт турындагы Россия Федерациясе законнары нигезендә суд тәртибендә дәгъваланмаган йә суд тәртибендә законлы һәм нигезле дип танылган җәза бирелү очрагы керми.

9. Тавыш бирү көнендә Татарстан Республикасы территориясендә тавыш бирү тәмамланган мизгелгә кадәр чакыртып алу буенча тавыш бирү йомгаклары турындагы, тавыш бирү нәтиҗәләре турындагы күрсәткечләрне бастырып чыгару (игълан итү), шул исәптән мондый күрсәткечләрне билгеле бер затлар даирәсе керү чикләнмәгән мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләрендә («Интернет» гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрен дә кертеп) урнаштыру тыела.

29 статья. **Җәмәгатьчелек фикерен сорашып белешүләр**

1. Чакыртып алу кампаниясенә бәйле рәвештә җәмәгатьчелек фикерен сорашып белешүләр нәтиҗәләрен бастырып чыгару (игълан итү) сайлаучыларга (чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларга) мәгълүмат җиткерүнең бер төре булып тора.

2. Чакыртып алу кампаниясенә бәйле рәвештә җәмәгатьчелек фикерен сорашып белешүләр нәтиҗәләрен бастырып чыгарганда (игълан иткәндә) массакүләм мәгълүмат чаралары, гражданнар һәм шуларны бастырып чыгаручы (игълан итүче) оешмалар сорашып белешү үткәргән оешманы, аны үткәрү вакытын, сораштырылганнарның санын (сайлап алу рәвешендә), мәгълүмат җыю ысулын, сорашып белешү үткәрелгән территорияне, сорауның төгәл формулировкасын, ихтимал хаталарның статистик бәяләнешен, сорашып белешүгә заказ биргән һәм шуны бастырып чыгару (игълан итү) өчен түләгән зат (затлар) күрсәтелергә тиеш.

3. Тавыш бирү көненә кадәр биш көн эчендә, шулай ук тавыш бирү көнендә җәмәгатьчелек фикерен сорашып белешүләр нәтиҗәләрен, чакыртып алу буенча тавыш бирү нәтиҗәләренең фаразларын, чакыртып алу кампаниясенә бәйле бүтән төрле тикшеренүләр нәтиҗәләрен бастырып чыгару (игълан итү), шул исәптән аларны билгеле бер затлар даирәсе керү чикләнмәгән мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләрендә («Интернет» гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрен дә кертеп) урнаштыру тыела.

30 статья. **Чакыртып алу кампаниясен мәгълүмати тәэмин итү өчен файдаланыла торган телерадиотапшырулар оешмалары һәм вакытлы матбугат басмалары**

1. Чакыртып алу кампаниясен мәгълүмати тәэмин итү дәүләт телерадиотапшырулар оешмаларын, вакытлы матбугат басмаларын, шулай ук «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 47 статьясында күрсәтелгән муниципаль һәм дәүләтнеке булмаган телерадиотапшырулар оешмаларын, вакытлы матбугат басмаларын файдаланып гамәлгә ашырыла.

2. Дәүләт хакимияте органнары, җирле үзидарә органнары тарафыннан үзләренең бары тик рәсми материалларын һәм хәбәрләрен, норматив һәм бүтән актларын бастырып чыгару өчен генә гамәлгә куелган вакытлы матбугат басмаларында агитация материаллары, шулай ук инициатив төркемнең, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның бүтән төркемнәренең эшчәнлеген чагылдырылучы редакцион материаллар бастырып чыгарылмый.

3. Чакыртып алу буенча агитация алып бару өчен эфир вакытын, матбугат мәйданын бирергә тиешле дәүләт телерадиотапшырулар оешмаларының, шулай ук дәүләт вакытлы матбугат басмаларының исемлеге башкарма хакимиятнең массакүләм мәгълүмат чараларын теркәү функцияләрен гамәлгә ашыруга вәкаләтле органы тәкъдиме буенча Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан бастырып чыгарыла. Әлеге исемлек «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 47 статьясында билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенә тапшырыла.

31 статья. **Чакыртып алу мәсьәләләре буенча агитация**

1. Гражданнар, иҗтимагый берләшмәләр законда рөхсәт ителгән рәвешләрдә һәм законлы ысуллар белән чакыртып алу буенча агитация алып барырга хокуклы.

2. Чакыртып алу буенча агитация түбәндәгечә алып барылырга мөмкин:

1) телерадиотапшырулар оешмалары каналларында һәм вакытлы матбугат басмаларында;

2) гавами агитация гамәлләре уздыру юлы белән;

3) басма, аудиовизуаль һәм башка агитация материаллары бастырып чыгару һәм тарату юлы белән;

4) закон белән тыелмаган башка ысуллар белән.

3. Инициатив төркем, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның бүтән төркемнәре үз агитациясенең эчтәлеген, рәвешләрен һәм ысулларын мөстәкыйль билгели, аны мөстәкыйль алып бара, шулай ук аны алып бару өчен законнарда билгеләнгән тәртиптә башка затларны җәлеп итәргә хокуклы.

4. Чакыртып алу мәсьәләләре буенча агитация алып бару чыгымнары бары тик чакыртып алу буенча тавыш бирү фондларыннан гына түләнергә тиеш, моңа әлеге Законда билгеләнгән тәртиптә түләүсез эфир вакыты, түләүсез матбугат мәйданы бирү очраклары керми.

5. Тавыш бирү көненә 18 яшькә җитмәгән затларны чакыртып алу буенча агитациягә җәлеп итү, шул исәптән агитация материалларында мондый затларның сурәтләрен һәм гыйбарәләрен файдалану тыела.

6. Чакыртып алу буенча агитация алып бару, теләсә нинди агитация материалларын чыгару һәм тарату түбәндәгеләргә тыела:

1) дәүләт хакимияте органнарына, башка дәүләт органнарына, җирле үзидарә органнарына;

2) дәүләт яисә сайланулы муниципаль вазыйфаларны биләүче затларга, дәүләт һәм муниципаль хезмәткәрләргә, сәяси партияләрдән тыш, барлык милек рәвешләрендәге оешмаларның идарә органнары әгъзалары (югары идарә органы җыелыш булган оешмаларда – шул оешмаларның эшчәнлегенә җитәкчелек итүче органнар әгъзалары) булып торучы затларга – үзләренең вазыйфаи яисә хезмәт бурычларын үтәгәндә (моңа әлеге статьяның 7 өлешендә каралган очрак керми) һәм (яисә) үзләренең вазыйфаи яисә хезмәт бурычлары өстенлекләреннән файдаланып;

3) хәрби частьләргә, хәрби учреждениеләргә һәм оешмаларга;

4) хәйрия һәм дини оешмаларга, алар гамәлгә куйган оешмаларга, шулай ук дини берләшмәләр әгъзаларына һәм аларда катнашучыларга – йолалар һәм дини тантаналар башкарганда;

5) чакыртып алу комиссияләренә, чакыртып алу комиссияләренең хәлиткеч тавыш бирү хокукына ия әгъзаларына;

6) чит ил гражданнарына, гражданлыгы булмаган затларга, чит ил юридик затларына;

7) массакүләм мәгълүмат чараларын чыгаруны гамәлгә ашыручы оешмалар вәкилләренә – үз профессиональ эшчәнлекләрен башкарганда;

8) халыкара оешмаларга һәм халыкара иҗтимагый хәрәкәтләргә;

9) уздырыла торган чакыртып алу кампаниясе чорында суд карары белән үзләренә карата «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 56 статьясындагы 1 пунктында каралган чикләүләрне бозу факты билгеләнгән затларга.

7. Дәүләт яисә сайланулы муниципаль вазыйфаларны биләүче затлар чакыртып алу агитациясен алып барырга, шул исәптән телерадиотапшырулар оешмалары каналларында һәм вакытлы матбугат басмаларында, агитация материалларын чыгарырга һәм таратырга хокуклы, әмма үзенең вазыйфаи яисә хезмәттәге хәле өстенлекләреннән файдалану тыела.

8. Агитация материалларында физик затның сурәтен, чакыртып алу буенча тавыш бирүне уздыру мәсьәләләре буенча физик зат әйткәннәрдән файдалану бары тик әлеге физик затның язма ризалыгы белән генә рөхсәт ителә. Мондый ризалыкны раслаучы документ Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенә әлеге Законның 37 статьясындагы 4 өлеше нигезендә тапшырыла торган агитация материаллары нөсхәләре белән бергә, ә агитация материалы телерадиотапшырулар оешмасы каналында йә вакытлы матбугат басмасында урнаштырылган очракта Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенә аның таләбе буенча тапшырыла. Әлеге чикләү түбәндәгеләргә кагылмый:

1) чакыртып алуны уздыру буенча тиешле инициатив төркем, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның бүтән төркемнәре әгъзаларының сурәтләрен, чакыртып алу буенча тавыш бирүне уздыру мәсьәләләре буенча алар әйткәннәрдән, шулай ук чакыртып алынучы зат сурәтеннән файдалануга;

2) чакыртып алу буенча тавыш бирүне уздыру мәсьәләләре буенча гавами әйтелгән һәм игълан ителгән фикерләрдән файдалануга, мондый фикерләрне игълан итү датасын (вакыт аралыгын) һәм аларны игълан иткән массакүләм мәгълүмат чарасының исемен күрсәтеп. Чакыртып алу мәсьәләләре буенча агитация материалларында әлеге Закон нигезендә чакыртып алу мәсьәләләре буенча агитация алып бару хокукына ия булмаган физик затның мондый әйткән фикеренә сылтама бары тик шушы әйтелгән фикер чакыртып алу буенча тавыш бирүне уздыруның инициатив төркеме теркәлгән көнгә кадәр игълан ителгән очракта гына рөхсәт ителә. Мондый чакта сылтамада әлеге фикерне игълан итү датасы (вакыт аралыгы) һәм аны игълан иткән массакүләм мәгълүмат чарасының исеме күрсәтелергә тиеш;

3) әлеге Закон нигезендә әзерләнгән һәм таратылган агитация материалларында игълан ителгән фикерләрдән өзекләр китерүгә.

32 статья. **Агитация чоры**

1. Агитация чоры чакыртып алуны уздыру буенча инициатив төркемне теркәгән көннән башлана һәм тавыш бирү көненә кадәр бер тәүлек кала җирле вакыт белән ноль сәгатьтә туктатыла.

2. Телерадиотапшырулар оешмалары каналларында һәм вакытлы матбугат басмаларында чакыртып алу мәсьәләләре буенча агитация тавыш бирү көненә кадәр 28 көн кала башлана һәм тавыш бирү көненә кадәр бер тәүлек кала ноль сәгатьтә туктатыла.

3. Чакыртып алу мәсьәләләре буенча агитацияне тавыш бирү көнендә һәм аннан алдагы көндә алып бару тыела.

4. Комиссияләр, тавыш бирү урыннары урнашкан биналардан читтә, шуларга керү урыннарыннан кимендә 50 метр ераклыкта әлеге Законда билгеләнгән тәртиптә элек урнаштырылган басма агитация материаллары (листовкалар, плакатлар һәм бүтән материаллар) тавыш бирү көнендә шул ук урыннарда сакланып кала.

33 статья. **Телерадиотапшырулар оешмалары каналларында һәм вакытлы матбугат басмаларында чакыртып алу буенча агитация алып баруның гомуми шартлары**

1. Дәүләт һәм муниципаль телерадиотапшырулар оешмалары, дәүләт һәм муниципаль вакытлы матбугат басмалары редакцияләре инициатив төркемгә һәм чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның бүтән төркемнәренә, чакыртып алынучы затка чакыртып алу буенча агитация алып бару өчен әлеге Законда һәм федераль законнарда билгеләнгән тәртиптә бертигез шартлар тәэмин итәргә тиеш.

2. Телерадиотапшыруларның дәүләт оешмалары каналларында эфир вакыты һәм дәүләт вакытлы матбугат басмаларында матбугат мәйданы түләүле бирелә, федераль законнарда, әлеге Законда каралган очракларда һәм тәртиптә шулай ук түләүсез дә (түләүсез эфир вакыты, түләүсез матбугат мәйданы) бирелергә мөмкин. Бүтән телерадиотапшырулар оешмалары каналларында эфир вакыты һәм бүтән вакытлы матбугат басмаларында матбугат мәйданы инициатив төркемгә, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның бүтән төркемнәренә федераль законнарда, әлеге Законда каралган тәртиптә түләүле рәвештә бирелергә мөмкин.

3. Чакыртып алу кампаниясе башланырга кимендә бер ел кала теркәлгән массакүләм мәгълүмат чараларын чыгаруны гамәлгә ашыручы дәүләтнеке булмаган телерадиотапшырулар оешмалары һәм дәүләтнеке булмаган вакытлы матбугат басмалары редакцияләре инициатив төркемгә һәм чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның бүтән төркемнәренә тиешле массакүләм матбугат чараларында эфир вакыты, матбугат мәйданы бирергә хокуклы. Дәүләтнеке булмаган бүтән телерадиотапшырулар оешмалары һәм дәүләтнеке булмаган бүтән вакытлы матбугат басмалары редакцияләре инициатив төркемгә, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның бүтән төркемнәренә эфир вакыты, матбугат мәйданы бирергә хокуклы түгел.

4. Дәүләтнеке булмаган телерадиотапшырулар оешмалары һәм дәүләтнеке булмаган вакытлы матбугат басмалары редакцияләре тарафыннан бирелә торган эфир вакыты, матбугат мәйданы өчен түләү шартлары инициатив төркем һәм чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның бүтән төркемнәре өчен бердәй булырга тиеш. Бу таләп инициатив төркемгә керүче сайлау берләшмәләре, гражданнар тарафыннан гамәлгә куелган дәүләтнеке булмаган вакытлы матбугат басмалары редакцияләренә кагылмый.

5. Чакыртып алу буенча тавыш бирү уздырганда эфир вакыты, матбугат мәйданы өчен түләү күләме (Россия Федерациясе валютасында) һәм башка шартлары турындагы белешмәләр тиешле телерадиотапшырулар оешмасы, вакытлы матбугат басмасы редакциясе тарафыннан бастырып чыгарылырга һәм Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан беренче агитация материалы бастырып чыгарылган көнгә кадәр бер көннән дә соңга калмыйча чакыртып алу буенча агитация алып бару өчен эфир вакыты, матбугат мәйданы бирү әзерлеге турындагы хәбәрнамә белән бергә Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенә тапшырылырга тиеш.

6. Дәүләтнеке булмаган телерадиотапшырулар оешмалары һәм дәүләтнеке булмаган вакытлы матбугат басмалары редакцияләре, атнага бер тапкырдан да сирәгрәк чыга торган дәүләт вакытлы матбугат басмалары редакцияләре, махсуслаштырылган телерадиотапшырулар оешмалары һәм махсуслаштырылган вакытлы матбугат басмалары редакцияләре (мәдәни-агарту, балалар өчен, техник, фәнни һәм башка), муниципаль телерадиотапшырулар оешмалары һәм вакытлы матбугат басмалары редакцияләре дә чакыртып алу буенча агитация алып бару өчен эфир вакыты, матбугат мәйданы бирүдән баш тартырга хокуклы.

Мондый баш тарту дип әлеге статьяның 5 өлешендә күрсәтелгән хәбәрнамәне шушы өлештә билгеләнгән срокларда Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенә тапшырмау санала.

7. Массакүләм мәгълүмат чараларын чыгаруны гамәлгә ашыручы оешмалар чакыртып алу буенча агитация алып бару өчен бирелгән эфир вакытының һәм матбугат мәйданының күләмнәрен һәм хакын Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнгән рәвешләрдә һәм тәртиптә исәпкә алып барырга һәм шундый исәпкә алу күрсәткечләрен тавыш биргән көннән соң 10 көннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенә тапшырырга тиеш.

8. Массакүләм мәгълүмат чараларын чыгаруны гамәлгә ашыручы оешмалар түләүсез һәм түләүле рәвештә эфир вакыты һәм матбугат мәйданы бирелү турындагы әлеге статьяның 7 өлешендә күрсәтелгән исәпкә алу документларын тавыш биргән көннән алып кимендә өч ел дәвамында сакларга тиеш.

9. Дәүләт телерадиотапшырулар оешмаларының һәм дәүләт вакытлы матбугат басмалары редакцияләренең чакыртып алу буенча агитация алып бару өчен түләүсез эфир вакыты һәм түләүсез матбугат мәйданы бирүгә бәйле чыгымнары әлеге оешмаларның һәм редакцияләрнең эшчәнлек нәтиҗәләренә кертелә.

10. Чакыртып алу буенча агитация алып бару өчен телерадиотапшырулар оешмалары каналларында эфир вакытын, вакытлы матбугат басмаларында матбугат мәйданын бирү эфир вакыты, матбугат мәйданы бирелгәнче телерадиотапшырулар оешмасы, вакытлы матбугат басмасы редакциясе белән инициатив төркем, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның бүтән төркемнәре, чакыртып алынучы зат арасында язма рәвештә төзелгән шартнамә нигезендә гамәлгә ашырыла.

34 статья. **Телевидениедә һәм радиода чакыртып алу буенча агитация алып бару шартлары**

1. Дәүләт телерадиотапшырулар оешмалары каналларында түләүсез эфир вакыты чакыртып алу буенча тавыш бирүне билгеләү турындагы карар рәсми басылып чыкканнан соң бары тик инициатив төркемгә һәм, әгәр үзләре күрсәткән кандидатлар исемлекләре Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасында һәм (яисә) Татарстан Республикасы Дәүләт Советында депутат мандатларын бүлешүгә кертелгән булса яисә үзләре күрсәткән кандидатлар исемлекләренә Татарстан Республикасы Сайлау кодексының $97^1$ статьясы нигезендә депутат мандат-

лары тапшырылган булса, «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 42 статьясындагы 2 пунктында күрсәтелгән иҗтимагый берләшмәләрнең (аларның структур бүлекчәләренең) җитәкче органнары шулар сыйфатында эш итә торган чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның бүтән төркемнәренә, шулай ук чакыртып алынучы затка чакыртып алу мәсьәләләре буенча агитация алып бару өчен тигез шартларда бирелә.

2. Региональ дәүләт телерадиотапшырулар оешмалары чакыртып алу буенча агитация уздыру өчен әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән эфир вакытын инициатив төркемгә һәм чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән бүтән төркемнәренә бирергә тиеш. Бирелә торган эфир вакыты тиешле телерадиотапшырулар оешмасы тарафыннан билгеләнә торган, теле- һәм радиотапшырулар күбрәк аудиторияне җыя торган вакытка туры килергә тиеш.

3. Һәр региональ дәүләт телерадиотапшырулар оешмасы чакыртып алу буенча агитация уздыру өчен бирә торган, әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән эфир вакытының гомуми күләме эш көннәре буенча һәр каналда 30 минуттан да кимрәк булмаска тиеш, ә телерадиотапшырулар оешмасы тапшыруларының гомуми вакыты көнгә ике сәгатьтән кимрәк булса, тапшыруларның гомуми вакытыннан дүрттән береннән кимрәк булмаска тиеш. Инициатив төркемгә, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның бүтән төркемнәренә яисә чакыртып алынучы затка әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән эфир вакытын бирү нәтиҗәсендә эфир вакыты 60 минуттан артып киткән очракта, агитация уздыру өчен һәр телерадиотапшырулар оешмасы бирә торган эфир вакытының гомуми күләме кыскартыла һәм ул чакыртып алу буенча агитация уздыру хокукы бирелгән субъектлар санына тапкырланган 60 минутны тәшкил итәргә тиеш.

4. Түләүсез эфир вакытының гомуми күләменнән кимендә яртысы инициатив төркемгә, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның бүтән төркемнәренә (әлеге статьяның 1 өлешендәге нигезләмәне исәпкә алып), чакыртып алынучы затка бергәләшеп дискуссияләр, «түгәрәк өстәлләр» һәм бүтән шундый уртак агитация гамәлләре үткәрү өчен бирелергә тиеш.

5. Инициатив төркем, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның бүтән төркемнәре, чакыртып алынучы зат бергәләп уздырылучы агитация гамәлләрендә катнашудан баш тартырга хокуклы. Бу чакта бергәләп уздырылучы агитация гамәлен

уздыру өчен бирелгән эфир вакыты, шул исәптән әлеге гамәлдә бер генә катнашучы булу очрагында киметелми. Бергәләп уздырылучы агитация гамәлендә катнашудан баш тарту әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән, әлеге гамәлдә катнашудан баш тартучы инициатив төркемгә, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның бүтән төркемнәренә, чакыртып алынучы затка бирелә торган эфир вакытының күләмен арттыруга китерми.

6. Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән эфир вакытының гомуми күләменең калган өлеше (ул булса) дәүләт телерадиотапшырулар оешмалары тарафыннан инициатив төркемгә һәм әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның бүтән төркемнәренә, чакыртып алынучы затка агитация материалларын урнаштыру өчен бирелә.

7. Дәүләт телерадиотапшырулар оешмалары чакыртып алу буенча түләүле нигездә агитация алып бару өчен эфир вакытын резервта калдырырга тиеш. Түләү күләме һәм шартлары инициатив төркем, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның бүтән төркемнәре өчен бердәй булырга тиеш. Резервта калдырылган эфир вакытының гомуми күләме әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән эфир вакытының билгеләнгән гомуми күләменә тигез булырга яисә аннан ике тапкырдан күбрәк булмаган күләмгә кадәр арттырылырга тиеш. Инициатив төркем, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның бүтән төркемнәре резервта калдырылган эфир вакытының гомуми күләменнән әлеге күләмне чакыртып алу буенча агитация алып бару хокукына ия төркемнәр санына бүлү нәтиҗәсендә килеп чыккан өлеш кысаларында вакытны тиешле түләү нигезендә алырга хокуклы.

8. Әлеге Законның 33 статьясындагы 5 өлеше шартларын үтәгән дәүләтнеке булмаган телерадиотапшырулар оешмалары эфир вакытын инициатив төркемгә һәм чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның бүтән төркемнәренә бертигез шартларда (шул исәптән эфирга чыгу вакыты буенча да) бирергә тиеш.

9. Телерадиотапшырулар оешмалары каналларында, бүтән теле- һәм радиопрограммаларны, башка агитация материалларын трансляцияләп, агитация материалларын тапшыруны каплау тыела.

35 статья. **Вакытлы матбугат басмаларында чакыртып алу буенча агитация алып бару шартлары**

1. Татарстан Республикасы территориясендә таратыла һәм кимендә атнага бер мәртәбә чыга торган дәүләт вакытлы матбу-

гат басмаларының редакцияләре инициатив төркем, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның бүтән төркемнәре, чакыртып алынучы зат тарафыннан бирелгән агитация материаллары өчен матбугат мәйданнары бүлеп бирергә тиеш. Атналык гомуми минималь күләм тиешле матбугат басмасының атналык гомуми күләменнән кимендә 5 процент тәшкил итәргә тиеш. Бу чакта бүленеп бирелүче матбугат мәйданының гомуми күләменнән кимендә 40 проценты дәүләт вакытлы матбугат басмалары редакцияләре тарафыннан түләүсез бирелергә тиеш.

2. Атнага кимендә бер мәртәбә чыга торган дәүләт вакытлы матбугат басмалары редакцияләре чакыртып алу буенча агитация алып бару өчен түләүле матбугат мәйданын резервта калдырырга тиеш. Түләү күләме һәм шартлары инициатив төркем, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның бүтән төркемнәре өчен бердәй булырга тиеш. Резервта калдырыла торган матбугат мәйданының гомуми күләме тиешле матбугат басмасының атналык гомуми матбугат мәйданы күләменнән 5 процenttан да кимрәк булмаска тиеш. Инициатив төркем, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның бүтән төркемнәре резервта калдырылган матбугат мәйданының гомуми күләменнән, күләмен чакыртып алу буенча агитация алып бару хокукына ия төркемнәр санына бүлү нәтиҗәсендә килеп чыккан өлеш чикләрендә, тиешенчә түләп, матбугат мәйданын алырга хокуклы.

3. Әлеге Законның 33 статьясындагы 5 өлеше шартларын үтәгән дәүләтнеке булмаган вакытлы матбугат басмалары редакцияләре чакыртып алу буенча агитация алып бару өчен матбугат мәйданы бирүдән баш тартырга хокуклы.

4. Әлеге статья нигезендә башкарыла торган агитация материалларында инициатив төркем, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның бүтән төркемнәре белән килештерелмәгән бернинди редакция комментарийлары, шулай ук текст исемнәре һәм иллюстрацияләр бастырып чыгарылырга тиеш түгел.

5. Вакытлы матбугат басмаларында урнаштырыла торган барлык агитация материалларында чакыртып алу буенча агитация алып бару хокукына ия булган кайсы төркемнең тавыш бирү фонды акчалары исәбеннән шушы басылып чыккан материал өчен түләү турындагы мәгълүмат бирелергә тиеш. Әгәр агитация материаллары түләүсез бастырып чыгарылган булса, шул публикациядә аны кем урнаштыруы турында мәгълүмат булырга тиеш. Әлеге таләпне үтәү өчен вакытлы басма матбугат редакциясе җаваплы була.

6. Агитация материалларын бастырып чыгаручы вакытлы матбугат басмалары редакцияләре, сайлау берләшмәләре тарафыннан гамәлгә куелганнарыннан гайре, тиражны үзгәртү һәм вакытлы матбугат басмаларының чыгу чиратлылыгын үзгәртү юлы белән инициатив төркемгә, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның бүтән төркемнәренә өстенлек бирергә хокуклы түгел.

36 статья. **Гавами агитация гамәлләрендә чакыртып алу мәсьәләләре буенча агитация алып бару шартлары**

1. Дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары инициатив төркемгә, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның бүтән төркемнәренә, чакыртып алынучы затка гавами агитация гамәлләрен оештыруда һәм уздыруда ярдәм итәргә тиеш.

2. Митинглар, демонстрацияләр, урам йөрешләре һәм пикетлар оештыручыларның хәбәрнамәләре Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә бирелә һәм карала.

3. Инициатив төркем, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның бүтән төркемнәре, чакыртып алынучы зат гаризасы буенча җыелышлар рәвешендә гавами агитация гамәлләре уздыру өчен яраклы һәм дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге бина инициатив төркемгә, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның бүтән төркемнәренә, чакыртып алынучы затка гражданнар белән очрашулар өчен Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе яисә аның кушуы буенча территория комиссиясе тарафыннан билгеләнгән вакытка бинаның милекчесе, биләүчесе тарафыннан түләүсез бирелә. Бу чакта тиешле комиссия күрсәтелгән гамәлләрне уздыру өчен инициатив төркем, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның бүтән төркемнәре, чакыртып алынган зат өчен бертигез шартлар тәэмин итәргә тиеш.

4. Әлеге статьяның 3 өлешендә күрсәтелгән бина, шулай ук чакыртып алу буенча тавыш бирүне билгеләү турындагы карар рәсми басылып чыккан көнгә үзенең устав (җыелма) капиталында Россия Федерациясе, Россия Федерациясе субъекты һәм (яисә) муниципаль берәмлекләр өлеше 30 проценттан артыграк булган оешма милкендәге бина гавами агитация гамәлләре уздыру өчен әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән башка төркемнәрнең берсенә яисә чакыртып алынучы затка бирелгән булса, бинаның милекчесе, биләүчесе әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар төркемнәренә

дә шундый ук шартларда бина бирүдән баш тартырга хокуклы түгел. Инициатив төркемгә, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның бүтән төркемнәренә, чакыртып алынучы затка бина бирелгән очракта, бинаның милекчесе, биләүчесе тарафыннан бина бирү көненнән соң килүче көннән дә соңга калмыйча бина бирү факты, бина бирелгән шартлар турында, шулай ук агитация чоры дәвамында бинаның әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар төркемнәренә, чакыртып алынучы затка кайсы вакытта бирелү мөмкинлеге турында Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенә язма рәвештә хәбәр ителергә тиеш.

5. Инициатив төркемгә, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның бүтән төркемнәренә, чакыртып алынучы затка бина бирелү факты турында хәбәрнамә алган Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе аны алган мизгелдән ике тәүлек эчендә анда булган мәгълүматны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга яисә аны башка ысул белән чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән башка төркемнәренә, чакыртып алынучы затка җиткерергә тиеш.

6. Чакыртып алынучы зат, инициатив төркем, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның бүтән төркемнәре гражданнар белән очрашулар уздыру өчен әлеге статьяның 3 һәм 4 өлешләрендә күрсәтелгән биналарны бирүгә заявкалар шул биналарның милекчеләре, биләүчеләре тарафыннан әлеге заявкалар бирелгән көннән соң өч көн эчендә карала.

7. Инициатив төркем, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның бүтән төркемнәре гражданнарныкы һәм барлык милек рәвешләрендәге оешмаларныкы булган биналарны һәм йортларны гавами агитация чаралары уздыру өчен шартнамә нигезендә арендаларга хокуклы.

8. Җыелышлар рәвешендә гавами агитация гамәлләре өчен яраклы бердәнбер бина (урын) хәрби частьнеке булган йә хәрби оешмада яисә учреждениедә булган очрактан гайре, хәрби частьләрдә, хәрби оешмаларда һәм учреждениеләрдә чакыртып алу мәсьәләләре буенча агитация алып бару тыела. Мондый бина (урын) территория комиссиясе гарызнамәсе буенча инициатив төркемгә, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның бүтән төркемнәренә, чакыртып алынучы затка чакыртып алу буенча тавыш бирүдә хәрбиләр арасыннан булган катнашучылар белән очрашулар уздыру өчен хәрби часть командиры тарафыннан бирелә. Күрсәтелгән очрашуларны оештыруны территория комиссиясе

белән берлектә хәрби часть командиры тәэмин итә, бу чакта аны уздыру көненә кадәр өч көннән дә соңга калмыйча очрашуның урыны һәм вакыты турында әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән бүтән төркемнәргә, чакыртып алынучы затка хәбәр ителә.

9. Гавами агитация гамәлләрен уздырганда иминлекне тәэмин итү Россия Федерациясе законнары нигезендә гамәлгә ашырыла.

37 статья. **Басма, аудиовизуаль һәм бүтән төрле агитация материалларын чыгару һәм тарату шартлары**

1. Инициатив төркем, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның бүтән төркемнәре басма, шулай ук аудиовизуаль һәм бүтән төрле агитация материалларын Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә Россия Федерациясе территориясендә тоткарлыксыз таратырга хокуклы. Барлык агитация материаллары Россия Федерациясе территориясендә әзерләнергә тиеш.

2. Басма агитация материалларын әзерләү буенча эшләр башкаручы яисә хезмәтләр күрсәтүче оешмалар, индивидуаль эшкуарлар инициатив төркемгә, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның бүтән төркемнәренә бу материалларны әзерләү өчен түләүнең бертигез шартларын тәэмин итәргә тиеш. Басма агитация материалларын әзерләү буенча әлеге оешмаларның, индивидуаль эшкуарларның эшләренә һәм хезмәт күрсәтүләренә түләү күләме (Россия Федерациясе валютасында) турындагы белешмәләр инициатив төркем теркәлгән көннән соң 30 көннән дә соңга калмыйча тиешле оешма, тиешле индивидуаль эшкуар тарафыннан бастырып чыгарылырга һәм шул ук срокта Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенә тапшырылырга тиеш. Әлеге таләпләрне үтәмәгән оешма, индивидуаль эшкуар басма агитация материалларын әзерләү буенча эшләр башкарырга яисә хезмәтләр күрсәтергә хокуклы түгел.

3. Барлык басма һәм аудиовизуаль агитация материалларында шул материалларны әзерләгән оешманың исеме, юридик адресы һәм салым түләүченең идентификация номеры (затның фамилиясе, исеме, атасының исеме һәм ул яши торган Россия Федерациясе субъектының, районның, шәһәрнең, бүтән торак пунктның атамасы), аларга заказ биргән оешманың атамасы (затның фамилиясе, исеме, атасының исеме), шулай ук әлеге материалларның тиражы һәм басылып чыгу датасы турында һәм аларны әзерләгән өчен тиешле тавыш бирү фонды акчаларыннан түләнүе турында мәгълүмат булырга тиеш.

4. Басма агитация материалларының нөсхәләре яисә аларның күчермәләре, аудиовизуаль агитация материалларының нөсхәләре, башка агитация материалларының фотографияләре, таратыла башлаганчы, инициатив төркем һәм чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның башка төркеме тарафыннан Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенә тапшырылырга тиеш. Күрсәтелгән материаллар белән бергә шулай ук әлеге материалларны әзерләгән һәм аларга заказ биргән оешманың (затның) урнашкан урыны турында (яшәү урынының адресы турында) белешмәләр тапшырылырга тиеш.

5. Агитация материалларын чакыртып алу буенча тавыш бирүнең тиешле фонды акчалары исәбеннән алдан түләмичә һәм әлеге статьяның 3 өлешендә билгеләнгән таләпләрне бозып әзерләү тыела.

6. Агитация материалларын әлеге статьяның 4 өлешендә билгеләнгән таләпләрне бозып тарату тыела.

7. Җирле үзидарә органнары тавыш бирү көненә кадәр кимендә 30 көннән дә соңга калмыйча чакыртып алу буенча тавыш бирү буенча һәр участок территориясендә басма агитация материаллары урнаштыру өчен территория комиссиясе тәкъдиме белән махсус урыннар билгеләргә тиеш. Мондый урыннар чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар керә алу өчен җайлы булырга һәм чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар андагы мәгълүмат белән таныша алырлык җирдә урнашкан булырга тиеш. Бүлеп бирелгән урыннарның мәйданы чакыртып алу комиссиясенең мәгълүмати материалларын һәм инициатив төркемнең, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның бүтән төркемнәренең агитация материалларын урнаштыру өчен җитәрлек булырга тиеш. Инициатив төркемгә, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның бүтән төркемнәренә басма агитация материалларын урнаштыру өчен бертигез мәйдан бирелгән булырга тиеш. Күрсәтелгән урыннар исемлеге инициатив төркемгә, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның бүтән төркемнәренә территория комиссиясе тарафыннан җиткерелә.

8. Басма агитация материаллары биналарда, йортларда, корылмаларда һәм башка объектларда (әлеге статьяның 7 өлешендә күрсәтелгән урыннардан гайре) әлеге объектларның милекчеләре, биләүчеләре ризалыгы һәм алар куйган шартларда гына эленергә (ябыштырылырга, урнаштырылырга) мөмкин. Дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге йә инициатив төркемне теркәү турында карар рәсми басылып чыккан (басылган) көнгә устав (җыелма) капиталында Россия Федерациясе, Россия Федерациясе субъект-

лары һәм (яисә) муниципаль берәмлекләр өлеше (кертеме) 30 процenttан артыграк булган оешмалар милкендәге объектта агитация материаллары инициатив төркем, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның бүтән төркемнәре өчен бертигез шартларда урнаштырыла. Бу чакта дәүләт милкендәге яисә муниципаль милектәге объектта агитация материалларын урнаштырган өчен түләү алынмый.

9. Реклама хезмәтләре күрсәтүче оешмалар, индивидуаль эшкуарлар инициатив төркемгә һәм чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның башка төркемнәренә агитация материалларын урнаштыру өчен бертигез шартлар тәэмин итәргә тиеш.

10. Агитация материалларын һәйкәлләргә, обелискларга, йортларга, корылмаларга һәм тарихи, мәдәни һәм архитектура кыйммәте булган биналарга, шулай ук чакыртып алу комиссияләре, тавыш бирү урыннары урнашкан йортларга һәм аларга керергә 50 метрдан кимрәк ераклыкта элү (ябыштыру, урнаштыру) тыела.

11. Әлеге статья нигезләмәләре әлеге Законның 34 һәм 35 статьялары нигезендә таратыла торган агитация материалларына карата кулланылмый.

38 статья. **Чакыртып алу агитациясен үткәргәндә чикләүләр**

1. Чакыртып алу агитациясен үткәргәндә Россия Федерациясе субъектында референдум мәсьәләләре буенча агитация үткәргәндәге «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 56 статьясы белән билгеләнгән чикләүләр гамәлдә була.

2. Чакыртып алу комиссияләре чакыртып алу агитациясен үткәрүнең билгеләнгән тәртибе үтәлешен тикшереп тора һәм җибәрелгән хокук бозуларны бетерү буенча чаралар күрә.

## 9 бүлек. **Чакыртып алу кампаниясен финанслау**

39 статья. **Чакыртып алу буенча тавыш бирүне әзерләүне һәм уздыруны финанс ягыннан тәэмин итү**

1. Чакыртып алу буенча тавыш бирүне уздыруга бәйле чыгымнар Татарстан Республикасы бюджетыннан шушы максатларга бүлеп бирелгән акчалар исәбеннән башкарыла. Шул ук вакытта чакыртып алу буенча тавыш бирүләрне билгеләү турында карар рәсми басылып чыкканга кадәр Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең чакыртып алу буенча тавыш бирүне

үткәрү тәкъдимен хуплап җыелган имзаларны тикшерүне уздыруга бәйле чыгымнары гына Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенә Татарстан Республикасы бюджетыннан бүленгән акчалар исәбеннән башкарыла.

2. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе чакыртып алу буенча тавыш бирүне уздыруга Татарстан Республикасы бюджетында каралган акчаларны баш бүлүче булып санала.

3. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең чакыртып алу буенча тавыш бирүләргә бүлеп бирелгән бюджет акчаларын тоту турындагы хисабы Татарстан Республикасы Дәүләт Советына тапшырыла. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе рәисе чакыртып алу буенча тавыш бирүне әзерләүгә һәм уздыруга бүлеп бирелгән акчаларны тота һәм финанс документларының Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең финанс мәсьәләләре буенча карарларына туры килүе өчен һәм әлеге акчаларның законда билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда тотылуы хакында хисаплар тапшыру өчен җаваплы була.

4. Татарстан Республикасы бюджетыннан Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенә чакыртып алу буенча тавыш бирүне әзерләү һәм үткәрү, автоматлаштыру чараларын эксплуатацияләү һәм арттыру, чакыртып алу комиссиясе эшчәнлеген тәэмин итү өчен бүлеп бирелгән акчаларның счетларын ачу һәм алып бару, исәпкә алу, хисаплылык һәм аларны күчерү тәртибе, Татарстан Республикасы Милли банкы белән килештереп, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнә. Акчалар Россия Федерациясе Үзәк банкы учреждениеләрендә, ә алар булмаган очракта Россия Федерациясе Саклык банкы филиалларында комиссияләргә ачыла торган счетларга күчерелә.

5. Чакыртып алу комиссияләренең счетларын ачу һәм счетлар буенча операцияләр үткәрү буенча банк хезмәтләре өчен түләү алынмый. Шушы счетлардагы акчалардан файдаланган өчен банк процентлар түләми.

6. Татарстан Республикасы бюджетыннан акчалар алган Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе алар буенча бухгалтерлык, касса исәбен алып бара һәм хисап бирә.

40 статья. **Чакыртып алу буенча тавыш бирү фондларын төзү тәртибе**

1. Инициатив төркем чакыртып алу буенча тавыш бирүне үткәрү инициативасын күрсәтү, әлеге инициативаны хуплап им-

залар җыюны оештыру эшчәнлеген, шулай ук тавыш бирүдә билгеле бер нәтиҗәгә ирешүгә юнәлдерелгән эшчәнлеген финанслау өчен үз фондын булдырырга тиеш. Чакыртып алу буенча тавыш бирү фонды акчаларын тотуның иң чик күләме 20 миллион сумнан артыграк була алмый.

2. Чакыртып алу буенча тавыш бирү фонды чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның башка төркемнәре тарафыннан, шул исәптән чакыртып алуны үткәрүгә, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашуга каршы, шулай ук чакыртып алуга каршы агитация өчен дә төзелергә мөмкин. Әлеге фондлар инициатив төркем тарафыннан төзелгән чакыртып алу буенча тавыш бирү фонды өчен федераль законнарда, әлеге Законда билгеләнгән кагыйдәләргә буйсына.

3. Чакыртып алу буенча тавыш бирү фонды түбәндәге акчалар исәбеннән төзелергә мөмкин:

1) инициатив төркемнең, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның башка төркемнәренең үз акчалары, аларның гомуми күләме төркемнең һәр әгъзасына чакыртып алу буенча тавыш бирү фонды акчаларыннан барлык чыгымнарның иң чик күләменең бер процентыннан артыграк була алмый;

2) гражданнарның һәм юридик затларның ирекле иганәләре, ул шулай ук һәр граждан, юридик зат өчен чакыртып алу буенча тавыш бирү фонды акчаларыннан барлык чыгымнарның иң чик күләменең 1 һәм 7 процентыннан артыграк күләмдә була алмый.

4. Инициатив төркем, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучы башка төркем финанс мәсьәләләре буенча вәкаләтле вәкилләрен билгеләргә тиеш. Финанс мәсьәләләре буенча вәкаләтле вәкилләрне теркәү инициатив төркем, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучы башка төркем үтенечнамәсе нигезендә Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан башкарыла, анда финанс мәсьәләләре буенча вәкаләтле вәкилнең фамилиясе, исеме, атасының исеме, туу датасы, паспортының яисә граждан паспортын алмаштыручы документның сериясе, номеры һәм аны бирү датасы, яшәү урынының адресы, төп эш яисә хезмәт урыны, биләгән вазыйфасы (төп эш яисә хезмәт урыны булмаганда, – шөгыльләренең төре), вәкаләтләре, шул исәптән финанс документларына имза салу хокукы күрсәтелә.

5. Чакыртып алу буенча тавыш бирү фондына түбәндәгеләр тарафыннан иганәләр кертү тыела:

1) чит дәүләтләр һәм чит ил оешмалары;

2) чит ил гражданнары;

3) гражданлыгы булмаган затлар;

4) иганә кертү көненә 18 яшькә җитмәгән Россия Федерациясе гражданнары;

5) әгәр устав (җыелма) капиталында чит ил катнашының өлеше (кертеме) чакыртып алу кампаниясе башланган көнгә (ачык акционер җәмгыятьләр өчен – узган финанс елына акционерларның еллык гомуми җыелышында катнашу хокукы булган затлар исемлеге төзелгән көнгә) 30 проценттан артыграк булса, чит ил катнашындагы Россия юридик затлары;

6) халыкара оешмалар һәм халыкара иҗтимагый хәрәкәтләр;

7) дәүләт хакимияте органнары, башка дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары;

8) дәүләт һәм муниципаль учреждениеләр, дәүләт һәм муниципаль унитар предприятиеләр;

9) әгәр устав (җыелма) капиталында Россия Федерациясе, Россия Федерациясе субъектлары һәм (яисә) муниципаль берәмлекләр өлеше (кертеме) чакыртып алу кампаниясе башланган көнгә (ачык акционер җәмгыятьләр өчен – узган финанс елына акционерларның еллык гомуми җыелышында катнашу хокукы булган затлар исемлеге төзелгән көнгә) 30 проценттан артыграк булса, юридик затлар;

10) дәүләт органнары һәм (яисә) җирле үзидарә органнары гамәлгә куйган оешмалар (хосусыйлаштыру тәртибендә гамәлгә куелган акционер җәмгыятьләрдән тыш); әлеге өлешнең 5 һәм 9 пунктларында күрсәтелгән юридик затлар гамәлгә куйган оешмалар; устав (җыелма) капиталында чакыртып алу кампаниясе башланган көнгә (ачык акционер җәмгыятьләр өчен – узган финанс елына акционерларның еллык гомуми җыелышында катнашу хокукы булган затлар исемлеге төзелгән көнгә) әлеге өлешнең 5 һәм 9 пунктларында күрсәтелгән юридик затларның өлеше (кертеме) 30 проценттан артыграк булган оешмалар;

11) хәрби частьләр, хәрби учреждениеләр һәм оешмалар, хокук саклау органнары;

12) хәйрия оешмалары һәм дини оешмалар, шулай ук алар тарафыннан гамәлгә куелган оешмалар;

13) аноним иганәчеләр. Иганә кертүгә түләү документында түбәндәге белешмәләрнең берәрсен: фамилиясен, исемен, атасының исемен, яшәү урыны адресын күрсәтми калган яисә дөрес булмаган белешмәләр күрсәткән граждан йә иганә кертүгә түләү документында түбәндәге белешмәләрнең берәрсен: салым түләүченең идентификация номерын, атамасын, банк реквизитларын күрсәтми калган яисә дөрес булмаган белешмәләр күрсәткән юридик зат аноним иганәче дип санала;

14) чакыртып алу кампаниясе башланачак көнгә бер елдан азрак вакыт калгач теркәлгән юридик затлар;

15) чакыртып алу буенча тавыш бирү фондына иганә кертү көне алдындагы ел дәвамында түбәндәгеләрдән акчалар йә башка мөлкәт алган коммерциячел булмаган оешмалар:

чит дәүләтләрдән, шулай ук әлеге өлешнең 1 – 4, 6 – 8, 11 – 14 пунктларында күрсәтелгән органнардан, оешмалардан яисә физик затлардан;

чит ил катнашындагы Россия юридик затларыннан, әгәр аларның устав (җыелма) капиталында чит ил катнашу өлеше (кертеме) шул акчаларны күчерү йә башка мөлкәтне тапшыру көненә (ачык акционер җәмгыятьләр өчен – узган финанс елына акционерларның еллык гомуми җыелышында катнашу хокукы булган затлар исемлеге төзелгән көнгә) 30 проценттан артып китсә;

устав (җыелма) капиталында Россия Федерациясенең, Россия Федерациясе субъектларының һәм (яисә) муниципаль берәмлекләрнең өлеше (кертеме) шул акчаларны күчерү йә башка мөлкәтне тапшыру көненә (ачык акционер җәмгыятьләр өчен – узган финанс елына акционерларның еллык гомуми җыелышында катнашу хокукы булган затлар исемлеге төзелгән көнгә) 30 проценттан артып киткән юридик затлардан;

дәүләт органнары һәм (яисә) җирле үзидарә органнары тарафыннан гамәлгә куелган оешмалардан (хосусыйлаштыру тәртибендә гамәлгә куелган акционер җәмгыятьләрдән тыш);

әлеге пунктның өченче һәм дүртенче абзацларында күрсәтелгән юридик затлар тарафыннан гамәлгә куелган оешмалардан;

устав (җыелма) капиталында әлеге пунктның өченче һәм дүртенче абзацларында күрсәтелгән юридик затларның өлеше (кертеме) шул акчаларны күчерү йә башка мөлкәтне тапшыру көненә (ачык акционер җәмгыятьләр өчен – узган финанс елына акционерларның еллык гомуми җыелышында катнашу хокукы булган затлар исемлеге төзелгән көнгә) 30 проценттан артып киткән оешмалардан.

6. Әлеге статьяның 5 өлешендәге 15 пунктында күрсәтелгән коммерциячел булмаган оешмалар, әлеге коммерциячел булмаган оешмалар алган акчалар йә башка мөлкәт шул акчаларны күчергән йә башка мөлкәтне тапшырган әлеге статьяның 5 өлешендәге 15 пунктының икенче – җиденче абзацларында күрсәтелгән чит дәүләтләргә, органнарга, оешмаларга яисә физик затларга чакыртып алу буенча тавыш бирү фондына иганә кертү көненә кадәр

кире кайтарылмаган очракта гына (кайтару мөмкин булмаганда – Россия Федерациясе кеременә күчерелмәгән (тапшырылмаган) очракта) чакыртып алу буенча тавыш бирү фондына иганәләрне кертергә хокуксыз.

7. Иганә керткәндә граждан түләү документында үзе турында түбәндәге белешмәләрне күрсәтә: фамилиясен, исемен, атасының исемен, туу датасын, яшәү урыны адресын, паспортының яисә граждан паспортын алмаштыручы документның сериясен һәм номерын, гражданлыгы турындагы мәгълүматны.

8. Иганә юридик зат тарафыннан кертелгәндә, түләү йөкләмәсендә аның турында түбәндәге белешмәләр күрсәтелә: салым түләүченең идентификация номеры, атамасы, теркәлү датасы, банк реквизитлары, әлеге статьяның 5 өлешендә каралган чикләүләрнең булмавы турында тамга.

9. Инициатив төркем, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучы башка төркем тавыш бирү фондына иганә керткән иганәчегә теләсә нинди иганәне, аноним иганәче тарафыннан кертелгән иганәдән тыш, кире кайтарырга хокуклы. Әгәр иганә шундый иганәне кертергә хокукы булмаган граждан яисә юридик зат тарафыннан кертелгән булса, йә иганә әлеге статьяның 7 һәм 8 өлешләрендәге таләпләрне бозып кертелгән булса, йә иганә мондый иганә кертүнең әлеге Законда каралган максималь күләменнән артыграк күләмдә кертелгән булса, чакыртып алу буенча тавыш бирү фондының махсус счетына иганә кертелгән көннән алып 10 көннән дә соңга калмыйча аны тулы күләмдә яисә иганәнең Законда билгеләнгән максималь күләменнән арткан өлешен, сәбәбен күрсәтеп, иганәчегә кайтарып бирергә тиеш. Аноним иганәче тарафыннан кертелгән иганә, чакыртып алу буенча тавыш бирү фондының махсус счетына кертелгән көннән соң 10 көннән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы бюджеты кеременә күчерелергә тиеш. Инициатив төркем, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучы башка төркем иганә кертүчеләр тарафыннан әлеге статьяның 7 яисә 8 өлешләрендә каралган һәм җитәрлек булмаган белешмәләр күрсәтелгән иганәләрне кабул иткән өчен җаваплы булмый.

10. Чакыртып алу буенча тавыш бирү фондын барлыкка китерүче барлык акчалар чакыртып алу буенча тавыш бирү фондының Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе рөхсәте белән инициатив төркемнең, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучы башка төркемнең финанс мәсьәләләре буенча вәкаләтле вәкиле тарафыннан Россия Федерациясе Саклык банкы филиалларында, ә алар булмаганда Татарстан Респу-

бликасы территориясендә урнашкан башка кредит оешмаларында ачылган махсус счетына күчерелә. Татарстан Республикасы территориясендә кредит оешмалары булмаган очракта, инициатив төркем, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучы башка төркем, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе белән килештереп, кредит оешмасын билгели, анда чакыртып алу буенча тавыш бирүнең махсус счеты ачыла.

11. Инициатив төркемнең, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучы башка төркемнең финанс мәсьәләләре буенча вәкаләтле вәкиле, Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан теркәлгәннән соң, тиешле чакыртып алу буенча тавыш бирү фондын булдыру өчен тиешле төркем Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясендә теркәлгән көннән алып 10 көн эчендә махсус счет ачарга тиеш.

12. Чакыртып алу буенча тавыш бирү фондының махсус счеты Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясеннән инициатив төркемнең, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучы башка төркемнең финанс мәсьәләләре буенча вәкаләтле вәкиленә бирелгән документ нигезендә ачыла.

13. Әлеге статьяның 10 өлешендә күрсәтелгән счетларны ачу, алып бару һәм ябу тәртибе, Татарстан Республикасы Милли банкы белән килештереп, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнә. Чакыртып алу буенча тавыш бирү фондларына акчалар керүне һәм әлеге акчаларны тотуны исәпләү һәм шул хакта хисап бирү тәртибе һәм рәвешләре Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнә.

41 статья. **Чакыртып алу буенча тавыш бирү фондлары акчаларын тоту тәртибе**

1. Чакыртып алу буенча тавыш бирү фондларының акчалары белән аларны төзегән инициатив төркем, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучы башка төркем эш итәргә хокуклы.

2. Чакыртып алу буенча тавыш бирү фондларының акчалары максатчан билгеләнештә була. Чакыртып алу буенча тавыш бирү фондларының акчаларын инициатив төркем бары тик чакыртып алу буенча тавыш бирүне үткәрү инициативасы белән чыгуга, бу инициативаны хуплап имзалар җыюга һәм тавыш бирүдә билгеле бер нәтиҗәләргә ирешүгә юнәлдерелгән эшчәнлек өчен генә, ә чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучы башка төркемнәр

чакыртып алу буенча тавыш бирүдә билгеле бер нәтиҗәләргә ирешүгә юнәлдерелгән эшчәнлек өчен генә файдалана ала.

3. Чакыртып алу буенча тавыш бирү фондлары акчалары түбәндәгеләр өчен тотылырга мөмкин:

1) чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның чакыртып алу буенча тавыш бирү инициативасын хуплап бирелгән имзаларын җыюга юнәлдерелгән оештыру-техник чараларны финанс белән тәэмин итүгә, шул исәптән тавыш бирүдә катнашучыларның имзаларын җыюга җәлеп ителгән затларның хезмәте өчен түләүгә;

2) чакыртып алу агитациясенә, шулай ук мәгълүмати һәм консультатив характердагы эшләр (хезмәт күрсәтүләр) өчен түләүгә;

3) гражданнар яки юридик затлар башкарган (күрсәткән) бүтән эшләр (хезмәт күрсәтүләр) өчен түләүгә, шулай ук инициатив төркемнең чакыртып алу буенча тавыш бирүне үткәрү инициативасын күрсәтүгә, бу инициативаны хуплап имзалар җыюга һәм чакыртып алу буенча тавыш бирүләрдә билгеле бер нәтиҗәләргә ирешүгә юнәлдерелгән эшчәнлеген, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучы башка төркемнәрнең чакыртып алу буенча тавыш бирүдә билгеле бер нәтиҗәләргә ирешүгә юнәлдерелгән эшчәнлеген башкаруга турыдан-туры бәйле бүтән төрле чыгымнарны түләүгә.

4. Гражданнар һәм юридик затлар белән чакыртып алу кампаниясенә бәйле билгеле бер эшләр башкару (хезмәтләр күрсәтү) турында шартнамәләр инициатив төркемнең, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучы башка төркемнең финанс мәсьәләләре буенча вәкаләтле вәкиле тарафыннан төзелә. Күрсәтелгән эшләрне башкарган (хезмәтләр күрсәткән) өчен инициатив төркем, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучы башка төркем һәм юридик затлар арасында үзара исәп-хисаплар бары тик акчалар күчерү тәртибендә генә башкарыла.

5. Гражданнар һәм юридик затлар инициатив төркемгә, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучы башка төркемгә финанс ярдәмен бары тик тиешле чакыртып алу буенча тавыш бирү фонды аша гына күрсәтергә хокуклы. Чакыртып алу буенча тавыш бирү фондына күчерелмәгән акчаларны чакыртып алу буенча тавыш бирүдә билгеле бер нәтиҗәгә ирешү максатларында тоту тыела. Инициатив төркемнең, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучы башка төркемнең финанс мәсьәләләре буенча вәкаләтле вәкиленең документаль расланган ризалыгыннан башка һәм тиешле чакыртып алу буенча тавыш бирү фондыннан түләүдән башка чакыртып алу буенча тавыш бирү белән турыдан-туры яисә

читләтелгән рәвештә бәйле булган һәм чакыртып алу буенча тавыш бирүләрне үткәрү инициативасын күрсәткәндә билгеле бер нәтиҗәгә ирешүгә, чакыртып алу буенча тавыш бирүләрдә билгеле бер нәтиҗәләр алуга юнәлдерелгән түләүле эшләр башкару, товарлар реализацияләү, түләүле хезмәтләр күрсәтү тыела. Юридик затлар, аларның филиаллары, вәкиллекләре һәм башка бүлекчәләре тарафыннан бушлай яисә нигезсез рәвештә төшерелгән (күтәрелгән) бәяләр буенча чакыртып алу буенча тавыш бирүләргә турыдан-туры яисә читләтелгән рәвештә бәйле булган һәм чакыртып алу буенча тавыш бирүләр үткәрү инициативасын күрсәткәндә билгеле бер нәтиҗәгә ирешүгә, чакыртып алу буенча тавыш бирүләрдә билгеле бер нәтиҗәләр алуга юнәлдерелгән эшләр башкару, хезмәтләр күрсәтү, товарлар реализацияләү тыела. Инициатив төркемгә, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучы башка төркемгә чакыртып алу буенча тавыш бирүләрдә билгеле бер нәтиҗәләргә ирешүгә юнәлдерелгән матди ярдәм күрсәтү бары тик аны тиешле чакыртып алу буенча тавыш бирү фонды акчалары исәбеннән компенсацияләгәндә генә мөмкин. Гражданның, өченче затларны җәлеп итмичә генә, чакыртып алу буенча тавыш бирүләрне әзерләү һәм үткәрү буенча үзе теләп шәхсән түләүсез эшләр башкаруы, хезмәтләр күрсәтүе рөхсәт ителә.

6. Инициатив төркем чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар имзаларын җыю буенча оештыру-техник чараларны түләү өчен чакыртып алу буенча тавыш бирү фондларына әлеге Законда билгеләнгән тәртиптә кергән акчаларны гына тотарга хокуклы. Инициатив төркем, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучы башка төркем чакыртып алу агитациясен үткәрүгә, тавыш бирүләрдә билгеле бер нәтиҗәгә ирешүгә юнәлдерелгән башка эшчәнлекне гамәлгә ашыруга түләү өчен әлеге чакыртып алу буенча тавыш бирү фондларына Законда билгеләнгән тәртиптә кергән акчаларны гына тотарга хокуклы.

7. Чакыртып алу буенча тавыш бирү фондының махсус счеты ачылган кредит оешмасы Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе, инициатив төркем, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучы башка төркем таләбе буенча бу махсус счетка акчалар керү һәм аларны тоту хакында даими рәвештә аларга мәгълүмат биреп торырга тиеш. Чакыртып алу буенча тавыш бирү фондының махсус счеты ачылган кредит оешмасы инициатив төркем, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучы башка төркем таләбе буенча – өч көн вакыт эчендә, ә тавыш бирү көненә кадәр өч көн кала кичекмәстән чакыртып алу буенча тавыш бирү фондына акчалар керүне һәм аларны тотуны раслаучы

беренчел финанс документларының таныкланган күчермәләрен тапшырырга тиеш.

8. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе чакыртып алу буенча тавыш бирү көненә кадәр даими рәвештә чакыртып алу буенча тавыш бирү фондларына акчалар керү һәм аларны тоту турындагы белешмәләрне массакүләм мәгълүмат чараларына бастырып чыгару өчен җибәреп тора. Дәүләт вакытлы матбугат басмалары редакцияләре бастырып чыгару өчен Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан җибәрелә торган әлеге белешмәләрне алынган көннән өч көн эчендә бастырып чыгарырга тиеш. Түбәндәге белешмәләр һичшиксез басылып чыгарга тиеш:

1) чакыртып алу буенча тавыш бирү фондыннан акчалар тоту буенча финанс операциясе турында, әгәр аның күләме 100 мең сумнан артыграк булса;

2) чакыртып алу буенча тавыш бирү фондына 60 мең сумнан артыграк суммада ихтыярый иганә керткән юридик затлар турында;

3) чакыртып алу буенча тавыш бирү фондына 7 мең сумнан артыграк суммада ихтыярый иганә керткән гражданнарның саны турында;

4) иганәчеләргә кире кайтарылган акчалар турында, шул исәптән аларны кире кайтару нигезләре турында;

5) чакыртып алу буенча тавыш бирү фондына кергән акчаларның гомуми суммасы турында һәм аннан тотылган акчаларның гомуми суммасы хакында.

9. Инициатив төркем, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучы башка төркем чакыртып алу буенча тавыш бирүләр нәтиҗәләре рәсми басылып чыккан көннән соң 30 көннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенә чакыртып алу буенча тавыш бирү фонды күләме турында, аны барлыкка китергән барлык чыганаклар хакында, шулай ук чакыртып алу буенча тавыш бирү фонды акчалары исәбеннән башкарылган барлык чыгымнар турында йомгаклау финанс хисабы тапшырырга тиеш. Йомгаклау финанс хисабына чакыртып алу буенча тавыш бирү фондына акчалар керүне һәм бу акчаларның тотылуын раслаучы беренчел финанс документлары өстәлеп бирелә. Йомгаклау финанс хисабына өстәлеп бирелә торган документлар исемлеге Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнә.

10. Әлеге статьяның 9 өлешендә күрсәтелгән финанс хисабының күчермәсе, аны алган көннән алып биш көннән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан массакүләм мәгълүмат чаралары редакцияләренә

бастырып чыгару өчен тапшырыла. Дәүләт вакытлы матбугат басмалары редакцияләре үзләренә Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан тапшырылган финанс хисабын (күрсәтелгән хисаптан белешмәләрне) алар кергән көннән алып биш көн эчендә бастырып чыгарырга тиеш.

11. Тавыш бирү көненнән соң инициатив төркем, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучы башка төркем чакыртып алу буенча тавыш бирү фондының махсус счетындагы тотылмый калган акчаларны чакыртып алу буенча тавыш бирү фондларына иганәләр керткән йә акчалар күчергән гражданнарга һәм юридик затларга шул акчаларга пропорциональ рәвештә күчерергә тиеш. Тавыш бирү көненнән соң 30 көн узгач кредит оешмасы Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең язма күрсәтмәсе буенча аңа тиешле акчаларны бәхәссез рәвештә Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе счетына күчерергә, ә чакыртып алу буенча тавыш бирү фондының махсус счетындагы тотылмый калган акчаларны, тавыш биргән көннән соң 60 көн узгач, Татарстан Республикасы бюджеты кеременә күчерергә тиеш.

12. Чакыртып алу буенча тавыш бирү фондлары акчаларына, күрсәтелгән фондларга кертелгән ихтыярый иганәләргә һәм күчерелгән акчаларга салым салу, шулай ук күрсәтелгән фондларның акчаларын тоту тәртибе федераль законнар белән билгеләнә.

13. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе чакыртып алу буенча тавыш бирү фонды акчаларын туплау һәм әлеге акчаларны тоту тәртибен тикшереп тора. Россия Федерациясе чикләрендә тору һәм яшәү урыны буенча Россия Федерациясе гражданнарын теркәп исәпкә алу органнары, юридик затларны дәүләт теркәвен гамәлгә ашыручы йә коммерциячел булмаган оешмаларны теркәү өлкәсендә вәкаләтле башкарма хакимият органнары, чакыртып алу буенча тавыш бирү фондларына иганәләр керткәндә яисә күчергәндә гражданнар һәм юридик затлар күрсәткән белешмәләрне Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясеннән мөрәҗәгать алганнан соң биш көн эчендә түләүсез нигездә тикшерергә һәм Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенә тикшерү нәтиҗәләре турында хәбәр итәргә тиеш.

42 статья. **Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе каршындагы контроль-ревизия хезмәте**

Чакыртып алу комиссияләренә чакыртып алу буенча тавыш бирүләрне әзерләү һәм үткәрү өчен бүлеп бирелгән акча-

ларны максатчан тотуны, шулай ук чакыртып алу буенча тавыш бирү фондлары акчаларының керү чыганакларын, аларны исәпкә алуның һәм тотуның дөреслеген контрольдә тоту, инициатив төркемнең, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучы башка төркемнең финанс хисапларын тикшерү Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе каршындагы контроль-ревизия хезмәте тарафыннан гамәлгә ашырыла.

10 бүлек. **Чакыртып алу буенча тавыш бирүне оештыру һәм тавыш бирү тәртибе, тавыш бирүдә катнашучыларның тавышларын санау, чакыртып алу буенча тавыш бирү нәтиҗәләрен билгеләү һәм аларны бастырып чыгару**

43 статья. **Чакыртып алу өчен тавыш бирү бинасы**

1. Тавыш бирү бинасы участок комиссиясе карамагына тиешле муниципаль берәмлекнең җирле администрациясе башлыгы тарафыннан түләүсез бирелә.

2. Тавыш бирү бинасында яктырту системасы куелган һәм язу әсбаплары белән, карандашлардан тыш, тәэмин ителгән яшерен тавыш бирү кабиналары яисә махсус җиһазландырылган башка урыннары булган зал булырга тиеш.

3. Тавыш бирү бинасында йә аның каршында ук участок комиссиясе мәгълүмат тактасын җиһазлый, анда чакыртып алу буенча мәгълүмат урнаштырыла, моңа чакыртып алу өчен нигез булып торучы фактны билгеләгән суд карары тексты да керә.

4. Мәгълүмат тактасында урнаштырыла торган материалларда чакыртып алу агитациясе билгеләре булмаска тиеш.

5. Чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучы сукыр инвалидларга мәгълүмат бирү өчен мәгълүмат тактасында әлеге статьяның 3 өлешендә күрсәтелгән, эре шрифт белән һәм (яисә) Брайльнең рельеф-нокта шрифтын кулланып басылган материаллар урнаштырыла. Мәгълүмат такталарында мондый материаллар урнаштырылган чакыртып алу буенча тавыш бирү участоклары Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнә.

6. Мәгълүмат тактасында чакыртып алу буенча тавыш бирү бюллетеньнәренең үрнәкләре урнаштырыла, аларда бюллетеньне (бюллетеньнәрне) тутыруның барлык вариантлары күрсәтелгән булырга тиеш.

7. Тавыш бирү бинасында тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәнең зурайтылган рәвеше урнаштырылырга тиеш, ул тавыш бирү йомгаклары ачыкланган саен шушы йомгаклар

турындагы күрсәткечләрне теркәү өчен файдаланыла. Тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәнең зурайтылган рәвеше тавыш бирү башланганчы эленеп куела, һәм ул участок комиссиясе әгъзаларының, күзәтүчеләрнең күз уңында һәм мәгълүмат күренерлек ераклыкта булырга тиеш.

8. Тавыш бирү бинасында стационар тавыш бирү әрҗәләре урнаштырыла. Тавышларны санау өчен кулланыла торган техник чаралар, шул исәптән бюллетеньнәрне эшкәртә торган программа-техник комплекслар да, стационар әрҗәләр буларак кулланылырга мөмкин.

9. Тавыш бирү бинасы чакыртып алу буенча тавыш бирү бюллетеньнәрен бирү урыннары, яшерен тавыш бирү урыннары һәм тавыш бирү әрҗәләре, тавышларны санау өчен кулланыла торган техник чаралар, алардан файдаланылган вакытта, участок комиссиясе әгъзаларына да, күзәтүчеләргә дә күренеп торырлык итеп җиһазланган булырга тиеш.

44 статья. **Чакыртып алу буенча бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы**

1. Чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегенә үзе кертелгән чакыртып алу буенча тавыш бирү участогының тавыш бирү бинасына тавыш бирү көнендә килә алмаган чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучы территория комиссиясендә (тавыш бирү көненә 45 – 20 көн кала) йә участок комиссиясендә (тавыш бирү көненә 19 – 1 көн кала) бүтән участокта тавыш бирү таныклыгын алырга һәм, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашу хокукына ия булган чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучы Татарстан Республикасы территориясендә чакыртып алу буенча тавыш бирүнең кайсы участогында булса, шул участокта тавыш бирүдә катнашырга хокуклы.

2. Чакыртып алу буенча бүтән участокта тавыш бирү таныклыгын бирү срокларын Федераль законнарда каралган очракларда билгеләгәндә, федераль закон нормалары кулланыла.

3. Бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы катгый хисап документы була һәм Татарстан Республикасының бөтен территориясендә бердәм нумерациягә ия. Бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы әлеге Законга 2 нче кушымтада билгеләнгән рәвештә әзерләнә. Бүтән участокта тавыш бирү таныклыгының тексты, аларның саны, бүтән участокта тавыш бирү таныклыгын бирү реестры рәвеше, тавыш бирү көненә кадәр 50 көннән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссия-

се тарафыннан раслана. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе шулай ук бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларын әзерләгәндә аларны ясалма таныклыклардан яклау ысулларын да билгели.

4. Бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларын ясалма таныклыклардан яклау максатларында, аларны әзерләгәндә су билгеләре булган һәм (яисә) типография ысулы белән микрошрифтлы язу һәм (яисә) саклау челтәре һәм (яисә) башка махсус саклау элементлары булган кәгазь кулланыла.

5. Бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларын әзерләүгә заказ урнаштыру Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан аның карары нигезендә үзәкләштерелеп гамәлгә ашырыла.

6. Чакыртып алу буенча әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән комиссияләр чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучының бүтән участокта тавыш бирү таныклыгын таләп итүенең сәбәбен күрсәткән язма гаризасы нигезендә бүтән участокта тавыш бирү таныклыгын чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучының шәхсән үзенә йә нотариаль таныкланган ышанычнамә нигезендә аның вәкиленә тапшыра. Ышанычнамә шулай ук стационар дәвалау-профилактика учреждениесе администрациясе тарафыннан (әгәр чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучы шул учреждениедә дәвалана торган булса), җинаять кылуда шикле яисә гаепләнүче затларны сак астында тота торган учреждение администрациясе тарафыннан (әгәр чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучы шикле яисә гаепләнүче зат буларак шул учреждениедә тотылса) таныкланырга мөмкин.

7. Бүтән участокта тавыш бирү таныклыгын тапшыручы комиссия рәисе, рәис урынбасары, секретаре яисә комиссиянең хәлиткеч тавыш хокукына ия башка әгъзасы таныклыкка чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучының фамилиясен, исемен һәм атасының исемен, паспортның яисә граждан паспортын алмаштыручы документның сериясен һәм номерын, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучы чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегенә кертелгән чакыртып алу буенча тавыш бирү участогы номерын, участок комиссиясе адресын, территориясендә чакыртып алу буенча тавыш бирү участогы урнашкан муниципаль берәмлек исемен, бүтән участокта тавыш бирү таныклыгын тапшырган комиссия исемен кертә. Бүтән участокта тавыш бирү таныклыгын тапшыручы комиссия рәисе, рәис урынбасары, секретаре яисә комиссиянең хәлиткеч тавыш хокукына ия башка әгъзасы бүтән участокта тавыш бирү таныклы-

гында үз фамилиясен һәм инициалларын, бүтән участокта тавыш бирү таныклыгын бирү датасын күрсәтә, имза куя һәм тиешле комиссия мөһерен суга.

8. Чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучы бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы алганда бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары бирү реестрының яисә чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегенең тиешле графаларында паспортының яисә граждан паспортын алмаштыручы документның сериясен һәм номерын күрсәтә һәм имза сала. Башка участокта тавыш бирү таныклыкларын тапшыру реестрында чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучының яшәү урыны адресы күрсәтелергә тиеш. Бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы ышанычнамә кәгазе нигезендә алынган очракта, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучы вәкиле тарафыннан бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары бирү реестрының яисә чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегенең тиешле графаларында чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучы паспортының яисә граждан паспортын алмаштыручы башка документның сериясе һәм номеры күрсәтелә, шулай ук чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучы вәкиле үз фамилиясен, исемен һәм атасының исемен, паспортының яисә граждан паспортын алмаштыручы башка документның сериясен һәм номерын күрсәтә һәм имза сала. Шуннан соң чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучы вәкиленнән ышанычнамә кәгазе алына һәм тиешенчә бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары бирү реестрына, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегенә кертелә.

9. Чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыга бүтән участокта тавыш бирү таныклыгын тапшыручы комиссия рәисе, рәис урынбасары, секретаре яисә территория комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия башка әгъзасы бүтән участокта тавыш бирү өчен бирелгән таныклык номерын бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларын бирү реестрының тиешле графасында күрсәтә һәм имза куя. Тавыш бирү көненә кадәр 20 көн кала территория комиссиясе участок комиссияләренә чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегенең беренче нөсхәсе белән бергә бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларын бирү реестрыннан расланган өземтәләрне җибәрә, аларда чакыртып алу буенча тавыш бирүнең тиешле участоклары территорияләрендә теркәлгән бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары алган чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар турында белешмәләр күрсәтелә. Тиешле өземтә нигезендә участок комис-

сиясе әгъзасы, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегенең «Махсус тамгалар» графасына бирелгән бүтән участокта тавыш бирү таныклыгының номерын күрсәтеп, «Территория комиссиясендә ___ номерлы бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы алды» тамгасын куя.

10. Чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыга участок комиссиясендә бүтән участокта тавыш бирү таныклыгын тапшырганда, комиссия рәисе, рәис урынбасары, секретаре яисә комиссиянең хәлиткеч тавыш хокукына ия башка әгъзасы чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегенең «Махсус тамгалар» графасына бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы номерын күрсәтеп, «___ номерлы бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы алды» тамгасын куя.

11. Бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы алган (шул исәптән ышанычнамә кәгазе нигезендә вәкиле аша) чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучы чакыртып алу буенча тиешле тавыш бирү участогында чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегеннән участок комиссиясе тарафыннан төшереп калдырыла һәм, тавыш бирү йомгаклары турында участок комиссиясе беркетмәсе төзелгәндә, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә теркәлгән катнашучылар санында исәпкә алынмый.

12. Бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы кабат бирелми. Бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы югалган очракта дубликаты бирелми.

13. Бүтән участокта тавыш бирүнең файдаланылмаган таныклыклары тавыш бирү көнендә тавыш бирү вакыты башланганчы юкка чыгарыла. Федераль законнар нигезендә, бүтән участокта тавыш бирүнең файдаланылмаган таныклыкларын юкка чыгару турында, аларның саны, шулай ук бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларының номерлары күрсәтелгән белешмәләр Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе раслаган рәвештә тиешле комиссия тарафыннан төзелгән актка кертелә.

14. Тавыш бирү көнендә чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучы, бүтән участокта тавыш бирү таныклыгын күрсәтеп, тавыш бирү көнендә үзе булачак чакыртып алу буенча тавыш бирү участогында чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегенә өстәмә рәвештә кертелә. Чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегенең «Махсус тамгалар» графасына участок комиссиясе тарафыннан чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучы тарафыннан күрсәтелгән бүтән участокта тавыш бирү таныклыгының номерын күрсәтеп, «___ номерлы бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы буенча тавыш

бирде» тамгасы куела. Шуннан соң чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыдан бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы кире алына. Чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларны чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегенә кертү өчен нигез булган бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары күрсәтелгән исемлек белән бергә саклананалар.

15. Бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы бланкы югалган очракта, бу югалту фактын билгеләгән комиссия кичекмәстән тиешле акт төзи һәм карар кабул итә, анда бүтән участокта тавыш бирү таныклыгының югалган бланкы номеры, бланкны югалту факты һәм югалту сәбәбе күрсәтелә. Әлеге карар шул ук көнне территория комиссиясенә һәм Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенә җиткерелә. Әлеге карар нигезендә Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тиешле бүтән участокта тавыш бирү таныклыгын гамәлдән чыккан дип таный, шул хакта кичекмәстән барлык түбәндәге комиссияләргә хәбәр итә. Гамәлдән чыккан бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыны чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегенә кертү өчен нигез була алмый. Чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучы мондый бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы күрсәткәндә, ул кире алынырга тиеш.

16. Федераль закон нигезендә комиссияләргә бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларын тапшыру һәм бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларын исәпкә алу тәртибе, шул исәптән «Сайлаулар» ДАС кулланып, Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан раслана.

### 45 статья. **Чакыртып алу буенча тавыш бирү бюллетене**

1. Чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашу өчен чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучы чакыртып алу буенча тавыш бирү бюллетене (алга таба шулай ук – бюллетень) ала.

2. Бюллетеньнәр бары тик Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе күрсәтмәсе буенча гына әзерләнә. Бюллетеньнәргә номерлар сугу рөхсәт ителми. Әзерләнгән бюллетеньнәр саны теркәлгән чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар санынннан 1,5 проценттан да артык булмаска тиеш. Чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучы сукыр инвалидларга ярдәм итү

өчен, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе карары белән, бюллетеньне мөстәкыйль тутыру өчен махсус, шул исәптән Брайльнең рельеф-нокталы шрифтын кулланып, трафаретлар әзерләнә. Мондый трафаретлар әзерләнә торган чакыртып алу буенча тавыш бирү участоклары Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнә.

3. Бюллетеньнәрне ясалма бюллетеньнәрдән яклау максатларында, аларны әзерләгәндә су билгеләре булган яисә типография ысулы белән микрошрифтлы язу төшерелгән һәм (яисә) саклау челтәре булган кәгазь яисә бу максатларда махсус тамга (марка) кулланыла. Махсус тамгаларны (маркаларны) әзерләү һәм куллану тәртибе, аларның саны, шулай ук чакыртып алу буенча тавыш бирүнең югарырак комиссияләре тарафыннан түбәнгерәк комиссияләргә махсус тамгалар (маркалар) тапшыруга куела торган таләпләр, тавыш бирү көненә кадәр 50 көннән дә соңга калмыйча, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан раслана.

4. Бюллетеньнең рәвеше һәм тексты, бюллетеньнәр саны, шулай ук бюллетеньнәрнең әзерләнүен тикшереп тору тәртибе тавыш бирү көненә кадәр 20 көннән дә соңга калмыйча Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан раслана. Бюллетень тексты бары тик бер якта гына урнаштырылырга тиеш. Кабат тавыш бирүләр уздырган очракта, бюллетень тексты, бюллетеньнәр саны Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе кабат тавыш бирүләрне үткәрү турында карар кабул иткән вакытта раслана.

5. Чакыртып алу буенча тавыш биргәндә бюллетеньдә тавыш бирүгә чыгарылган мәсьәлә тексты бастырыла һәм «Чакыртып алу өчен» һәм «Чакыртып алуга каршы» сүзләре белән тавыш бирүченең ихтыяр белдерү вариантлары күрсәтелә, аларның уң ягында буш квадратлар урнаша. Бюллетеньдә аны тутыру тәртибе аңлатылган булырга тиеш.

6. Бюллетеньнәр рус телендә бастырыла. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе карары буенча бюллетеньнәр рус һәм татар телләрендә, ә кирәк очракларда – Россия Федерациясе халыклары күпләп яши торган территорияләрдә шул халыклар телләрендә бастырыла. Әгәр чакыртып алу буенча тавыш бирү участогы өчен бюллетеньнәр ике яки аннан да күбрәк телдә бастырылса, рус телендәге текст һәр сайлау бюллетенендә урнаштырылырга тиеш.

7. Полиграфия оешмасы тарафыннан әзерләнгән бюллетеньнәр Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең

хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзаларына акт буенча тапшырыла, анда актны төзү датасы һәм вакыты, шулай ук тапшырылучы бюллетеньнәр саны күрсәтелә. Заказга туры килә торган санда, төргәкләргә төрелгән бюллетеньнәр тапшырылганнан соң, полиграфия оешмасы хезмәткәрләре артык бюллетеньнәрне (алар ачыкланганда) юкка чыгаралар, бу хакта акт төзелә. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе, тиешле полиграфия оешмасыннан бюллетеньнәр алырга ике көннән дә соңга калмыйча, бюллетеньнәрне Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе әгъзаларына тапшыру, бюллетеньнәрне юкка чыгару урыны һәм вакыты турында карар кабул итәргә тиеш. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең теләсә кайсы әгъзасы йә инициатив төркем, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучы нинди дә булса башка төркем вәкиле әлеге өлештә күрсәтелгән актларга имза салырга хокуклы.

8. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе, полиграфия оешмасы аңа бюллетеньнәрне тапшырганнан соң, бюллетеньнәрне бүлү турындагы үз карары нигезендә, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнгән вакытта аларны акт буенча территория комиссияләренә тапшыра. Территория комиссияләре бюллетеньнәрне шул ук тәртиптә участок комиссияләренә тапшыра. Чакыртып алу буенча югарырак комиссия тарафыннан чакыртып алу буенча түбәнгерәк комиссиягә бюллетеньнәрне тапшыру турында ике нөсхәдә акт төзелә, анда актны төзү датасы һәм вакыты, шулай ук тапшырылучы бюллетеньнәр саны күрсәтелә.

9. Участок комиссияләренә бюллетеньнәр тапшыру тавыш бирү көненә кадәр бер көннән дә соңга калмыйча гамәлгә ашырыла. Чакыртып алу буенча тавыш бирү өчен һәр участокка тапшырыла торган бюллетеньнәр саны әлеге чакыртып алу буенча тавыш бирү участогында теркәлгән чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар саныннан 0,5 проценттан артык (әмма ике бюллетеньнән дә кимрәккә түгел) һәм бюллетеньнәр тапшыру көненә тиешле участокта чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлекләренә кертелгән чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар саныннан 70 проценттан кимрәк булырга тиеш түгел. Бюллетеньнәрне участок комиссияләренә тапшырганда алар аерым-аерым санала һәм аларның браклары ачыклана, бу очракта брак дип танылган бюллетеньнәр (ачыкланган очракта) территория комиссиясе әгъзалары тарафыннан юкка чыгарыла, бу хакта акт төзелә.

10. Чакыртып алу буенча югарырак комиссия тарафыннан чакыртып алу буенча түбәнгерәк комиссиягә бюллетеньнәрне тапшырганда, аларның бракларын ачыклаганда һәм аларны юкка чыгарганда әлеге комиссияләрнең әгъзалары, шулай ук инициатив төркем, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучы башка төркемнәр вәкилләре катнашырга хокуклы. Санап үтелгән затларга бюллетеньнәрне тапшыру урыны һәм вакыты турында тиешле чакыртып алу комиссиясе тарафыннан хәбәр ителә, әлеге комиссия инициатив төркемнең, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучы башка төркемнең кимендә бер вәкиленә бюллетеньнәр тапшырганда катнашу мөмкинлеге тудырырга тиеш. Бу чакта санап үтелгән затларның теләсә кайсы бюллетеньнәрне тапшыру, шулай ук аларның бракларын ачыклау һәм юкка чыгару (әгәр булса) вакытында төзелә торган актларга имза салырга хокуклы.

11. Бюллетеньнәрне тапшыра, ала һәм саклый торган чакыртып алу комиссияләре рәисләре бюллетеньнәрне тапшыру һәм аларның саклanышы өчен җаваплы була.

12. Участок комиссиясе тарафыннан алынган барлык бюллетеньнәрнең өске уң почмагында участок комиссиясенең ике әгъзасы имза сала, алар участок комиссиясенең мөһере белән таныклана.

13. Тавыш бирү көнендә, тавыш бирү вакыты тәмамланганнан соң, чакыртып алу комиссияләрендәге файдаланылмый калган бюллетеньнәр санала һәм юкка чыгарыла. Участок комиссияләрендә бу процедура әлеге Законның 49 статьясындагы 3 өлеше нигезендә гамәлгә ашырыла. Башка чакыртып алу комиссияләрендә файдаланылмый калган бюллетеньнәрне юкка чыгарганда акт төзелә, анда юкка чыгарылган бюллетеньнәрнең саны күрсәтелә. Бюллетеньнәрне юкка чыгарганда әлеге Законның 22 статьясындагы 3 өлешендә күрсәтелгән затлар катнашырга хокуклы. Бу бюллетеньнәр чакыртып алу комиссиясенең башка документлары белән бергә чакыртып алу комиссиясе секретарендә саклана.

14. Чакыртып алу буенча тавыш бирүләрне электрон тавыш бирү комплексын кулланып үткәргәндә, электрон бюллетень кулланыла. Электрон бюллетень тексты һәм рәвеше тавыш бирү көненә кадәр 20 көннән дә соңга алмыйча Татарстан Республикасы Үзәк Сайлау комиссиясе тарафыннан раслана һәм әлеге статьяның 5 һәм 6 өлешләрендә каралган таләпләргә туры килергә тиеш. Кабат тавыш бирүләр уздырган очракта электрон бюллетень тексты Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе ка-

бат тавыш бирүләрне үткәрү турында карар кабул иткән вакытта раслана.

46 статья. **Тавыш бирү тәртибе**

1. Чакыртып алу буенча тавыш бирү 8 сәгатьтән алып 20 сәгатькә кадәр уздырыла. Чакыртып алу буенча тавыш бирү участогы территориясендә эш вакытлары тавыш бирү вакытына туры килә торган (предприятиеләрдә өзлексез эш циклы яисә вахта ысулы белән эшләгәндә) чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның яшәү урыны урнашкан булса, бу чакыртып алу буенча тавыш бирү участогында тавыш бирүне башлау вакыты Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе карары белән иртәрәк вакытка, ләкин ике сәгатьтән дә иртәрәк түгел, күчерелергә мөмкин.

2. Тавыш бирү вакыты һәм урыны турында территория һәм участок комиссияләре, тавыш бирү көненә кадәр 20 көннән дә соңга калмыйча, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларга массакүләм мәгълүмат чаралары аша яисә бүтән ысуллар белән хәбәр итәргә тиеш.

3. Тавыш бирү көнендә тавыш бирү башланыр алдыннан участок комиссиясе рәисе участок комиссиясе әгъзаларына, шундагы чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларга, әлеге Законның 22 статьясындагы 3 өлешендә күрсәтелгән затларга тавыш бирү өчен әзерләнгән буш әрҗәләрне (тавышларны санау өчен техник чаралар кулланылганда — аларның бүлемнәрен) күрсәтә, шуннан соң әрҗәләр бикләнә һәм аларга участок комиссиясе мөһере сугыла.

4. Чакыртып алу буенча тавыш бирүдә һәр катнашучы шәхсән тавыш бирә, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә башка катнашучылар өчен тавыш бирү рөхсәт ителми.

5. Чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегенә кертелгән чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларга бюллетеньнәр паспорт яисә граждан паспортын алыштыручы документны күрсәткәч бирелә, әгәр чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучы бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы буенча тавыш бирсә, – шулай ук бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы да күрсәтелә.

6. Чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучы бюллетеньне алганда чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегендә паспортының яисә граждан паспортын алмаштыручы документның сериясен һәм номерын куя. Чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучы ризалыгы йә үтенече буенча, ул күрсәткән

паспортның яисә граждан паспортын алмаштыручы документның сериясе һәм номеры чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегенә участок комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзасы тарафыннан кертелергә мөмкин. Тавыш бирүдә катнашучы язманың дөреслеген тикшерә һәм чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегенең тиешле графасында бюллетень алуын раслап имза куя. Бүтән участокта тавыш бирү таныклыгы буенча тавыш биргән очракта, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегендә өстәмә тамгалар куела. Чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыга бюллетень биргән участок комиссиясе әгъзасы шулай ук чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегенең тиешле графасында имза куя.

7. Тавыш бирү чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучы тарафыннан ихтыяр белдерүнең бюллетеньдә үзе хуплаган вариантка туры килә торган квадратта теләсә нинди тамга кую юлы белән башкарыла.

8. Бюллетень әлеге статьяның 10 өлешендә күрсәтелгән очрактан тыш, махсус җиһазландырылган кабинада, башка затларның булуы рөхсәт ителми торган бүтән махсус җиһазландырылган урында чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучы тарафыннан тутырыла.

9. Әгәр чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучы бюллетеньне тутырганда хата ясадым дип санаса, ул, бозылган бюллетень урынына яңасын бирүне үтенеп, чакыртып алу комиссиясенең бюллетень биргән әгъзасына мөрәҗәгать итәргә хокуклы. Чакыртып алу комиссиясе әгъзасы чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыга яңа бюллетень бирә, мондый чакта ул чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегендә әлеге чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучы фамилиясе янында тиешле тамга куя. Чакыртып алу комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзасы бозылган бюллетеньгә тиешенчә язып куя һәм аны имзасы белән таныклый, бозылган бюллетень шулай ук участок комиссиясе секретаре имзасы белән таныклана, шуннан соң кичекмәстән юкка чыгарыла.

10. Бюллетень алганда мөстәкыйль рәвештә имза салу яисә бюллетень тутыру, электрон тавыш бирүдә катнашу мөмкинлеге булмаган чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучы моның өчен комиссия әгъзасы, теркәлгән кандидат, инициатив төркем әгъзасы яисә вәкаләтле вәкиле, күзәтүче булмаган бүтән чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучы ярдәменнән файдаланырга хокуклы. Мондый очракта чакыртып алу буенча тавыш бирүдә кат-

нашучы бюллетень тутыру өчен, электрон тавыш бирүдә катнашу өчен ярдәмнән файдаланырга нияте барлыгы турында комиссиягә телдән хәбәр итә. Бу очракта чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегенең тиешле графасында (графаларында) чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыга ярдәм итүче затның фамилиясе, исеме, атасының исеме, паспортының яисә граждан паспортын алмаштыручы документның сериясе һәм номеры күрсәтелә.

11. Тутырылган бюллетеньнәр чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучы тарафыннан мөһерләнгән (пломбаланган) тавыш бирү әрҗәләренә йә тавышларны санауның техник чараларына, алар кулланылган очракта, төшереләләр.

12. Закон бозылган очракта, участок комиссиясе әгъзасы комиссия эшендә катнашудан кичекмәстән читләштерелә, ә күзәтүче һәм башка затлар тавыш бирү бинасыннан чыгарылалар. Бу хакта дәлилләнгән карар участок комиссиясе яисә югарырак комиссия тарафыннан язма рәвештә кабул ителә. Хокук саклау органнары әлеге карарның үтәлешен тәэмин итәләр һәм участок комиссиясенең читләштерелгән әгъзасын, шулай ук бинадан чыгарылган күзәтүчене һәм башка затларны федераль законнарда каралган җаваплылыкка җәлеп итү чараларын күрәләр.

13. Инициатив төркем, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның башка төркемнәре әгъзаларына һәм вәкаләтле вәкилләренә, шулай ук гамәлгә куючылары, милекчеләре, хуҗалары һәм (яисә) идарә органнары яисә тикшереп тору органнары әгъзалары күрсәтелгән затлар һәм оешмалар булган оешмаларга, шушы затларның һәм оешмаларның үтенече яисә кушуы буенча эш итүче башка физик һәм юридик затларга чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларны тавыш бирүдә катнашу өчен китерүне тәэмин итүгә юнәлдерелгән теләсә нинди чаралар күрү тыела.

14. Чакыртып алу буенча тавыш бирүне үткәргәндә, кәгазь чыганакларда әзерләнгән бюллетеньнәр белән тавыш бирү урынына электрон тавыш бирү үткәрелә ала. Электрон тавыш бирү үткәрелә торган чакыртып алу буенча тавыш бирү участокларының гомуми саны Татарстан Республикасы территориясендә оешкан чакыртып алу буенча тавыш бирү участоклары санының 1 процентыннан артмаска тиеш. Электрон тавыш бирүне үткәрү турында карар Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе яисә аның кушуы буенча, Россия Федерациясе субъектында референдум вакытында электрон тавыш бирүне үткәрү өчен билгеләнгән

тәртиптә, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан кабул ителә.

47 статья. **Тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш бирү тәртибе**

1. Участок комиссиясе шушы чакыртып алу буенча тавыш бирү участогында чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегенә кертелгән һәм тавыш бирү бинасына нигезле сәбәпләр (сәламәтлек торышы, инвалидлыгы буенча) буенча мөстәкыйль рәвештә килә алмаучы чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларга тавыш бирүдә катнашу мөмкинлеген тәэмин итәргә тиеш. Участок комиссиясе шулай ук шушы чакыртып алу буенча тавыш бирү участогында чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегенә кертелгән һәм шикле, гаепле затларны сак астында тоту урыннарында булган чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларга тавыш бирүдә катнашу мөмкинлеген тәэмин итә.

2. Тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш бирү бары тик тавыш бирү көнендә генә һәм чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучының үзенә тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш бирү мөмкинлеге тудыру турындагы язма гаризасы яисә телдән мөрәҗәгате (шул исәптән башка затлар аша тапшырылган) нигезендә генә үткәрелә. Участок комиссиясе бирелгән барлык гаризаларны (телдән мөрәҗәгатьләрне) махсус реестрда терки, ул, тавыш бирү тәмамланганнан соң, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлеге белән бергә саклана.

3. Әлеге статьяның 2 өлешендә каралган реестрда телдән мөрәҗәгатьне теркәгәндә, аның керү вакыты, тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш бирергә теләге барлыгы турында мөрәҗәгать иткән чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучының фамилиясе, исеме, атасының исеме, яшәү урыны адресы күрсәтелә, шулай ук мөрәҗәгатьне кабул итеп алган комиссия әгъзасының имзасы куела. Әгәр мөрәҗәгать башка зат аша тапшырылган булса, реестрда шулай ук әлеге затның фамилиясе, исеме, атасының исеме һәм яшәү урыны адресы күрсәтелә. Комиссия әгъзалары чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучы янына килгәч, әлеге мөрәҗәгать язма гариза белән раслана.

4. Тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш бирү мөмкинлеге тудыру турындагы гаризада (телдән мөрәҗәгатьтә) чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучының тавыш бирү бинасына килә алмау сәбәбе күрсәтелергә тиеш. Гаризада чакыртып алу буенча

тавыш бирүдә катнашучының фамилиясе, исеме һәм атасының исеме, яшәү урыны адресы күрсәтелергә тиеш.

5. Участок комиссиясенә әлеге статьяның 4 өлешендә күрсәтелгән гаризалар (телдән мөрәҗәгатьләр), участок комиссиясе төзелгәннән соң теләсә кайсы вакытта, ләкин тавыш бирү вакыты тәмамланырга алты сәгатьтән дә соңга калмыйча, тапшырылырга мөмкин. Күрсәтелгән вакыттан соң кергән гаризалар (телдән мөрәҗәгатьләр) канәгатьләндерелми, бу хакта чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыга йә мөрәҗәгатьне тапшыруга ярдәм иткән затка гариза (телдән мөрәҗәгать) тапшыру вакытында телдән хәбәр ителә.

6. Участок комиссиясе рәисе участок комиссиясе әгъзаларының тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш бирүне уздырулары турында, мондый тавыш бирүне үткәрү өчен чыгып китәргә 30 минуттан да соңга калмыйча, игълан итәргә, шулай ук хәлиткеч тавыш бирү хокукына ия участок комиссиясе әгъзаларына һәм күзәтүчеләргә аны үткәргәндә катнашуны тәкъдим итәргә тиеш.

7. Участок комиссиясе тавыш бирү бинасына чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның мөстәкыйль килә алмау сәбәбенең нигезсез булуын танырга һәм шул сәбәпле чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыга тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш бирүне үткәрүдән баш тартырга хокуклы. Мондый тавыш бирүне үткәрүдән баш тарту турындагы карарны кабул итү хакында комиссия чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыга кичекмәстән хәбәр итә.

8. Участок комиссиясендә тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш бирү өчен тиешле санда күчерелмә әрҗәләр булырга тиеш. Мондый әрҗәләрнең саны турыдан-туры югарырак комиссия карары белән билгеләнә. Чакыртып алу буенча тавыш бирү һәм төрле дәрәҗәдәге сайлауларда һәм (яисә) референдумнарда тавыш бирү көннәре туры килгән очракта, карар югарырак дәрәҗәдәге сайлауларны (референдумны) әзерләүдә һәм үткәрүдә катнашучы чакыртып алу комиссиясе тарафыннан кабул ителә. Бу чакта чакыртып алу буенча бер үк тавыш бирү участогында тавыш бирү көнендә тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш бирү өчен кулланыла торган күчерелмә әрҗәләрнең максималь саны, чакыртып алу буенча тавыш бирү участогы территориясендә теркәлгән чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар санына бәйле рәвештә, түбәндәгечә төзелә:

1) чакыртып алу буенча тавыш бирүдә 501 катнашучыга кадәр – тавыш бирү өчен 1 күчерелмә әрҗә;

2) чакыртып алу буенча тавыш бирүдә 501 катнашучыдан алып чакыртып алу буенча тавыш бирүдә 1001 катнашучыга кадәр – тавыш бирү өчен 2 күчерелмә әрҗә;

3) чакыртып алу буенча тавыш бирүдә 1000 катнашучыдан артыграк – тавыш бирү өчен 3 күчерелмә әрҗә.

9. Әлеге статьяның 8 өлешендә күрсәтелгән тиешле комиссия карары белән тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш бирү өчен кулланыла торган күчерелмә әрҗәләрнең әлеге статьяның 8 өлешендәге 1 һәм 2 пунктларында күрсәтелгән саны, түбәндәге шартларның берсе генә булса да, арттырылырга мөмкин, әмма 1 күчерелмә әрҗәдән күбрәккә арттырылмаска тиеш:

1) чакыртып алу буенча тавыш бирү участогына берничә торак пункт территориясе керсә һәм тавыш бирү урыны урнашкан торак пункт башка торак пунктларга тавыш бирү вакыты эчендә җәяү барып җитәрлек булмаса;

2) сайлау участогы төзелмәгән сайлаучыларның вакытлыча булу урыны чакыртып алу буенча тавыш бирү участогы территориясендә урнашкан булса;

3) чакыртып алу буенча тавыш бирү участогы территориясендә чакыртып алу буенча тавыш бирүдә 80 яшьтән өлкәнрәк һәм (яисә) инвалид булган 50дән артык катнашучы теркәлгән булса.

10. Участок комиссиясенең гаризалар (телдән мөрәҗәгатьләр) буенча чыгучы әгъзалары бюллетеньнәрне алалар һәм аларны алу хакында имза куялар. Алына торган бюллетеньнәрнең гомуми саны чыгып китү мизгеленә алынган гаризалар (телдән мөрәҗәгатьләр) санынннан 5 проценттан да артык булмаска тиеш (әмма кимендә ике бюллетень). Тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш бирүне участок комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия кимендә ике әгъзасы уздыра, алар үзләре белән участок комиссиясендә алдан мөһерләнгән (пломбаланган) күчерелмә тавыш бирү әрҗәсе, тиешле санда билгеләнгән рәвештәге бюллетеньнәр, әлеге статьяның 2 өлешендә каралган реестр йә аннан чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучы турында һәм тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш бирү мөмкинлеге тудыру турында алынган гариза (телдән мөрәҗәгать) хакында кирәкле белешмәләре булган таныкланган өземтә, тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш бирү мөмкинлеге тудыру турында чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылардан кергән гаризаларны, шулай ук чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучы бюллетенен тутыру өчен кирәкле язу әйберләре (карандашлардан гайре) алырга тиешләр. Әгәр тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш

бирүне уздырганда әлеге статьяның 16 өлешендә күрсәтелгән затлардан кимендә икесе катнашса, тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш бирүне участок комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия бер әгъзасы гына да уздырырга мөмкин.

11. Тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш бирү әлеге Законның 46 статьясында каралган таләпләр үтәлгән килеш гамәлгә ашырыла.

12. Тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш бирү мөмкинлеге тудыру турындагы гаризада чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучы паспортының яисә граждан паспортын алмаштыручы документның сериясен һәм номерын куя һәм, бюллетень алуын таныклап, үзенең имзасын куя. Чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучы ризалыгы белән йә аның үтенече буенча, ул күрсәткән паспортның яисә граждан паспортын алмаштыручы документның сериясе һәм номеры участок комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзасы тарафыннан әлеге гаризага кертелергә мөмкин. Участок комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзалары үз имзалары белән гаризада бюллетень бирү фактын таныклыйлар. Гаризага шулай ук бозылган бюллетень урынына яңасын алу турында да тамга салына, – алынган бюллетеньнәрнең гомуми саны күрсәтелә.

13. Чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучының бюллетень алганда инвалидлык яисә сәламәтлек торышы буенча мөстәкыйль рәвештә имза салу яисә бюллетень тутыру мөмкинлеге булмаган очракта, ул әлеге Законның 46 статьясындагы 10 өлешендә билгеләнгән тәртиптә чакыртып алу буенча тавыш бирүдә башка катнашучы ярдәменнән файдаланырга хокуклы.

14. Участок комиссиясенең чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар гаризалары (телдән мөрәҗәгатьләре) буенча чыккан әгъзалары бюллетеньнәрне бары тик әлеге статьяның 2 өлеше нигезендә гаризалары (телдән мөрәҗәгатьләре) реестрда теркәлгән чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларга гына бирергә хокуклы.

15. Тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш биргән чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучы паспортының яисә граждан паспортын алыштыручы документның сериясе һәм номеры участок комиссиясенең чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар гаризалары (телдән мөрәҗәгатьләре) буенча чыккан хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзалары тарафыннан чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегенә кертелә. Бер үк вакытта чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегенең тиешле графасында (графаларында) «Тавыш бирү

бинасыннан читтә тавыш бирде» дигән махсус тамга салына, шулай ук күрсәтелгән комиссия әгъзаларының имзалары куела.

16. Тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш бирүне уздырганда, чакыртып алу комиссиясенең киңәш бирү тавышы хокукына ия әгъзалары, күзәтүчеләр катнашырга хокуклы. Мондый чакта участок комиссиясе чакыртып алу комиссиясенең киңәш бирү тавышы хокукына ия булган кимендә ике әгъзасына, инициатив төркем, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның башка төркемнәре, иҗтимагый берләшмәләр тарафыннан билгеләп куелган күзәтүчеләргә тавыш бирүне үткәрү урынына бару буенча участок комиссиясенең тавыш бирүне уздыру өчен чыгучы әгъзалары белән бертигез мөмкинлекләр тудырырга тиеш.

17. Тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш бирүне оештыру чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучының чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашуга хокукларын бозу, шулай ук аның ихтыяр белдерүен бозып күрсәтү ихтималын калдырмаска тиеш.

18. Тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш бирү мөмкинлеген тудыруны сорап гариза (телдән мөрәҗәгать) биргән чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучы янына тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш бирүне уздыру өчен участок комиссиясе әгъзалары киткәннән соң бу тавыш бирүдә катнашучы тавыш бирү бинасына килгән очракта, шушы чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучы гаризасы (телдән мөрәҗәгате) буенча киткән чакыртып алу комиссиясе әгъзалары кире әйләнеп кайтканчы һәм әлеге чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучының тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш бирмәү факты билгеләнгәнче, участок комиссиясенең тиешле әгъзасы шушы чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыга тавыш бирү бинасында бюллетень бирергә хокуксыз.

19. Һәр күчерелмә тавыш бирү әрҗәсеннән файдаланып тавыш бирү тәмамлангач, участок комиссиясе акт төзи, аңа тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш бирүне уздырган киңәш бирү тавышы хокукына ия участок комиссиясе әгъзаларына бирелгән бюллетеньнәр саны, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш бирү мөмкинлеген тудыру турындагы язма гаризалары саны, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларга бирелгән һәм кире кайтарылган (файдаланылмаган, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар тарафыннан бозылган) бюллетеньнәр саны, шулай ук участок комиссиясенең тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш бирүне уздырган хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзалары, участок комиссиясенең киңәш бирү тавышы хокукына ия әгъзалары һәм

тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш бирүне уздырганда катнашкан күзәтүчеләр турында белешмәләр күрсәтелә.

48 статья. **Тавыш бирү йомгаклары турында участок комиссиясе беркетмәсе**

1. Участок комиссиясе тавыш бирү йомгаклары турындагы карарын чакыртып алу буенча тиешле участокта тавыш бирү йомгаклары турында беркетмә белән рәсмиләштерә.

2. Тавыш бирү йомгаклары турында беркетмә бер биттә төзелергә тиеш. Искәрмә рәвешендә ул бердән артыграк битләрдә дә төзелә ала, бу чакта һәр биткә номерлар сугылган, участок комиссиясенең шунда булган хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзаларының барысы тарафыннан да имзаланган һәм участок комиссиясе мөһере сугылган булырга тиеш. Тавыш бирү йомгаклары турында беркетмәдә түбәндәгеләр булырга тиеш:

1) нөсхә номеры;

2) тавыш бирү исеме һәм датасы;

3) «Беркетмә» сүзе;

4) чакыртып алу буенча тавыш бирү участогының номерын күрсәтеп, тавыш бирү бинасы адресы;

5) түбәндәге эзлеклелектәге беркетмә юллары:

1 юл: тавыш бирү тәмамланган вакытка чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның исемлеккә кертелгән саны;

2 юл: участок комиссиясе алган бюллетеньнәр саны;

3 юл: тавыш бирү көнендә тавыш бирү бинасында чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларга бирелгән бюллетеньнәр саны;

4 юл: тавыш бирү көнендә тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш биргән чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларга бирелгән бюллетеньнәр саны;

5 юл: юкка чыгарылган бюллетеньнәр саны;

6 юл: тавыш бирү өчен күчерелмә әрҗәләрдәге бюллетеньнәр саны;

7 юл: тавыш бирү өчен стационар әрҗәләрдәге бюллетеньнәр саны;

8 юл: гамәлгә яраксыз бюллетеньнәр саны;

9 юл: гамәлгә яраклы бюллетеньнәр саны;

9 а юл: участок комиссиясе тарафыннан алынган башка участокта тавыш бирү таныклыклары саны;

9 б юл: чакыртып алу буенча тавыш бирү участогында чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларга тавыш бирү

көненә кадәр участок комиссиясе тарафыннан бирелгән башка участокта тавыш бирү таныклыклары саны;

9 в юл: чакыртып алу буенча тавыш бирү участогында башка участокта тавыш бирү таныклыклары буенча тавыш биргән чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар саны;

9 г юл: чакыртып алу буенча тавыш бирү участогында юкка чыгарылган башка участокта тавыш бирү кенәгәләре саны;

9 г-1 юл: чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларга территория комиссиясе тарафыннан бирелгән башка участокта тавыш бирү таныклыклары саны;

9 г-2 юл: башка участокта тавыш бирү таныклыкларының югалганнары саны;

9 д юл: югалган бюллетеньнәр саны;

9 е юл: алганда исәпкә кертелмәгән бюллетеньнәр саны;

10 һәм аннан соңгы юллар: чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның бюллетеньнәрдәге «Чакыртып алу өчен» һәм «Чакыртып алуга каршы» позицияләре буенча бирелгән тавышлары саны;

6) тавыш бирү көнендә һәм чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар тавышларын санау беткәнче участок комиссиясенә кергән, беркетмәгә кушымта итеп бирелә торган шикаятьләр (гаризалар) саны турында белешмәләр;

7) участок комиссиясе рәисенең, рәис урынбасарының, секретаренең һәм хәлиткеч тавыш хокукына ия башка әгъзаларының фамилияләре, инициаллары һәм имзалары;

8) беркетмәгә кул кую датасы һәм вакыты;

9) участок комиссиясе мөһере.

3. Әлеге статьяның 2 өлешендә күрсәтелгән саннар тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәгә саннар белән һәм язмача кертелә.

49 статья. **Чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар тавышларын санау һәм тавыш бирү йомгаклары турында участок комиссиясенең беркетмә төзү тәртибе**

1. Чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар тавышларын санау, участок комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзалары тарафыннан ачыктан-ачык һәм хәбәрдар итеп, бюллетеньнәрне һәм чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар тавышларын санау буенча башкарыла торган гамәлләрнең барлык нәтиҗәләрен эзлекле рәвештә игълан итеп

һәм тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәнең зурайтылган рәвешендә тиешенчә рәсмиләштереп башкарыла.

2. Чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның тавышларын санау тавыш бирү вакыты тәмамлануга ук башлана һәм тавыш бирү йомгакларын билгеләгәнгә кадәр тәнәфессез уздырыла, бу хакта участок комиссиясенең барлык әгъзаларына, шулай ук күзәтүчеләргә хәбәр ителә.

3. Тавыш бирү вакыты тәмамланганнан соң, участок комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзалары, күзәтүчеләр, әлеге Законның 22 статьясындагы 3 өлешендә күрсәтелгән башка затлар катнашында, файдаланылмаган бюллетеньнәрне саныйлар, сул яктагы аскы почмагын кисеп юкка чыгаралар, шуннан соң файдаланылмыйча юкка чыгарылган бюллетеньнәрнең санын, шулай ук тавыш бирүне уздырганда чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар тарафыннан бозылган бюллетеньнәр санын игълан итәләр һәм аларны тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәнең һәм аның тавыш бирү бинасындагы зурайтылган рәвешенең 5 юлына язып куялар. Тавышлар санауның техник чараларын кулланганда, алынган күрсәткечләр игълан ителгәннән соң, тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәнең зурайтылган рәвешенең 5 юлына кертәләр.

4. Участок комиссиясе рәисе, рәис урынбасары яисә секретаре участок комиссиясе тарафыннан алынган бюллетеньнәрнең санын төгәлләштерә, игълан итә һәм аны тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәнең һәм аның зурайтылган рәвешенең 2 юлына кертә. Тавышлар санауның техник чараларын кулланганда, алынган күрсәткечләр игълан ителгәннән соң, тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәнең зурайтылган рәвешенең 2 юлына кертәләр.

5. Чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның тавышларын турыдан-туры санау алдыннан участок комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзалары чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегенең һәр битенә шушы биттәге түбәндәге суммар күрсәткечләрне кертәләр:

1) тавыш бирү тәмамланган вакытка чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның исемлегенә кертелгән чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар санын (территория һәм (яисә) участок комиссияләре тарафыннан бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары бирелгән, шулай ук башка сәбәпләр аркасында киткән чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларны исәпкә алмыйча);

2) тавыш бирү көнендә тавыш бирү бинасында чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларга бирелгән бюллетеньнәр санын (чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегендәге чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар имзалары саны буенча билгеләнә);

3) тавыш бирү көнендә тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш биргән чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларга бирелгән бюллетеньнәр санын (чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегендәге тиешле тамгалар саны буенча билгеләнә);

4) чакыртып алу буенча тавыш бирү участогында чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларга участок комиссиясе тарафыннан бирелгән бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары санын;

5) чакыртып алу буенча тавыш бирү участогында бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары буенча тавыш биргән чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар санын;

6) чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларга территория комиссиясе тарафыннан бирелгән бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны.

6. Әлеге статьяның 5 өлешендә күрсәтелгән күрсәткечләр кертелгәннән соң, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегенең һәр битенә чакыртып алу комиссиясенең әлеге күрсәткечләрне керткән әгъзасы имза сала, аннан соң ул шушы күрсәткечләрне кушып берләштерә, игълан итә һәм участок комиссиясе рәисенә, рәис урынбасарына яисә секретарена һәм тавышларны санаганда шунда булган затларга хәбәр итә. Әлеге статьяның 5 өлеше нигезендә билгеләнгән күрсәткечләр суммасы буларак билгеләнүче йомгаклау күрсәткечләрен участок комиссиясе рәисе, рәис урынбасары яисә секретаре игълан итә, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегенең соңгы битенә кертә, аларны үз имзасы белән раслый һәм участок комиссиясе мөһере белән таныклый. Игълан ителгән күрсәткечләр тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәнең һәм аның зурайтылган рәвешенең тиешле юлларына, тавышларны санаганда техник чараларны кулланганда – бары тик беркетмәнең зурайтылган рәвешенең тиешле юлларына гына, кертелә:

1) 1 юлга – тавыш бирү тәмамланган вакытка чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегенә кертелгән чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар саны;

2) 3 юлга – тавыш бирү көнендә тавыш бирү бинасында тавыш биргән чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларга бирелгән бюллетеньнәр саны;

3) 4 юлга – тавыш бирү көнендә тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш биргән чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларга бирелгән бюллетеньнәр саны;

4) 9 а юлга – бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларының участок комиссиясе тарафыннан алынган саны;

5) 9 б юлга – чакыртып алу буенча тавыш бирү участогында чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларга участок комиссиясе тарафыннан бирелгән бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны;

6) 9 в юлга – чакыртып алу буенча тавыш бирү участогында бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары буенча тавыш биргән чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар саны;

7) 9 г юлга – чакыртып алу буенча тавыш бирү участогында юкка чыгарылган башка участокта тавыш бирү таныклыклары саны;

8) 9 г-1 юлга – чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларга территория комиссиясе тарафыннан бирелгән башка участокта тавыш бирү таныклыклары саны.

Күрсәтелгән гамәлләр башкарылганнан соң, түбәндәге контроль чагыштырмаларга тикшерү үткәрелә: бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларының участок комиссиясе тарафыннан алынган саны участок комиссиясе тарафыннан чакыртып алу буенча тавыш бирү участогында чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларга тавыш бирү көненә кадәр бирелгән бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны һәм чакыртып алу буенча тавыш бирү участогында юкка чыгарылган бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны суммасына тигез булырга тиеш. Күрсәтелгән контроль чагыштырмалар үтәлмәгән очракта, участок комиссиясе чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегенә кертелгән күрсәткечләрне һәм башка участокта тавыш бирү таныклыкларының юкка чыгарылганнарын өстәмә санау турында карар кабул итә. Өстәмә санау нәтиҗәсендә контроль чагыштырмалар тагын үтәлмәсә, участок комиссиясе тиешле карар кабул итә, ул тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәгә кушымта итеп бирелә һәм аермалар турындагы күрсәткечләр тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәнең һәм аның зурайтылган рәвешенең 9 г-2 юлына язып куела. Әгәр контроль чагыштырмалар үтәлсә, беркетмәнең 9 г-2 юлында «0» саны куела.

Шуннан соң чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлеге белән күзәтүчеләр һәм әлеге Законның 22 статьясындагы 3 өлешендә күрсәтелгән башка затлар танышырга хокуклы, ә участок комиссиясенең киңәш бирү тавышы хокукына ия әгъзалары башкарылган санауның дөреслегенә ышанырга хокуклы.

7. Чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлеге белән алга таба эш итү әлеге статьяның 20 өлеше нигезендә тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәгә кертелгән күрсәткечләрнең контроль чагыштырмалары тикшерелгәнче гамәлгә ашырыла алмый. Чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлеге шушы вакытка сейфка йә документларны саклау өчен җайлаштырылган башка махсус урынга җыеп куела. Чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлеген тавыш бирү бинасындагы затлар ала алмаслык итеп саклауны участок комиссиясе рәисе яисә секретаре тәэмин итә.

8. Чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар тавышларын турыдан-туры санау участок комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзалары тарафыннан тавыш бирү әрҗәләрендәге бюллетеньнәр буенча гамәлгә ашырыла.

9. Чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның тавышларын турыдан-туры санаганда участок комиссиясенең киңәш бирү тавышы хокукына ия әгъзалары, күзәтүчеләр, әлеге Законның 22 статьясындагы 3 өлешендә күрсәтелгән башка затлар карап торырга хокуклы.

10. Чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның тавышларын турыдан-туры санау комиссиянең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзаларына да, киңәш бирү хокукына ия әгъзаларына да кереп йөрүне тәэмин итәрлек җиһазландырылган, махсус билгеләнгән урыннарда үткәрелә. Чакыртып алу комиссиясе рәисеннән (рәис урынбасарыннан) һәм секретареннан гайре, комиссиянең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзаларына тавышларны санаганда язу әсбапларыннан файдалану тыела, әлеге статьяның 12 һәм 15 өлешләрендә каралган очраклар моңа керми. Тавышларны турыдан-туры санаганда карап торган затларга чакыртып алу комиссиясе әгъзалары эшчәнлегенең тулысынча күренүе тәэмин ителергә тиеш.

11. Бюллетеньнәрне сортларга аерганда участок комиссиясе билгеләнмәгән рәвештәге бюллетеньнәрне аерым куя. Билгеләнмәгән рәвештәге бюллетеньнәр тавышларны санаганда исәпкә алынмый.

12. Беренче чиратта тавыш бирүнең күчерелмә әрҗәләрендәге бюллетеньнәр санала. Башта, тавыш бирүнең күчерелмә әрҗәләрен ачканчы, алардагы мөһерләрнең (пломбаларның) төзеклеге тикшерелә. Тавышларны санау тавыш бирүнең яшеренлеген бозмаслык итеп алып барыла. Әрҗәләрдән алынган билгеләнгән рәвештәге бюллетеньнәр саны игълан ителә һәм тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәнең һәм аның зурайтылган рәвешенең 6 юлына язып куела. Әгәр тавыш бирүнең күчерелмә әрҗәләрендәге билгеләнгән рәвештәге бюллетеньнәр саны алынган бюллетеньнәр саны турында чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның тамгаланган гаризалары саныннан артып китсә, тавыш бирүнең әлеге күчерелмә әрҗәсендәге барлык бюллетеньнәр участок комиссиясе карары белән гамәлгә яраксыз дип танила, бу хакта акт төзелә, ул тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәгә кушымта итеп бирелә, һәм анда тавыш бирү бинасыннан читтә тавыш бирүнең әлеге күчерелмә әрҗәсеннән файдаланып тавыш бирүне тәэмин иткән участок комиссиясе әгъзаларының фамилияләре һәм инициаллары күрсәтелә. Бу очракта гамәлгә яраксыз дип танылган бюллетеньнәр саны игълан ителә, күрсәтелгән актка кертелә һәм шуннан соң бюллетеньнәрне сортларга аерганда ачыкланган гамәлгә яраксыз бюллетеньнәр саны белән кушыла. Бюллетеньнәрнең һәркайсының алгы ягында «Чакыртып алуны хуплыйм» һәм «Чакыртып алуга каршы» позицияләренә кагылышлы квадратларга бюллетеньне гамәлгә яраксыз дип тануның сәбәбе язып куела, ул участок комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия ике әгъзасының имзасы белән расслана һәм участок комиссиясенең мөһере белән таныклана, ә бюллетеньнәр тавышларны турыдан-туры санаганда аерым төреп куела, аңа мөһер сугыла һәм алга таба тавышларны санаганда исәпкә алынмый.

13. Тавыш бирүнең стационар әрҗәләре алардагы мөһерләрнең (пломбаларның) төзеклеге тикшерелгәннән соң ачыла.

14. Участок комиссиясе әгъзалары тавыш бирүнең күчерелмә һәм стационар әрҗәләреннән алынган бюллетеньнәрне «Чакыртып алуны хуплыйм» һәм «Чакыртып алуга каршы» позицияләренә кагылышлы бирелгән тавышлар буенча сортларга аералар, бер үк вакытта билгеләнмәгән рәвештәге бюллетеньнәрне һәм гамәлгә яраксыз бюллетеньнәрне аерып алалар. Бюллетеньнәрне сортларга аерганда участок комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзалары аларның һәркайсына чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучы тарафыннан куелган тамганы игълан итәләр һәм тавышларны турыдан-туры санаганда карап торган барлык

затларга да бюллетеньнәрне карап тикшерү өчен күрсәтәләр. Ике яисә аннан да күбрәк бюллетеньнең эчтәлеген бер үк вакытта игълан итү рөхсәт ителми.

15. Гамәлгә яраксыз бюллетеньнәр санала һәм аерым кушып куела. «Чакыртып алуны хуплыйм» һәм «Чакыртып алуга каршы» позицияләренә кагылышлы квадратларда бернинди дә тамга куелмаган яисә бу квадратлардагы тамгалар саны законда билгеләнгән тамгалар санынннан артык булган бюллетеньнәр гамәлгә яраксыз дип санала. Чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучының ихтыяр белдерүен ачыклаганда шик туган очракта, бу бюллетень аерым төргәккә алып куела. Сортларга аеру тәмамлангач, участок комиссиясе барлык шикле бюллетеньнәрнең гамәлгә яраклылыгы турындагы мәсьәләне тавыш бирү юлы белән хәл итә, бу чакта бюллетеньнең икенче ягында аны гамәлгә яраклы яисә гамәлгә яраксыз дип тануның сәбәпләре күрсәтелә. Бу язма участок комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия ике яисә аннан күбрәк әгъзаларының имзалары белән раслана һәм комиссия мөһере белән таныклана. Гамәлгә яраклы яисә гамәлгә яраксыз дип танылган бюллетень тиешле төргәккә алып куела. Гамәлгә яраксыз бюллетеньнәрнең гомуми саны (әлеге статьяның 12 өлеше нигезендә гамәлгә яраксыз дип танылган бюллетеньнәр санын исәпкә алып) тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәнең һәм аның зурайтылган рәвешенең 8 юлына язып куела.

16. Шуннан соң һәр төргәктәге сортларга аерылган билгеләнгән рәвештәге бюллетеньнәр «Чакыртып алуны хуплыйм» һәм «Чакыртып алуга каршы» позицияләре буенча аерым-аерым санала. Бу чакта бюллетеньнәр һәр төргәкнең бер өлешеннән икенче өлешенә берәм-берәм алып кую юлы белән санала, тавышларны санауны карап торган затлар һәр бюллетеньдә чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучы тамгасын күрерлек итеп башкарылырга тиеш. Бюллетеньнәрне бер үк вакытта төрле төргәкләрдән алып санау рөхсәт ителми. Алынган күрсәткечләр тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәнең, шулай ук аның зурайтылган рәвешенең 10 юлына һәм аннан соңгы юлларына язып куела.

17. Участок комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзалары гамәлгә яраклы бюллетеньнәрне саныйлар һәм тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәнең һәм аның зурайтылган рәвешенең 9 юлына язып куялар.

18. Участок комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзалары тавыш бирүнең стационар әрҗәләрендәге билгеләнгән рәвештәге бюллетеньнәрне санныйлар, игълан итәләр һәм аларның санын тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәнең һәм аның зурайтылган рәвешенең 7 юлына кертәләр.

19. Участок комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзалары тикшереп торган килеш, күзәтүчеләр сортларга аерылган бюллетеньнәрне карап чыгарга хокуклы, ә участок комиссиясенең киңәш бирү тавышы хокукына ия әгъзалары башкарылган санауның дөреслегенә ышанырга хокуклы.

20. Сортировкаланган бюллетеньнәр белән участок комиссиясенең киңәш бирү тавышы хокукына ия әгъзаларын һәм күзәтүчеләрне таныштырганнан соң тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәгә кертелгән күрсәткечләрнең контроль чагыштырмаларына әлеге Законның 3 кушымтасы нигезендә тикшерү үткәрелә. Күрсәтелгән контроль чагыштырмалар үтәлмәгән очракта, участок комиссиясе тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәнең барлык юлларын яисә аерым юлларын өстәмә санау турында, шул исәптән бюллетеньнәрне өстәмә санау турында карар кабул итә. Өстәмә санау нәтиҗәсендә контроль чагыштырмалар тагын үтәлмәсә, участок комиссиясе тиешле акт төзи, ул тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәгә кушымта итеп бирелә һәм аермалар турындагы күрсәткечләр беркетмәнең 9д һәм 9е юлларына язып куела. Әгәр өстәмә санау нәтиҗәсендә тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәгә үзгәреш кертергә кирәк булса, беркетмәнең яңа бланкы тутырыла, ә аның зурайтылган рәвешенә тиешле төзәтмәләр кертелә. Әгәр контроль чагыштырмалар үтәлсә, беркетмәнең 9д һәм 9е юлларында «0» саны куела.

21. Санау тәмамланганнан соң сортларга аерылган бюллетеньнәр аерым төргәкләргә төреп куела. Шул рәвешле җыеп куелган бюллетеньнәр капчыкларга яисә тартмаларга тутырыла, анда чакыртып алу буенча тавыш бирү участогы номеры, бюллетеньнәр саны күрсәтелә. Капчыкларга яисә тартмаларга мөһер сугыла һәм алар бары тик чакыртып алу буенча югарырак комиссия яисә суд карары буенча гына ачылырга мөмкин. Күрсәтелгән капчыкларга яисә тартмаларга участок комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзалары да, киңәш бирү тавышы хокукына ия әгъзалары да үз имзаларын куярга хокуклы. Капчыкларны яисә тартмаларны тутыру әлеге Законның 22 статьясындагы 3 өлешендә күрсәтелгән затлар барында гамәлгә ашырыла һәм аларга капчыкларга яисә тартмаларга үз имзаларын кую мөмкинлеге бирелә.

22. Тавышлар санауның техник чараларыннан кулланганда чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлеге белән эш тәмамланганнан соң участок комиссиясенең киңәш бирү тавышы хокукына ия әгъзалары, күзәтүчеләр һәм әлеге Законның 22 статьясындагы 3 өлешендә күрсәтелгән затлар катнашында:

1) әгәр вакытлыча нинди дә булса сәбәп белән тавыш бирү бинасында тавыш бирү тавышларны санауның техник чараларын кулланмыйча үткәрелсә, участок комиссиясе тавышларны санауның әлеге техник чарасындагы махсус бүлегендәге йә тавыш бирү өчен стационар резерв әрҗәсендәге мөһерләрнең (пломбаларның) төзеклеген тикшерә, мондый әрҗәне ача һәм андагы барлык бюллетеньнәрне тавышларны санауның техник чарасына тавыш бирү сере бозылмаслык итеп төшерә;

2) участок комиссиясе тавыш бирү өчен күчмә әрҗәләрдәге бюллетеньнәрне әлеге статьяның 12 өлешендә каралган тәртиптә саный, шуннан соң андагы барлык бюллетеньнәрне тавыш бирү өчен күчмә әрҗәләрдән тавышларны санау режимына күчерелгән тавышларны санауның техник чарасына тавыш бирү сере бозылмаслык итеп төшерә;

3) участок комиссиясе чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлекләре белән эшләүнең беренче этабында алынган күрсәткечләрне, ягъни тавыш бирү йомгаклары турындагы зурайтылган рәвештәге беркетмәнең 1, 2,3, 4, 5 һәм 9а, 9б, 9в, 9г, 9г-1, 9г-2 юлларына кертелгән күрсәткечләрне, тавышларны санауның техник чарасына кертә;

4) участок комиссиясе тавышларны санауның техник чарасыннан тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәнең күчермәсен бастырып ала, тиешле күрсәткечләрне игълан итә һәм тавыш бирү йомгаклары турындагы зурайтылган рәвештәге беркетмәнең 6, 7, 8, 9, 10 юлларына һәм аннан соңгы юлларына кертә;

5) участок комиссиясе тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәгә кертелгән күрсәткечләрнең контроль чагыштырмаларын тикшерә. Күрсәтелгән контроль чагыштырмалар үтәлмәсә, участок комиссиясе тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәнең барлык яисә аерым юллары буенча өстәмә санау, шул исәптән бюллетеньнәрне өстәмә рәвештә кулдан санау турында карар кабул итә. Өстәмә санау нәтиҗәсендә контроль чагыштырмалар тагын үтәлмәсә, участок комиссиясе тиешле карар кабул итә, ул тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәгә кушымта итеп бирелә һәм аермалар турындагы күрсәткечләрне

тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәнең 9д һәм 9е юлларына кертә.

23. Участок комиссиясе, тавыш бирү көнендә чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар тавышларын санау тәмамланганчыга кадәр, тавышларны санауны карап торган затларның шикаятьләрен (гаризаларын) карарга һәм тиешле карарлар кабул итәргә тиеш, алар тавыш бирү йомгаклары турында участок комиссиясе беркетмәсенең беренче нөсхәсенә кушып бирелә. Тавышларны санаганда турыдан-туры катнашкан затлардан нигезләнгән шикаятьләр (гаризалар) кергән очракта тавышларны санауның техник чарасын кулланган участок комиссиясе кичекмәстән әлеге чараны кулланмыйча гына турыдан-туры санауны үткәрү (кулдан санау) турында карар кабул итәргә хокуклы. Күрсәтелгән санау йомгаклары буенча аерма бер проценттан артык (кечкенә санны зур санга бүлеп билгеләнә), ләкин тавышларны кулдан санау күрсәткечләре белән тавышларны санауның техник чарасын кулланып алынган күрсәткечләр арасында аерма тавыш бирү йомгаклары турында участок комиссиясе беркетмәсенең һичьюгы 8, 9, 10 юлларының берсендә һәм калган юлларында кимендә өч берәмлек булса, кулдан санау нәтиҗәләре буенча тавыш бирү йомгаклары турында беркетмә төзелә. Әгәр күрсәтелгән аерма барлыгы ачыкланмаса, тавышларны санауның техник чарасы ярдәмендә алынган беркетмәгә имза салына һәм тавышларны кабат санау барышында алынган күрсәткечләрнең баштагы күрсәткечләргә туры килүе турында акт төзелә, ул участок комиссиясенең тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәсе белән бергә югарырак комиссиягә җибәрелә.

24. Барлык тиешле гамәлләр башкарылганнан һәм тавышлар саналганнан соң участок комиссиясенә йомгаклау утырышын уздыру мәҗбүри, анда чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның тавыш биргәндә һәм тавышларын санаганда булган хокук бозулар турындагы шикаятьләр (гаризалар) карала, шуннан соң тавыш бирү йомгаклары турында участок комиссиясе беркетмәсенә имза салына һәм әлеге Законның 22 статьясындагы 3 өлешендә күрсәтелгән затларга беркетмәнең күчермәләре тапшырыла. Тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмә ике нөсхәдә тутырыла һәм участок комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия булган шундагы барлык әгъзалары тарафыннан имзалана, имза салу датасы һәм вакыты (сәгате һәм минутлары) күрсәтелә. Тавышларны санауның техник чарасын кулланып йә электрон тавыш бирү комплексыннан файдаланып алынган тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмә әлеге имзалаудан соң юридик

көчкә ия була. Тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәне карандаш белән тутыру һәм аңа нинди дә булса үзгәрешләр кертү рөхсәт ителми. Беркетмәгә әлеге тәртипне бозып имза салу шушы беркетмәне гамәлгә яраксыз дип тану һәм тавышларны кабат санауны уздыру өчен нигез була.

25. Тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәне тутырганда участок комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия кайбер әгъзалары булмаса, аларның булмау сәбәпләре күрсәтелеп, беркетмәгә бу хакта язып куела. Беркетмәгә участок комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзаларының билгеләнгән саныннан күпчелеге имза салган булса, беркетмә гамәлгә яраклы була. Әгәр тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәгә имза салганда участок комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия берәр әгъзасы өчен участок комиссиясенең бүтән әгъзасы яисә чит зат имза салса, бу әлеге беркетмәне гамәлгә яраксыз дип тану һәм тавышларны кабат санауны уздыру өчен нигез була.

26. Тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәгә имза салганда участок комиссиясенең беркетмәнең эчтәлеге белән килешмәгән хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзалары беркетмәгә үзләренең аерым фикерен кушымта итеп теркәргә хокуклы, бу хакта беркетмәгә тиешенчә язып куела.

27. Участок комиссиясе әгъзасы, күзәтүче, әлеге Законның 22 статьясындагы 3 өлешендә күрсәтелгән башка затлар таләбе буенча участок комиссиясе, тавыш бирү йомгаклары турында беркетмәгә (шул исәптән кабат төзелгәненә) имза салынгач, кичекмәстән әлеге затларга тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәнең таныкланган күчермәсен бирергә тиеш. Участок комиссиясе таныкланган күчермәне бирү фактын тиешле реестрда билгеләп куя. Таныкланган күчермәне алган зат күрсәтелгән реестрга имза сала. Тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәнең күчермәсен таныклаган зат тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмә күчермәсендәге күрсәткечләрнең беркетмәдәге күрсәткечләргә тулысынча туры килүе өчен җаваплы була.

28. Тавыш бирү йомгаклары турында участок комиссиясе беркетмәсенең беренче нөсхәсе, аңа участок комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия шунда булган барлык әгъзалары имза салгач һәм әлеге күчермәләрне алу хокукы булган затларга шушы таныкланган күчермәләрне биргәч, кичекмәстән чакыртып алу буенча югарырак комиссиягә җибәрелә һәм участок комиссиясенә кире кайтарылмый. Тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәнең беренче нөсхәсенә участок комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзаларының аерым фикерләре,

шулай ук чакыртып алу буенча күрсәтелгән комиссиягә тавыш бирү көнендә һәм чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның тавышларын санау тәмамланганчы әлеге Законны бозуга карата кергән шикаятьләр (гаризалар) һәм участок комиссиясенең күрсәтелгән шикаятьләр (гаризалар) буенча кабул ителгән карарлары һәм участок комиссиясе төзегән актлар һәм реестрлар кушып бирелә. Күрсәтелгән документларның һәм участок комиссиясе карарларының таныкланган күчермәләре тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәнең икенче нөсхәсенә кушып бирелә. Тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәнең беренче нөсхәсе аңа кушып бирелгән документлары белән бергә участок комиссиясе рәисе яисә секретаре йә участок комиссиясе рәисе кушуы буенча участок комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия бүтән әгъзасы тарафыннан чакыртып алу буенча югарырак комиссиягә илтеп тапшырыла. Участок комиссиясе беркетмәсен тапшырганда участок комиссиясенең башка әгъзалары, шулай ук әлеге участок комиссиясенә җибәрелгән күзәтүчеләр дә катнашырга хокуклы.

29. Тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәнең икенче нөсхәсе танышу өчен күзәтүчеләргә, әлеге Законның 22 статьясындагы 3 өлешендә күрсәтелгән бүтән затларга тапшырыла, ә аның таныкланган күчермәсе гомуми танышу өчен участок комиссиясе билгеләгән урынга элеп куела, шуннан соң беркетмәнең икенче нөсхәсе әлеге Законда каралган чакыртып алу буенча тавыш бирү документлары белән бергә, бюллетеньнәрне, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлеген кертеп, шулай ук участок комиссиясе мөһере чакыртып алу буенча югарырак комиссиягә саклау өчен тапшырыла.

30. Чакыртып алу буенча тавыш биргәндә участок комиссияләре Россия Федерациясенең Үзәк сайлау комиссиясе карары буенча яисә аның кушуы нигезендә Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе карары буенча тавыш бирү өчен стационар әрҗәләр урынына тавышларны сауның техник чараларын яисә электрон тавыш бирү комплексларын файдаланалар. Тавышларны санауның техник чаралары яисә электрон тавыш бирү комплекслары файдалана торган чакыртып алу буенча тавыш бирү участоклары исемлеге Россия Федерациясенең Үзәк сайлау комиссиясе яисә аның кушуы нигезендә Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнә.

31. Тавышларны санауның техник чараларын кулланганда участок комиссиясе тарафыннан тавышларны санау әлеге статьяның 22 өлеше нигезендә башкарыла. Бер территория комис-

сиясе эшли торган территория чикләрендә мондый техник чаралар кулланылган чакыртып алу буенча тавыш бирү участокларының җирәбә салу юлы белән билгеләнә торган кимендә 5 процентында (чакыртып алу буенча тавыш бирүнең кимендә өч участогында) турыдан-туры участок комиссияләренең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзалары тарафыннан чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның тавышларын контроль санау (тавышларны кулдан санау) үткәрелә. Җирәбә салу тиешле территория комиссиясе тарафыннан тавыш бирү вакыты тәмамланганнан соң ярты сәгать эчендә үткәрелә, ә җирәбә салу нәтиҗәләре һәр участок комиссиясе игътибарына кичекмәстән җиткерелә.

32. Тавышларны контроль (кулдан) санауны үткәрү мөмкинлеге турында тавышларны санауның техник чараларын кулланган чакыртып алу буенча тавыш бирү участогында тавыш бирү йомгакларын билгеләгәндә шунда булган барлык затларга хәбәр ителергә тиеш. Тавышларны кулдан санау әлеге Законның 22 статьясындагы 3 өлешендә санап кителгән күзәтүчеләр, башка затлар катнашында үткәрелә. Җирәбә салып билгеләнгән чакыртып алу буенча тавыш бирү участокларында тавышларны кулдан санау әлеге статьяның 8 – 11, 13 – 17, 19 – 21 өлешләрендә билгеләнгән тәртиптә үткәрелә. Тавышларны кулдан санау йомгаклары буенча йә тавыш бирү йомгаклары турында (әгәр аерма бер проценттан артык булса) тавышларны кулдан санау күрсәткечләре белән тавышларны санауның техник чарасын кулланып алынган күрсәткечләр арасындагы аерманы тавышларның зур санына бүлеп билгеләнә), ләкин тавышларны кулдан санау күрсәткечләре белән тавышларны санауның техник чарасын кулланып алынган күрсәткечләр арасында аерма тавыш бирү йомгаклары турында участок комиссиясе беркетмәсендәге 8, 9, 10 юлларның һичьюгы берсендә һәм калган юлларында кимендә өч берәмлек булса) яңа беркетмә төзелә, анда «Кабат» дигән тамга ясала һәм тавыш бирү йомгаклары турында участок комиссиясенең баштагы беркетмәсе белән чакыртып алу буенча югарырак комиссиягә җибәрелә, йә тавышларны кабат санау барышында алынган күрсәткечләрнең баштагы күрсәткечләре белән туры килүе турында акт төзелә, ул участок комиссиясенең тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәсе белән чакыртып алу буенча югарырак комиссиягә җибәрелә. Тавышларны контроль (кулдан) санау өчен җирәбә белән билгеләнгән чакыртып алу буенча тавыш бирү участогының участок комиссиясе рәисе тавышларны санауның контроль (кулдан) санау нәтиҗәләре билгеләнгәннән соң алынган нәтиҗәләр турында турыдан-туры территория комиссиясенә хәбәр итә.

33. Җирәбә белән билгеләнгән чакыртып алу буенча тавыш бирү участокларын билгеләгән территория комиссиясе тавышларны контроль (кулдан) санауны үткәрү өчен чакыртып алу буенча тавыш бирүнең күрсәтелгән участокларының участок комиссияләре рәисләреннән тавышларны контроль (кулдан) санау нәтиҗәләре турында белешмәләр алынгач кичекмәстән тиешле карар кабул итә, шул исәптән чакыртып алу буенча тавыш бирүнең тавышларны кулдан санау үткәрелмәгән һәм тиешле территориядә урнашкан барлык участокларында, тавышларны контроль санау нәтиҗәсендә җирәбә белән билгеләнгән чакыртып алу буенча тавыш бирү участокларының һичьюгы берсендә беркетмәнең 8, 9, 10 юлларында һәм аннан соңгы юлларында тавышларны санауның техник чараларын кулланганда һәм тавышларны кулдан санаганда алынган белешмәләр туры килмәгәнгә күрә тавыш бирү йомгаклары турында беркетмә яңадан төзелгән очракта, тавышларны кулдан санауны үткәрү турында карар кабул итә.

34. Тавышларны санауның техник чараларын кулланган чакыртып алу буенча участок комиссияләре тавышларны кулдан санаганда тавыш бирү йомгаклары билгеләнгәннән һәм тавыш бирү йомгаклары турында яңа беркетмәләрне йә әлеге статьяның 28 өлешендә каралган тәртиптә белешмәләрнең туры килүе турындагы актларны имзалаганнан соң, беркетмәләр территория комиссиясенә җибәрелә.

35. Тавышларны санауның техник чаралары кулланылганда чакыртып алу буенча тавыш бирү участогында тавыш бирү тәмамланганчыга кадәр тавышларны санау күрсәткечләрен, чакыртып алу буенча тавыш биргән катнашучыларның гомуми саны турындагы күрсәткечләрдән тыш, фаш итү тыела.

36. Тавыш бирү йомгаклары турында беркетмә күрсәткечләре, шул исәптән тавышларны санауның техник чараларын кулланып алынганнары да, чакыртып алу буенча югарырак комиссиягә «Сайлаулар» ДАС техник элемтә каналлары аша (тавышлы элемтә чараларыннан тыш) йә мәгълүмат тапшыруның башка техник системасы аша тапшырыла, ә тавыш бирү йомгаклары турында беркетмәнең беренче нөсхәсе һәм чакыртып алу буенча бөтен документация, бюллетеньнәрне дә кертеп, беренче мөмкинлек булганда ук чакыртып алу буенча югарырак комиссиягә тапшырыла йә чакыртып алу буенча тавыш бирү документациясенең иминлеген һәм аны тиешле урынга илтеп

тапшыруның куркынычсызлыгын тәэмин итә торган башка ысул белән тапшырыла.

37. Тавыш бирү йомгаклары турында участок комиссияләре беркетмәләрендәге күрсәткечләр Россия Федерациясе Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан билгеләнә торган тәртиптә «Интернет» гомуми файдалану мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырыла.

38. Әгәр тавыш бирү йомгаклары турында участок комиссиясе беркетмәсенә имза салынганнан соң һәм аның беренче нөсхәсе территория комиссиясенә җибәрелгәннән соң беркетмә төзегән участок комиссиясе беркетмәнең 1 – 9, 9а – 9е юлларында төгәлсезлек (шул исәптән хата, өстәп язу яисә белешмәләрне кушканда хата җибәрү) барлыгын ачыкласа йә территория комиссиясе беркетмә төзүнең дөреслеген алдан тикшерү барышында төгәлсезлекләр барлыгын ачыкласа, участок комиссиясе үз утырышында беркетмәнең 1 – 9, 9а – 9е юлларына төгәлләштерүләр кертү турындагы мәсьәләне карарга тиеш. Участок комиссиясе, күрсәтелгән утырышны үткәрү турында хәбәр итеп, анда әлеге мәсьәләнең каралачагын күрсәтергә тиеш. Кабул ителгән карар турында участок комиссиясе үзенең киңәш бирү хокукына ия әгъзаларына, тавыш бирү йомгаклары турында участок комиссиясенең элек расланган беркетмәсен төзегәндә катнашкан башка затларга, шулай ук массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләренә һичшиксез хәбәр итә. Бу очракта участок комиссиясе тавыш бирү йомгаклары турында беркетмә төзи, анда «Кабат» дигән тамга куела. Күрсәтелгән беркетмә кичекмәстән территория комиссиясенә җибәрелә. Участок комиссиясенең югарырак сайлау комиссиясенә элек бирелгән беркетмәсе кабат төзелгән беркетмәгә кушып бирелә. Беркетмәнең 10 юлына һәм аннан соңгы юлларына төгәлләштерүләр кертергә кирәк булган очракта әлеге Законның 50 статьясындагы 9 өлешендә каралган тәртиптә тавышларны кабат санау үткәрелә. Кабат беркетмә төзүнең күрсәтелгән тәртибен бозу әлеге беркетмәне гамәлгә яраксыз дип тану өчен нигез булып тора.

50 статья. **Территория комиссияләрендә тавыш бирү йомгакларын эшкәртү**

1. Тавыш бирү йомгаклары турында участок комиссияләре беркетмәләренең беренче нөсхәләре аларга чакыртып алу комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзалары имза салганнан соң һәм аларның күчермәләрен алу хокукы булган затларга беркетмәләрнең таныкланган күчермәләрен һәм җыелма таблицаларның таныкланган күчермәләрен тапшырганнан соң,

күрсәтелгән беркетмәләрдә булган күрсәткечләрне берләштерү максатларында территория комиссиясенә җибәрелә, аннан соң әлеге күрсәткечләр Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенә чакыртып алу буенча тавыш бирү нәтиҗәләрен билгеләү өчен тапшырыла.

2. Тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәләр күрсәткечләре нигезендә, аларны төзүнең дөреслеге алдан тикшерелгәннән соң, территория комиссиясе тиешле территориядә тавыш бирү йомгакларын алардагы күрсәткечләрне берләштерү юлы белән билгели. Тавыш бирү йомгаклары турында чакыртып алу буенча комиссия карары тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмә белән рәсмиләштерелә.

3. Участок комиссияләренең беркетмәләрен кабул итү, шушы беркетмәләрдәге күрсәткечләрне берләштерү һәм тиешле территориядә тавыш бирү йомгаклары турында беркетмә төзү бер бинада гамәлгә ашырыла, территория комиссиясе әгъзаларының участок комиссияләренең беркетмәләрен кабул итеп алу, шушы беркетмәләрдәге күрсәткечләрне берләштерү һәм тиешле территориядә тавыш бирү йомгаклары турында беркетмә төзү буенча барлык гамәлләре чакыртып алу комиссиясе әгъзаларының һәм күзәтүчеләрнең, әлеге Законның 22 статьясындагы 3 өлешендә күрсәтелгән башка затларның күз уңында булырга тиеш. Күрсәтелгән бинада тиешле территория буенча җыелма таблицаның зурайтылган рәвеше булырга тиеш, аңа кичекмәстән, участок комиссиясе рәисе, секретаре яисә хәлиткеч тавыш хокукына ия башка әгъзасы тавыш бирү йомгаклары турында беркетмәнең беренче нөсхәсен алып килүгә үк, шушы беркетмәдәге күрсәткечләр, аларны кертү вакыты күрсәтелеп, кертелә.

4. Участок комиссиясе рәисе, секретаре яисә аның хәлиткеч тавыш хокукына ия башка әгъзасы участок комиссиясе беркетмәсенең беренче нөсхәсен, аңа кушымта итеп бирелгән документлары белән бергә, территория комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзасына тапшыра, ул исә беркетмәне тутыруның дөреслеген, кушымта итеп бирелгән документларның тулылыгын һәм контроль чагыштырмаларның үтәлешен тикшерә.

5. Тавыш бирү йомгаклары турында участок комиссиясе беркетмәсе һәм (яисә) җыелма таблицасы аларны төзүгә карата әлеге Законда булган таләпләрне бозып төзелгән булса, күрсәтелгән комиссия әлеге статьяның 13 өлеше таләпләре нигезендә кабат беркетмә һәм (яисә) җыелма таблица төзергә

тиеш, ә башта бирелгән беркетмә һәм (яисә) җыелма таблица территория комиссиясендә кала.

6. Әгәр тавыш бирү йомгаклары турында участок комиссиясе беркетмәсе һәм (яисә) җыелма таблицасы аларны төзүгә карата әлеге Законда булган таләпләр нигезендә төзелгән булса, территория комиссиясе әгъзасы әлеге беркетмә күрсәткечләрен территория комиссиянең җыелма таблицасына кертә. Тавыш бирү йомгаклары турында беркетмәне территория комиссиясе әгъзасына тапшырган участок комиссиясе рәисе, секретаре яисә хәлиткеч тавыш хокукына ия башка әгъзасы тавыш бирү йомгаклары турында тиешле чакыртып алу комиссиясе беркетмәсе күрсәткечләреннән соң җыелма таблицаның зурайтылган рәвешендә имза сала.

7. Тавыш бирү йомгаклары турында участок комиссияләре беркетмәләрендәге күрсәткечләрне берләштерү территория комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзалары тарафыннан турыдан-туры башкарыла.

8. Участок комиссияләре беркетмәләрендәге күрсәткечләр буенча территория комиссиясе җыелма таблица һәм тавыш бирү йомгаклары турында беркетмә төзи, аларга тиешле территориядә участок комиссияләренең саны, күрсәтелгән беркетмә нигезләнеп төзелә торган участок комиссияләреннән алынган беркетмәләр саны, шулай ук әлеге Законның 48 статьясындагы 2 өлешендә билгеләнгән тавыш бирү йомгаклары турында участок комиссиясе беркетмәсендәге юллар буенча суммар күрсәткечләр кертелә. Беркетмәне имзалау өчен территория комиссиясе мәҗбүри тәртиптә йомгаклау утырышы үткәрә, анда тавыш бирүне үткәрүгә бәйле чакыртып алу комиссиясенә кергән шикаятьләр (гаризалар) карала. Шуннан соң территория комиссиясе тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәгә имза сала һәм әлеге Законның 22 статьясындагы 2 өлешендә күрсәтелгән затларга беркетмәнең күчермәләрен бирә. Тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмә ике нөсхәдә төзелә һәм аңа сайлау комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия шунда булган барлык әгъзалары имза сала, анда имза салу датасы һәм вакыты (сәгате һәм минутлары) куела. Тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәгә тиешле комиссия тарафыннан алынган бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны, түбәнгерәк комиссияләргә бирелгән бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны, тиешле комиссия тарафыннан юкка чыгарылган файдаланылмаган бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны һәм югалган бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны турындагы күрсәткечләр кертелә. Беркетмәгә

әлеге тәртипне бозып имза салу беркетмәне гамәлгә яраксыз дип тану өчен нигез булып тора.

9. Әлеге статьяның 1 өлешендә күрсәтелгән чакыртып алу комиссияләренең тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәләргә тиешле территориядә тавыш бирү йомгаклары турында ике нөсхәдә төзелә торган җыелма таблица кушымта итеп бирелә, аңа территория комиссиясенә кергән барлык тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәләрдәге күрсәткечләр тулысынча кертелә. Территория комиссиясенең беркетмә белән тулаем яисә аның аерым нигезләмәләре белән килешмәүче хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзасы беркетмәгә үзенең төп фикерен өстәп бирергә хокуклы, бу турыда беркетмәдә тиешенчә язып куела.

10. Беркетмәнең беренче нөсхәсенә беркетмәне төзегән территория комиссиясе әгъзаларының аерым фикерләре, шулай ук тавыш бирү көнендә башланып тавыш бирү йомгаклары турында тиешле беркетмә төзелгән көндә тәмамланган чорда закон бозуларга карата шушы комиссиягә кергән шикаятьләр (гаризалар) һәм шушы шикаятьләр (гаризалар) буенча кабул ителгән карарлар кушып куела.

11. Тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәнең икенче нөсхәсе, җыелма таблицаның икенче нөсхәсе, территория комиссиясенең киңәш бирү тавышы хокукына ия беркетмә төзегән әгъзаларының, тавыш бирү йомгакларын билгеләгәндә һәм беркетмәләр төзегәндә шунда булган әлеге Законның 22 статьясындагы 3 өлешендә күрсәтелгән башка затларның исемлекләре, башка документлар белән бергә, саклана торган бинада күрсәтелгән чакыртып алу комиссиясе секретаренда саклана.

12. Тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәнең икенче нөсхәсе, тавыш бирү йомгаклары турындагы җыелма таблицаның икенче нөсхәсе белән бергә, чакыртып алу комиссиясенең беркетмә төзегән әгъзаларына, күзәтүчеләргә, әлеге Законның 22 статьясындагы 3 өлешендә күрсәтелгән башка затларга танышу өчен бирелә, ә беркетмәнең таныкланган күчермәсе гомуми танышу өчен элеп куела.

13. Тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәгә һәм (яисә) тавыш бирү йомгаклары турындагы җыелма таблицага имза салынганнан һәм аларның беренче нөсхәләре Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенә җибәрелгәннән соң, беркетмәне һәм җыелма таблицаны җибәргән территория комиссиясе йә Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе алдан тикшерү барышында аларда төгәлсезлек барлыгы (чакыртып алу буенча түбәнрәк комиссияләр беркетмәләренең күрсәткечләрен

кушканда хата ясау, хәреф хатасы йә ялгыш җибәрү) ачыкланса, беркетмәне һәм җыелма таблицаны җибәргән чакыртып алу комиссиясе беркетмәнең 1 – 9, 9а – 9е юлларына һәм (яисә) җыелма таблицага төгәлләштерүләр кертү турындагы мәсьәләне үзенең утырышында карарга хокуклы. Чакыртып алу комиссиясе кабул ителгән карар турында үзенең киңәш итү тавышы хокукына ия әгъзаларына, күзәтүчеләргә һәм элек расланган беркетмәне төзегәндә шунда булган башка затларга, шулай ук массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләренә һичшиксез хәбәр итәргә тиеш. Бу очракта чакыртып алу комиссиясе тавыш бирү йомгаклары турында беркетмә һәм (яисә) җыелма таблица төзи, анда «Кабат» дигән тамга куела. Әлеге беркетмә һәм (яисә) җыелма таблица Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенә кичекмәстән җибәрелә. Кабат беркетмә һәм кабат җыелма таблица төзүнең күрсәтелгән тәртибен бозу әлеге беркетмәне гамәлгә яраксыз дип тану өчен нигез булып тора. Әгәр тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәнең 10 юлына һәм аннан соңгы юлларына төгәлләштерү кертү таләп ителсә, әлеге статьяның 14 өлешендә билгеләнгән тәртиптә чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның тавышлары кабат санала.

14. Тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәләрдә һәм (яисә) тавыш бирү йомгаклары турындагы җыелма таблицаларда хаталар, төгәлсезлекләр барлыгы ачыкланганда, участок комиссиясеннән кергән беркетмәләрнең һәм кабат җыелма таблицаларның төзелү дөреслегенә шик туганда, территория комиссиясе участок комиссиясе тарафыннан чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның тавышларын кабат санауны уздыру турында йә чакыртып алу буенча тавыш бирүнең тиешле участогында чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның тавышларын кабат санауны мөстәкыйль уздыру турында карар кабул итәргә хокуклы. Чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның тавышларын кабат санау, югарырак комиссиянең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзасы (әгъзалары) шунда булганда, тикшерелергә тиешле беркетмәне төзегән һәм раслаган чакыртып алу комиссиясе тарафыннан яисә чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның тавышларын кабат санау турында карар кабул иткән комиссия тарафыннан уздырыла, бу хакта чакыртып алу буенча тиешле комиссиянең киңәш бирү тавышы хокукына ия әгъзаларына, күзәтүчеләргә, әлеге Законның 22 статьясындагы 3 өлешендә күрсәтелгән башка затларга хәбәр ителә, алар чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның тавышларын кабат санаганда шунда булырга

хокуклы. Чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның тавышларын кабат санау йомгаклары буенча әлеге санауны башкарган чакыртып алу комиссиясе тавыш бирү йомгаклары турында беркетмә төзи, анда «Тавышларны кабат санау» дип язып куела. Аның таныкланган күчермәләре күзәтүчеләргә, әлеге Законның 22 статьясындагы 3 өлешендә күрсәтелгән башка затларга бирелә. Беркетмә кичекмәстән чакыртып алу буенча югарырак комиссиягә җибәрелә. Тавышларны кабат санау чакыртып алу буенча югарырак комиссия тарафыннан чакыртып алу буенча тавыш бирү йомгакларын билгеләгәнгә, чакыртып алу буенча тавыш бирү нәтиҗәләрен ачыклаганга һәм чакыртып алу буенча тавыш бирү йомгаклары турында, тавыш бирү нәтиҗәләре турында беркетмә төзегәнгә кадәр үткәрелергә мөмкин.

51 статья. **Чакыртып алу буенча тавыш бирү нәтиҗәләрен билгеләү тәртибе**

1. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе территория комиссияләреннән алынган тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәләрнең беренче нөсхәләре нигезендә, бу беркетмәләрдәге күрсәткечләрне кушып берләштерү юлы белән, тавыш биргән көннән 10 көннән дә соңга калмыйча чакыртып алу буенча тавыш бирү нәтиҗәләрен билгели. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия әгъзалары чакыртып алу буенча тавыш бирү нәтиҗәләрен шәхсән үзләре билгелиләр. Чакыртып алу буенча тавыш бирү нәтиҗәләре турында ике нөсхәдә беркетмә һәм җыелма таблица төзелә, аларга Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең хәлиткеч тавыш хокукына ия шунда катнашучы барлык әгъзалары имза сала. Чакыртып алу буенча тавыш бирү нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе чакыртып алу буенча тавыш бирү нәтиҗәләре турында карар кабул итә. Чакыртып алу буенча тавыш бирү нәтиҗәләре турындагы беркетмәгә түбәндәге күрсәткечләр кертелә:

1) Татарстан Республикасы территориясендә территория комиссияләре саны;

2) территория комиссияләренең тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәләре саны;

3) территория комиссияләренең тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәләрендә барлык юллар буенча кушып бирелгән күрсәткечләр.

2. Чакыртып алу буенча тавыш бирү нәтиҗәләре турындагы беркетмәгә шулай ук тиешле комиссия тарафыннан алынган бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны, түбәнгерәк комиссияләргә бирелгән бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны, тиешле комиссия тарафыннан юкка чыгарылган файдаланылмаган бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны һәм югалган бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны турындагы күрсәткечләр дә кертелә.

3. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенең чакыртып алу буенча тавыш бирү нәтиҗәләре турындагы җыелма таблицасына шулай ук тиешле территория комиссиясе тарафыннан алынган бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны, участок комиссияләренә бирелгән бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны, тиешле комиссия тарафыннан юкка чыгарылган файдаланылмаган бүтән участокта тавыш бирү таныклыклары саны һәм тиешле территория комиссиясендә югалган тавыш бирү таныклыклары саны турындагы күрсәткечләр дә кертелә.

4. Чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлекләренә кертелгән чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның яртысыннан күбрәге аны хуплап тавыш бирсә, чакыртып алу узган дип танылa.

5. Әгәр чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлекләренә кертелгән чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның яртысыннан күбрәге катнашмаса, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе чакыртып алу буенча тавыш бирүне узмаган дип таный.

6. Әгәр чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлекләренә кертелгән чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның яртысы яисә яртысыннан кимрәге хуплап тавыш бирсә, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе чакыртып алуны узмаган (карарны кабул ителмәгән) дип таный.

7. Чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар саны тавыш бирү әрҗәләрендә табылган билгеләнгән рәвештәге бюллетеньнәр саны буенча билгеләнә. Чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашкан чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар саны чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегендә тавыш бирү көнендә тавыш бирү урынында тавыш биргән катнашучылар имзалары саны һәм чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегендә чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучының тавыш бирү урыныннан читтә тавыш биргәнлеге хакында ясалган тамгалар саны буенча билгеләнә.

8. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе чакыртып алу буенча тавыш бирү нәтиҗәләрен түбәндәге очракларда гамәлгә яраксыз дип саный:

1) әгәр тавыш бирү уздырганда яисә тавыш бирү йомгакларын билгеләгәндә юл куелган хокук бозулар чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның ихтыяр белдерү нәтиҗәләрен дөрес билгеләргә мөмкинлек бирмәсә;

2) әгәр алар Татарстан Республикасы территориясендә тавыш бирү тәмамланган вакытка чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлекләренә кертелгән чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның гомуми саныннан кимендә дүрттән бер өлешен эченә алган чакыртып алу буенча тавыш бирү тәмамланган вакытка тавыш бирүдә катнашучылар исемлекләре булган чакыртып алу буенча тавыш бирү участокларының бер өлешендә гамәлгә яраксыз дип танылса;

3) суд карары буенча.

9. Барлык дәрәҗәдәге чакыртып алу буенча тавыш бирү комиссияләре документациясе, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар имзалары белән имзалар кәгазьләрен, бюллетеньнәрне, бүтән участокта тавыш бирү таныклыкларын һәм чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлекләрен дә кертеп, тавыш бирү йомгаклары һәм чакыртып алу буенча тавыш бирү нәтиҗәләре басылып чыкканнан соң бер ел дәвамында сакланырга тиеш. Чакыртып алу комиссияләренең тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәләрен һәм тавыш бирү йомгаклары турында җыелма таблицаларын саклау вакыты тавыш бирү йомгаклары басылып чыккан көннән алып биш ел тәшкил итә. Тавыш бирү йомгаклары турында, чакыртып алу буенча тавыш бирү нәтиҗәләре турында чакыртып алу комиссиясе карарына судта шикаять каралган, гражданнарның чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашу хокукын бозуга бәйле җинаять эшләре кузгатылган очракта, чакыртып алу буенча тавыш бирүнең тиешле документациясен саклау вакыты суд карарының законлы көченә керүенә (закон нигезендә эшне туктатуга) кадәр дәвам итә. Чакыртып алу буенча тавыш бирү документациясенең саклануы өчен җаваплылык документацияне югарырак чакыртып алу комиссиясенә йә архивка тапшырганга кадәр тиешле чакыртып алу комиссиясе рәисенә (рәис урынбасарына) һәм секретарена йөкләнә.

10. Чакыртып алу буенча тавыш бирү документациясен саклау, архивка тапшыру һәм юк итү тәртибе, тиешле дәүләт архив ор-

ганнары белән килештереп, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан раслана.

52 статья. **Чакыртып алу буенча тавыш бирүдә кабул ителгән карарны гамәлгә ашыру тәртибе**

1. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе чакыртып алу буенча тавыш бирү нәтиҗәләрен билгеләгәннән һәм чакыртып алуны узган дип таныганнан соң Татарстан Республикасы Президентына кичекмәстән бу хакта язмача хәбәр итә.

2. Чакыртып алу узган дип танылган очракта Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан аның тиешле карары Россия Федерациясе Президентына һәм Татарстан Республикасы Президенты вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында карар кабул итү өчен Татарстан Республикасы Дәүләт Советына җибәрелә.

3. Татарстан Республикасы Президенты вәкаләтләрен вакытыннан алда туктату турында карар «Россия Федерациясе дәүләт хакимиятенең закон чыгару (вәкиллекле) һәм башкарма органнары эшчәнлеген оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 19 статьясында билгеләнгән тәртиптә кабул ителә.

53 статья. **Чакыртып алу буенча тавыш бирү йомгакларын һәм тавыш бирү нәтиҗәләрен бастырып чыгару һәм халыкка җиткерү**

1. Чакыртып алу комиссиясе һәр чакыртып алу буенча тавыш бирү участогы, чакыртып алу комиссиясенең эшчәнлеге кагыла торган һәр территория буенча чакыртып алу буенча тавыш бирү йомгакларын, тавыш бирү нәтиҗәләрен танышу өчен чакыртып алу буенча тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәдә һәм тавыш бирү йомгаклары турында турыдан-туры түбәнгерәк чакыртып алу комиссияләре беркетмәләрендә булган күрсәткечләр күләмендә чакыртып алу буенча тавыш бирү нәтиҗәләрен чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларга, инициатив төркемнең, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның башка төркеменең вәкаләтле вәкилләренә, күзәтүчеләргә, чит ил (халыкара) күзәтүчеләренә, массакүләм мәгълүмат чаралары вәкилләренә алар таләбе буенча бирә.

2. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе чакыртып алу буенча тавыш бирү нәтиҗәләре турындагы гомуми күрсәткечләрне массакүләм мәгълүмат чараларына чакыртып алу

буенча тавыш бирү нәтиҗәләре билгеләнгәннән соң бер тәүлек эчендә җибәрә.

3. Чакыртып алу буенча тавыш бирү нәтиҗәләрен, шулай ук чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның «Чакыртып алуны хуплыйм» һәм «Чакыртып алуга каршы» позицияләре буенча бирелгән тавышлары саны турындагы күрсәткечләрне рәсми бастырып чыгару тавыш биргән көннән бер айдан да соңга калмыйча Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе тарафыннан башкарыла.

4. Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе һәм территория комиссияләре тиешле дәрәҗәдәге чакыртып алу комиссияләренең чакыртып алу буенча тавыш бирү йомгаклары һәм тавыш бирү нәтиҗәләре турындагы беркетмәләрендә булган күрсәткечләрне һәм турыдан-туры түбәнгерәк чакыртып алу комиссияләренең тавыш бирү йомгаклары турындагы беркетмәләрендә булган һәм шуларга нигезләнеп тиешле чакыртып алу комиссияләрендә чакыртып алу буенча тавыш бирү йомгаклары, тавыш бирү нәтиҗәләре билгеләнгән күрсәткечләрне бастырып чыгара (халыкка җиткерә). Чакыртып алу буенча тавыш бирү нәтиҗәләре турында тулы күрсәткечләрне рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү) тавыш бирү көненнән алып ике ай дәвамында башкарыла. Чакыртып алу буенча тавыш бирү нәтиҗәләре турында тулы күрсәткечләрне рәсми бастырып чыгару (халыкка җиткерү) көненнән алып өч ай дәвамында барлык чакыртып алу комиссияләренең чакыртып алу буенча тавыш бирү йомгаклары һәм тавыш бирү нәтиҗәләре турындагы күрсәткечләр «Интернет» гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырыла.

54 статья. **Чакыртып алу буенча тавыш бирү үткәргәндә «Сайлаулар» ДАСтан файдалану**

1. Чакыртып алу буенча тавыш бирүне әзерләгәндә һәм үткәргәндә, шулай ук гражданнарның чакыртып алу буенча тавыш бирүгә хокукларын тәэмин итү буенча комиссияләрнең башка вәкаләтләрен гамәлгә ашыру өчен федераль законнарда каралган тәртиптә бары тик «Сайлаулар» ДАСтан гына файдаланыла. «Сайлаулар» ДАСка чакыртып алу буенча тавыш бирү йомгаклары турында, тавыш бирү нәтиҗәләре турында чакыртып алу комиссияләренең беркетмәләрендәге белешмәләрне кертү мәҗбүри.

2. Чакыртып алу буенча тавыш бирү уздырганда, шул исәптән чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларны теркәгәндә (исәпкә алганда), чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлеген төзегәндә, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар тавышларын санаганда, чакыртып алу буенча тавыш бирү йомгакларын билгеләгәндә һәм тавыш бирү нәтиҗәләрен ачыклаганда закон нигезендә «Сайлаулар» ДАСтан гына файдаланганда тиешле чакыртып алу комиссиясе «Сайлаулар» ДАСтан (аның аерым техник чараларыннан) файдалануны тикшереп тору өчен чакыртып алу комиссиясенең хәлиткеч тавыш һәм киңәш бирү тавышы хокукына ия әгъзалары кергән төркем төзиләр. Чакыртып алу комиссияләренең барлык әгъзалары, күзәтүчеләр «Сайлаулар» ДАСка кертелүче теләсә нинди мәгълүмат белән танышырга хокуклы.

3. Тавыш бирү башланган мизгелдән тавыш бирү йомгаклары турындагы (чакыртып алу буенча тавыш бирү нәтиҗәләре турындагы) беркетмәгә тиешле чакыртып алу комиссиясе тарафыннан имза салынган мизгелгә кадәр түбәнгерәк чакыртып алу комиссияләреннән югарырак чакыртып алу комиссияләренә күрсәткечләр тапшыру юлы белән тавыш бирүнең барышын һәм тавыш бирү йомгакларын күзәтеп тору өчен – «Сайлаулар» ДАС, ә аның аерым техник чаралары чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның тавышларын санау өчен файдаланыла. Тавыш бирүнең барышы һәм тавыш бирү йомгаклары турында «Сайлаулар» ДАС (аның аерым техник чаралары) аша алынган күрсәткечләр, әгәр Федераль законда, башка законда бүтәнчә билгеләнмәгән булса, юридик әһәмияткә ия булмаган якынча мәгълүмат кына булып тора.

4. Әгәр тавыш бирү йомгаклары турында участок комиссиясе беркетмәсе күрсәткечләрен «Сайлаулар» ДАСка керткәннән соң аны керткәндә техник хаталар җибәрелгәнлеге ачыкланса, төзәтү таләп ителә торган күрсәткечләр «Сайлаулар» ДАСка бары тик югарырак чакыртып алу комиссиясенең дәлилләнгән карары буенча гына кертелә.

5. Чакыртып алу буенча тавыш бирү барышында «Сайлаулар» ДАСтан (аның аерым техник чараларыннан) файдаланган очракта, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның тавыш бирүдә катнашуы турындагы, тавыш бирүнең алданрак бирелгән һәм иң соңгы йомгаклары турындагы күрсәткечләре «Интернет» гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәре абонентлары өчен оператив файдаланырлык («Бары тик уку» режимында) булырга тиеш. Андый күрсәткечләрне бирү

тәртибе һәм вакытлары федераль закон, башка закон таләпләренә каршы килмәскә тиеш.

### 11 бүлек. **Гражданнарның чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашу хокукын бозуларга карата шикаять белдерү һәм чакыртып алу буенча тавыш бирүне үткәргәндә законнарны бозган өчен җаваплылык**

55 статья. **Гражданнарның чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашу хокукын боза торган карарларга һәм гамәлләргә (гамәл кылмауга) карата шикаять белдерү**

1. Гражданнарның чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашу хокукын боза торган карарларга һәм гамәлләргә (гамәл кылмауга) шикаять белдерү «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законның 75 статьясында гражданнарның Россия Федерациясе субъекты референдумында катнашу хокукын боза торган карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) шикаять белдерү өчен билгеләнгән тәртиптә һәм вакытларда гамәлгә ашырыла.

2. Чакыртып алу буенча тавыш бирүне үткәргәндә Россия Федерациясе законнарын бозган өчен җаваплылык федераль закон белән билгеләнә.

56 статья. **Инициатив төркемне, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның башка төркемен теркәүне юкка чыгару нигезләре**

Инициатив төркемне, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның башка төркемен теркәү Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе гаризасы буенча тавыш бирү көненә кадәр өч көннән дә соңга калмыйча суд тарафыннан түбәндәге очракларда юкка чыгарылырга мөмкин:

1) чакыртып алу буенча тавыш бирүне үткәрү инициативасын күрсәтү тәртибе бозылу;

2) инициатив төркемнең, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның башка төркеменең әгъзалары һәм (яисә) вәкаләтле вәкилләре тарафыннан чакыртып алу мәсьәләләре буенча агитация үткәрү һәм чакыртып алу буенча тавыш бирүне үткәрү инициативасын күрсәтү, имзалар җыюны оештыру эшчәнлеген, шулай ук чакыртып алу буенча тавыш бирүнең аерым нәтиҗәсен алуга юнәлдерелгән эшчәнлекне финанслау тәртибен бозу;

3) инициатив төркемнең, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның башка төркеменең әгъзалары һәм (яисә) вәкаләтле вәкилләре үзләренең вазыйфаи һәм хезмәттәге торышы өстенлекләреннән файдалану;

4) инициатив төркемнең, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның башка төркеменең әгъзалары һәм (яисә) вәкаләтле вәкилләре тарафыннан чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларны кызыксындыру факты билгеләнү;

5) «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законда, әлеге Законда билгеләнгән башка нигезләр булу.

57 статья. **Чакыртып алу буенча тавыш бирү йомгаклары һәм тавыш бирү нәтиҗәләре турындагы карарны юкка чыгару**

1. Әгәр тавыш бирүне үткәргәндә яисә тавыш бирү йомгакларын билгеләгәндә «Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» Федераль законны, әлеге Законны бозу очраклары булса, югарырак комиссия чакыртып алу буенча тавыш бирү йомгаклары, тавыш бирү нәтиҗәләре билгеләнгәнчегә кадәр тавыш бирү йомгаклары турында түбәнгерәк комиссиянең карарын юкка чыгарырга һәм тавышларны кабат санау турында карар кабул итәргә мөмкин, җибәрелгән хокук бозулар чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның ихтыяр белдерү нәтиҗәләренең дөреслеген билгеләргә мөмкинлек бирмәсә, тавыш бирү йомгакларын дөрес түгел дип танырга мөмкин.

2. Югарырак комиссия чакыртып алу буенча тавыш бирү йомгакларын, тавыш бирү нәтиҗәләрен билгеләгәннән соң, түбәнгерәк комиссиянең тавыш бирү йомгаклары турындагы карары бары тик суд тарафыннан гына юкка чыгарылырга мөмкин йә тавыш бирү йомгаклары турында комиссия беркетмәсенә һәм (яисә) җыелма таблицага үзгәрешләр кертү турында суд тарафыннан карар кабул ителергә мөмкин. Тавыш бирү йомгакларын юкка чыгару турында гариза белән судка мөрәҗәгать итү турында, тавыш бирү йомгаклары хакында комиссия беркетмәсенә һәм (яисә) җыелма таблицага үзгәрешләр кертү турында комиссия тарафыннан кабул ителгән карар хакында әлеге комиссия Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясенә хәбәр итә. Тавыш бирү йомгаклары турында комиссия беркетмәсенә һәм (яисә) җыелма

таблицага үзгәрешләр кертү турында суд тарафыннан карар кабул ителгән очракта, әлеге беркетмәне һәм (яисә) җыелма таблицаны төзегән комиссия тавыш бирү йомгаклары турында «Кабат» тамгасы белән яңа беркетмә һәм (яисә) «Кабат» тамгасы белән яңа җыелма таблица төзи.

3. Тиешле дәрәҗәдәге суд, тавыш бирү йомгаклары турында комиссия карарын юкка чыгарып, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар тавышларын кабат санау турында карар кабул итәргә мөмкин, әгәр җибәрелгән хокук бозулар чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның ихтыяр белдерү нәтиҗәләренең дөреслеген билгеләргә мөмкинлек бирмәсә, тавыш бирү йомгакларын дөрес түгел дип тану турында карар кабул итәргә мөмкин.

4. Тиешле дәрәҗәдәге суд чакыртып алу буенча тавыш бирү йомгаклары турында, тавыш бирү нәтиҗәләре турында комиссия карарын чакыртып алуда катнашучыларның исемлекләрен төзү кагыйдәләрен, комиссияләр төзү тәртибен, чакыртып алу мәсьәләләре буенча агитация үткәрү кагыйдәләрен һәм чакыртып алу буенча тавыш бирүне үткәрү инициативасын күрсәтү, имзалар җыюны оештыру эшчәнлеген, шулай ук чакыртып алу буенча тавыш бирүнең аерым нәтиҗәсен алуга юнәлдерелгән эшчәнлекне финанслау тәртибен бозу очрагында, инициатив төркем әгъзалары һәм вәкаләтле вәкилләре үзләренең вазыйфаи хәленнән чакыртып алу буенча тавыш бирүнең үзләре теләгән нәтиҗәсен алу максатында файдаланган очракта, чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларны әлеге затлар тарафыннан шул ук максатларда сатып алу фактлары билгеләнүе ачыкланган очракта, тавыш бирү һәм тавышларны санау (аларның үткәрелүен күзәтүгә каршылык күрсәтүне кертеп) тәртибен бозган очракта, шулай ук чакыртып алу турында законнарны бозуның башка очракларында, әгәр әлеге гамәлләр (гамәлләр кылмау) чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның чын ихтыярын ачыкларга мөмкинлек бирмәсә, юкка чыгарырга мөмкин.

5. Чакыртып алу буенча тавыш бирү нәтиҗәләре турында карарны суд тарафыннан юкка чыгару, әгәр җибәрелгән хокук бозулар чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыларның чын ихтыярын ачыкларга мөмкинлек бирмәсә, чакыртып алу буенча тавыш бирү нәтиҗәләрен дөрес түгел дип тануга китерә. Әгәр чакыртып алу буенча тавыш бирү нәтиҗәләре дөрес түгел дип танылса, Татарстан Республикасы Дәүләт Советы кабат тавыш бирү билгели, ул билгеләнгән көннән алып 60 көннән дә соңга калмыйча үткәрелә.

6. Чакыртып алу буенча тавыш бирү участогында, территориядә тиешле югарырак комиссия тавыш бирү йомгаклары турында беркетмә төзегәннән соң тавыш бирү йомгаклары дөрес түгел дип танылган очракта, әлеге комиссия тавыш бирү йомгаклары турында «Кабат» тамгасы белән яңа беркетмә төзергә тиеш.

7. Югарырак комиссия чакыртып алу буенча тавыш бирү йомгаклары турында беркетмә һәм җыелма таблица төзегәннән соң төзелгән тавыш бирү йомгаклары турында «Кабат» яисә «Тавышларны кабат санау» тамгасы булган беркетмәләр нигезендә югарырак комиссия төзегән беркетмәгә һәм җыелма таблицага тиешле үзгәрешләр кертелә.

8. Әлеге статьяның 2 өлешендә күрсәтелгән суд карары закон көченә кергән очракта, барлык югарырак комиссияләр чакыртып алу буенча тавыш бирү йомгаклары турында, тавыш бирү нәтиҗәләре турында беркетмәләргә үзгәрешләр кертәләр. Әгәр әлеге хәл чакыртып алу буенча тавыш бирү нәтиҗәләре турында Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе карарына үзгәреш кертүгә китерсә, Татарстан Республикасы Үзәк сайлау комиссиясе чакыртып алу буенча тавыш бирү нәтиҗәләре турында яңа карар кабул итә, ул рәсми бастырып чыгарылырга тиеш.

## 12 бүлек. **Йомгаклау һәм күчеш нигезләмәләре**

### 58 статья. **Әлеге Законның үз көченә керүе**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 елның 25 декабре
№ 92-ТРЗ

«Татарстан Республикасы Президентын
чакыртып алу тәртибе турында» Татарстан Республикасы Законына
1 нче кушымта

## ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ПРЕЗИДЕНТЫН ЧАКЫРТЫП АЛУ БУЕНЧА ТАВЫШ БИРҮНЕ ҮТКӘРҮ ИНИЦИАТИВАСЫН КҮРСӘТҮНЕ ХУПЛЫЙ ТОРГАН ИМЗА КӘГАЗЕ

Без, түбәндә имза салучылар, ______________________________
(Татарстан Республикасы Президентын чакыртып алу өчен нигез булып торган фактны билгеләгән Татарстан Республикасы Югары Суды карарын күрсәтеп, Татарстан Республикасы Президентын чакыртып алу өчен нигез күрсәтелә)

бәйле рәвештә Татарстан Республикасы Президентын: ______________________________
(чакыртып алынучының фамилиясе, исеме, атасының исеме)[1]

чакыртып алу буенча тавыш бирүне үткәрү инициативасын хуплыйбыз:

| № | Фамилиясе, исеме, атасының исеме | Туган елы (18 яшьтә булса – өстәмә рәвештә туган датасы һәм ае) | Яшәү урыны адресы | Паспортының яисә граждан паспортын алмаштыручы документының сериясе һәм номеры | Имза кертү датасы | Имза |
|---|---|---|---|---|---|---|
| 1 | | | | | | |
| 2 | | | | | | |
| ... | | | | | | |

Имза кәгазен таныклыйм: ______________________________
(имзалар жыйган затның фамилиясе, исеме, атасының исеме, яшәү урынының адресы, туган датасы, паспортының яисә граждан паспортын алмаштыручы документының сериясе һәм номеры, аны биргән органның исеме яисә коды, имзалар җыйган затның имзасы һәм аны кую датасы)

Инициатив төркемнең вәкаләтле вәкиле: ______________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме, кулдан куелган имзасы һәм аны кертү датасы)

______________________________
(Татарстан Республикасы Президентын чакыртып алу буенча тавыш бирүне үткәрү буенча инициатив төркемгә бирелгән теркәлү таныклыгы номеры, аны бирү датасы, күрсәтелгән таныклыкны биргән комиссия исеме)

Чакыртып алу буенча тавыш бирү фондының махсус счеты № ______________

[1] Юл астындагы текст, шулай ук искәрмә һәм сноска әзерләнгән имза кәгазендә күрсәтелмәскә мөмкин.

«Татарстан Республикасы Президентын чакыртып алу тәртибе турында»
Татарстан Республикасы Законына
2 нче кушымта

Татарстан Республикасы Президентын чакыртып алу буенча тавыш бирү

________________________________________
(тавыш бирү датасы)

## БАШКА УЧАСТОКТА ТАВЫШ БИРҮ ТАНЫКЛЫГЫ №______

________________________________________________________________
(Татарстан Республикасы муниципаль берәмлегенең исеме)[1]

_______________________________________ территориясендә төзелгән _________________________________ номерлы
(участок комиссиясе адресы)

чакыртып алу буенча тавыш бирү участогында чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучылар исемлегенә кертелгән
____________________________________________________________________________________________________
(фамилиясе, исеме, атасының исеме)

____________________________________________________________________________________________________
(паспортының яисә граждан паспортын алмаштыручы документының сериясе һәм номеры)

башка участокта тавыш бирү таныклыгын алды һәм тавыш бирү көнендә үзе була торган чакыртып алу буенча тавыш бирү участогында тавыш бирүдә катнашу хокукына ия.

______________________________________________
(комиссия рәисе, рәис урынбасары, секретаре яисә әгъзасы)

_________________________
(комиссия исеме)

_____________ ___________________
(имза) (фамилиясе һәм инициаллары)

МУ

___________ елның « ___» __________________
(башка участокта тавыш бирү таныклыгын бирү датасы)

Башка участокта тавыш бирү таныклыгы чакыртып алу буенча тавыш бирүдә катнашучыдан тавыш бирү көнендә күрсәткәннән соң алына.

[1]Әгәр чакыртып алу буенча тавыш бирү участогы җирлек территориясендә урнашса, шулай ук муниципаль район исеме күрсәтелә.

«Татарстан Республикасы Президентын чакыртып алу тәртибе турында»
Татарстан Республикасы Законына
3 нче кушымта

# ТАВЫШ БИРҮ ЙОМГАКЛАРЫ ТУРЫНДАГЫ БЕРКЕТМӘГӘ КЕРТЕЛГӘН КҮРСӘТКЕЧЛӘРНЕҢ КОНТРОЛЬ ЧАГЫШТЫРМАЛАРЫ

(ӘЛЕГЕ ЗАКОННЫҢ 48 СТАТЬЯСЫ НИГЕЗЕНДӘ НОМЕРЛАНГАН БЕРКЕТМӘ ЮЛЛАРЫ САННАР БЕЛӘН БИЛГЕЛӘНДЕ)

| | |
|---|---|
| 1 зуррак яисә тигез | 3 + 4 |
| 2 тигез | 3 + 4 + 5 + 9д – 9е |
| 6 + 7 | зуррак (чакыртып алу буенча тавыш бирүдә тавыш бирү өчен билгеләнмәгән рәвештәге бюллетеньнәр табылган очракта) яисә 8 + 9 тигез |
| 9 тигез | 10 + беркетмәнең шуннан соңгы барлык юллары |

## 1885. «Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2012 елның 24 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Татарстан Республикасында муниципаль берәмлекнең вәкиллекле органы депутаты, җирле үзидарәнең сайланулы органы әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вәкаләтләрен гамәлгә ашыру гарантияләре турында» 2009 елның 12 февралендәге 15-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2009, № 2; 2010, № 1 – 2; 2011, № 5) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 1 статьяда:

а) 1 өлештә «(алга таба – муниципаль вазыйфа биләүче зат)» сүзләрен төшереп калдырырга;

б) 2 өлешкә түбәндәге эчтәлекле җөмлә өстәргә: «Әлеге Законның муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләгән затларны пенсия белән тәэмин итү өлешендә гамәли көче муниципаль берәмлекнең контроль-хисап органы рәисенә дә, шулай ук муниципаль берәмлекнең контроль-хисап органы рәисе урынбасарына һәм аудиторына, әгәр күрсәтелгән вазыйфалар билгеләнгән тәртиптә муниципаль вазыйфаларга кертелгән булса, кагыла.»;

в) түбәндәге эчтәлекле 4 өлеш өстәргә:

«4. Әлеге Законда кулланыла торган терминнар һәм төшенчәләр «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закондагы мәгънәләрендә кулланыла.»;

2) 6 статьяны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«6 статья. **Муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләгән затны пенсия белән тәэмин итү**

1. Муниципаль вазыйфаны даими нигездә биләгән затлар әлеге Закон нигезендә түбәндәге шартларда дәүләт пенсиясенә өстәмә (алга таба – пенсиягә өстәмә) алу хокукына ия булалар:

1) муниципаль вазыйфаны, шул исәптән 1995 елның 5 мартыннан 2006 елның 1 гыйнварына кадәр Татарстан Республикасында җирле үзидарәнең сайланулы органы депутаты, әгъзасы, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи заты вазыйфасын, кимендә биш ел даими нигездә йә җирле үзидарә органының тулы бер вәкаләтләр срогында, әмма өч елдан да кимрәк булмаган срокта биләсә;

2) вәкаләтләре туктатылуга бәйле рәвештә вазыйфасыннан азат ителсә (шул исәптән вакытыннан алда), вәкаләтләрне туктатуның түбәндәгеләргә бәйле очраклары моңа керми:

а) ышаныч югалту;

б) вазыйфасыннан читләштерү;

в) отставкага җибәрелү;

г) судның гаепләү карарының закон көченә керүе;

д) сайлаучылар тарафыннан чакыртып алу;

е) федераль законнарда билгеләнгән чикләүләрне һәм тыюларны үтәмәү, йөкләмәләрне үтәмәү;

ж) муниципаль вазыйфаны биләүгә тоткарлык тудыра торган шартлар ачыклану;

з) муниципаль вазыйфаны биләүгә бәйле вәкаләтләрне үтәмәү яисә тиешенчә үтәмәү;

и) сайлаулар һәм референдумнар турындагы законнарны бозган өчен административ җәза билгеләү турында суд карарының (карарнамәсенең) закон көченә керүе;

3) муниципаль вазыйфаны 2006 елның 1 гыйнварына һәм (яисә) аннан соңрак биләсә;

4) «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» 2001 елның 17 декабрендәге 173-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» Федераль закон) нигезендә картлык (инвалидлык) буенча хезмәт пенсиясе билгеләнсә.

2. Пенсиягә өстәмә күләме түбәндәге формула буенча билгеләнә:

ДП = ЕДВ × РК × КС, монда

ДП – пенсиягә өстәмә;

ЕДВ – тиешле муниципаль вазыйфа буенча муниципаль хокукый актларда билгеләнгән айлык акчалата түләү;

РК – муниципаль район һәм шәһәр округы башлыгы, башлык урынбасары вазыйфаларын биләгән затлар өчен билгеләнгән исәп-хисап коэффициенты – 1,2, җирле үзидарә органнарында башка муниципаль вазыйфаларны биләгән затлар өчен – 1;

КС – стаж коэффициенты, ул муниципаль вазыйфаларны биш елдан җиде елга кадәр йә җирле үзидарә органы вәкаләтләрен тулы бер срок, әмма кимендә өч ел биләгәндә 0,45кә тиң; муниципаль вазыйфаларны кимендә җиде ел биләгәндә һәм муниципаль һәм (яисә) дәүләт вазыйфаларын биләү срогы (стажы), дәүләт һәм (яисә) муниципаль хезмәт стажы гомумән алганда кимендә унике ел булганда йә муниципаль вазыйфаларны кимендә ун ел биләгәндә 0,65кә тиң; муниципаль вазыйфаларны ун елдан артыграк биләгәндә һәм муниципаль һәм (яисә) дәүләт вазыйфаларын биләү срогы (стажы), дәүләт һәм (яисә) муниципаль хезмәт стажы гомумән алганда кимендә унбиш ел булганда 0,7гә тиң.

3. Муниципаль берәмлек башлыгы вазыйфасын биләгән затның пенсиясенә өстәмәнең әлеге статьяның 2 өлеше нигезендә билгеләнгән күләме Татарстан Республикасы министрының дәүләт пенсиясенә өстәмә күләме зурлыгыннан артыграк була алмый, ул зурлык түбәндәгеләрне тәшкил итә:

1) хезмәт өчен түләүнең беренче төркеменә керә торган муниципаль район яисә шәһәр округы башлыгы вазыйфасы буенча – Татарстан Республикасы министрының дәүләт пенсиясенә өстәмәнең 1,4 күләменнән, икенче төркеме буенча – 1,3, өченче һәм дүртенче төркемнәре буенча – 1, сигезенче төркеме буенча – 0,9;

2) хезмәт өчен түләүнең дүртенче төркеменә керә торган шәһәр яисә авыл җирлеге башлыгы вазыйфасы буенча – Татарстан Республикасы министрының дәүләт пенсиясенә өстәмәнең 0,71 күләменнән, бишенче төркеме буенча – 0,65, алтынчы төркеме буенча – 0,61, җиденче төркеме буенча – 0,54, тугызынчы төркеме буенча – 0,42, унынчы төркеме буенча – 0,35, унберенче төркеме буенча – 0,31, уникенче төркеме буенча – 0,27.

4. Муниципаль берәмлекләрне хезмәт өчен түләү төркемнәренә кертү үз вәкаләтләрен даими нигездә гамәлгә ашыручы депутатлар, җирле үзидарәнең сайланулы вазыйфаи затлары хезмәте өчен түләү чыгымнарын булдыру нормативларын билгели торган

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты норматив хокукый акты нигезендә гамәлгә ашырыла.

5. Татарстан Республикасы министрының дәүләт пенсиясенә өстәмә күләме әлеге статьяның 3 өлеше максатларында түбәндәге тәртиптә билгеләнә:

1) муниципаль вазыйфаларны биш елдан җиде елга кадәр йә җирле үзидарә органы вәкаләтләрен тулы бер срок, әмма кимендә өч ел биләгән затларга карата – дәүләт вазыйфасын бер елдан өч елга кадәр биләгән Татарстан Республикасы министрының дәүләт пенсиясенә өстәмә күләме буенча;

2) муниципаль вазыйфаларны кимендә җиде ел биләгән һәм муниципаль һәм (яисә) дәүләт вазыйфаларын биләү срогы (стажы), дәүләт һәм (яисә) муниципаль хезмәт стажы гомумән алганда кимендә унике ел булган йә муниципаль вазыйфаларны кимендә ун ел биләгән затларга карата – дәүләт вазыйфасын өч елдан артыграк биләгән Татарстан Республикасы министрының дәүләт пенсиясенә өстәмә күләме буенча;

3) муниципаль вазыйфаларны ун елдан артыграк биләгән һәм муниципаль һәм (яисә) дәүләт вазыйфаларын биләү срогы (стажы), дәүләт һәм (яисә) муниципаль хезмәт стажы гомумән алганда кимендә унбиш ел булган затларга карата – дәүләт вазыйфаларын кимендә унбиш ел биләгән йә күрсәтелгән вазыйфаларны өч елдан артыграк биләгән һәм дәүләт хезмәте стажы гомумән алганда кимендә унбиш ел булган Татарстан Республикасы министрының дәүләт пенсиясенә өстәмә күләме буенча.

6. Муниципаль вазыйфаны биләгән затның, әлеге статьяның 3 өлешендә күрсәтелгән затлардан тыш, пенсиясенә өстәмәнең максималь күләме, муниципаль берәмлек башлыгы урынбасары вазыйфасы буенча – тиешле муниципаль берәмлек башлыгы урынбасары вазыйфасын биләгән затның пенсиясенә әлеге статьяның 3 өлеше нигезләмәләрен исәпкә алып саналган өстәмәнең 0,8 күләменнән, башка муниципаль вазыйфа буенча – 0,6 күләменнән һәм Татарстан Республикасы министрының дәүләт пенсиясенә өстәмәнең 0,9 күләменнән, күрсәтелгән вазыйфаларны биләү дәвамлылыгының әлеге статьяның 2 һәм 5 өлешләрендә каралган шундый ук күрсәткечләре булганда, артыграк була алмый.

7. Пенсиягә өстәмәнең әлеге статьяның 2 – 6 өлешләре нигезендә билгеләнгән күләме «Россия Федерациясендә хезмәт пенсияләре турында» Федераль законның 14 статьясындагы 2 пункты нигезендә билгеләнгән картлык буенча хезмәт пенсиясенең иминләштерү өлешендә беркетелгән база күләменнән артмаган очракта, пенсиягә өстәмә картлык буенча хезмәт пенсиясенең

иминлəштерү өлешендə беркетелгəн шушы база күлəменə тиң күлəмдə түлəнə.

8. Пенсиягə өстəмə күлəме, шундый түлəүне билгелəүне сорап мөрəҗəгать иткəн затның телəге белəн, билəнə торган иң соңгы муниципаль вазыйфа буенча, йə «Россия Федерациясендə хезмəт пенсиялəре турында» Федераль закон нигезендə картлык буенча хезмəт пенсиясе алу хокукын бирə торган яшькə җиткəн көнгə билəнə торган муниципаль вазыйфа буенча, йə башка муниципаль вазыйфа буенча, əгəр ул вазыйфа кимендə унике ай билəнгəн булса, айлык акчалата түлəүдəн чыгып исəплəнə.

9. Муниципаль вазыйфаны даими нигездə билəгəн һəм бер үк вакытта əлеге Закон нигезендə пенсиягə өстəмə һəм «Татарстан Республикасы дəүлəт вазыйфалары турында» 2006 елның 4 мартындагы 16-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы нигезендə пенсиягə өстəмə, дəүлəт граждан хезмəтендə яисə муниципаль хезмəттə тиешле еллар эшлəгəн өчен пенсия, тиешле еллар эшлəгəн өчен башка нигезлəр буенча пенсия, гомер буена айлык акчалата түлəү алу, гомер буена өстəмə рəвештə айлык матди тəэмин ителү, федераль законнар, Татарстан Республикасының, Россия Федерациясенең башка субъектларының законнары, муниципаль хокукый актлар нигезендə дəүлəт пенсиясенə башка өстəмə алу хокукына ия затка əлеге Закон нигезендə пенсиягə өстəмə түлəнə яисə, əгəр законнарда яки муниципаль хокукый актларда башкасы билгелəнмəгəн булса, аның телəге буенча бүтəн түлəү башкарыла.

10. Пенсиягə өстəмə билгелəү һəм түлəү, аның күлəмен яңадан исəплəү (индексациялəү), өстəмəне түлəүне туктатып тору һəм яңадан түли башлау Татарстан Республикасы дəүлəт граждан хезмəткəрлəренə тиешле еллар эшлəгəн өчен пенсия билгелəү һəм түлəү өчен əлеге Законда каралган үзенчəлеклəрне исəпкə алып билгелəнгəн тəртиптə башкарыла.

11. Муниципаль вазыйфаны даими нигездə билəүче зат үзенең вазыйфаи бурычларын үтəүгə бəйле рəвештə, шул исəптəн вəкалəтлəрен туктатканнан соң, вафат булган очракта, аның гаилə əгъзалары туендыручыны югалту очрагы буенча федераль законнарда билгелəнгəн тəртиптə пенсия алу хокукына ия.».

**2 статья**

Əлеге Закон рəсми басылып чыккан көненнəн соң 10 көн узгач үз көченə керə.

**3 статья**

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты һәм Татарстан Республикасының башка дәүләт органнары өч ай эчендә үз норматив хокукый актларын әлеге Законга туры китерергә, шулай ук әлеге Законны гамәлгә ашыруны тәэмин итә торган норматив хокукый актлар кабул итәргә тиеш.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 елның 25 декабре
№ 93-ТРЗ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

**1886. «Физик культура һәм спорт турында» Татарстан Республикасы Законының 27 статьясына үзгәреш кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2012 елның 24 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Физик культура һәм спорт турында» 2008 елның 8 октябрендәге 99-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 27 статьясындагы 7 өлешенә (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2008, № 10 (I өлеш); 2010, № 6 (I өлеш); 2011, № 5; Ватаным Татарстан, 2012, 14 июль), аны түбәндәге редакциядә бәян итеп, үзгәреш кертергә:

«7. Дәүләт милкендәге спорт корылмалары, федераль законнарда билгеләнгән очраклардан тыш, хосусыйлаштырылырга тиеш түгел.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 елның 25 декабре
№ 94-ТРЗ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

**1887. «Торак төзелеше үсешенә ярдәм итү турында» Федераль законның 16⁶ статьясын гамәлгә ашыру чаралары хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2012 елның 24 декабрендә
кабул ителде

1 статья. **Гомуми нигезләмәләр**

Әлеге Закон «Торак төзелеше үсешенә ярдәм итү турында» 2008 елның 24 июлендәге 161-ФЗ номерлы Федераль законның (алга таба – Федераль закон) $16^6$ статьясындагы 36 өлеше нигезендә Торак төзелеше үсешенә ярдәм итү федераль фондының (алга таба – Фонд) эконом класслы торак төзелеше өчен, шул исәптән мондый торак төзү максатларында комплекслы үзләштерү өчен, түләүсез вакытлыча файдалануга яисә арендага тапшырылган җир кишәрлекләрендә төзелгән яисә төзелеп килүче эконом класслы торакка кертү шартларына туры килә торган күпфатирлы йортларда, торак йортларда (шул исәптән индивидуаль торак төзелеше объектларында) (алга таба – эконом класслы торак) торак урыннарын сатып алу хокукына ия гражданнар исемлекләрен (алга таба – исемлек) төзү кагыйдәләрен һәм күрсәтелгән гражданнарны исемлекләргә кертү тәртибен, аерым алганда, чиратлылыгын билгели.

2 статья. **Исемлекләр төзү мәсьәләләре буенча Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органнары вәкаләтләре**

1. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты:

1) әлеге статьяның 2 өлешендә каралган вәкаләтләрне гамәлгә ашыручы Татарстан Республикасы башкарма хакимияте органын (алга таба – вәкаләтле орган) билгели;

2) гражданнарның гаризаларын теркәү кенәгәсе (алга таба – теркәү кенәгәсе), шулай ук муниципаль берәмлек территориясендә исемлекләргә кертү хокукына ия гражданнарның гаризалары исемлеге (алга таба – гражданнарның исәпкә алынган гаризалары исемлеге) рәвешен һәм алып бару тәртибен билгели;

3) исемлеккә кертү турында граждан гаризасының рәвешен билгели;

4) гражданның өлешле төзелештә катнашу шартнамәсен яисә сату-алу шартнамәсен төзүгә язма ризалыгы (алга таба – шартнамә төзүгә гражданның ризалыгы) рәвешен билгели;

5) әлеге Законда каралган мәгълүмати хәбәрләрне бастырып чыгарырга тиешле рәсми массакүләм мәгълүмат чараларын билгели.

2. Вәкаләтле орган:

1) әлеге Законның 3 статьясындагы 2 өлешенең 3 пунктында каралган тәкъдимнәрне (алга таба – җирле үзидарәнең вәкаләтле органы тәкъдимнәре) әзерләү турындагы гарызнамәләрне җирлекләрнең һәм шәһәр округларының җирле үзидарә органнарына (алга таба – җирле үзидарәнең вәкаләтле органы) җибәрә, аларны җыюны һәм гомумиләштерүне тәэмин итә;

2) җирле үзидарәнең вәкаләтле органы тәкъдимнәренә таянып, Федераль законның 11 статьясындагы $6^8$ һәм $6^9$ өлешләре нигезендә эконом класслы торак төзелеше өчен Фондның җир кишәрлекләреннән түләүсез вакытлыча файдалану шартнамәләрен төзү хокукына аукционнар уздыру турындагы үтенечнамәләрне (алга таба – үтенечнамәләр) әзерли һәм Фондка җибәрә;

3) җирле үзидарәнең вәкаләтле органы тәкъдимнәре составында муниципаль берәмлекләр территориясендә эконом класслы торак төзү өчен файдаланырга мөмкин булган федераль милектәге җир кишәрлекләре, шул исәптән аларда урнашкан күчемсез мөлкәт объектлары белән, булу турында белешмәләр алган очракта, бер үк вакытта Федераль законның 11 статьясында каралган исемлекләрне үтенечнамәләр белән бергә җибәрүне тәэмин итә;

4) әлеге Законда каралган мәгълүмати хәбәрләрне рәсми массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгаруны һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итә;

5) Федераль законда каралган тәртиптә федераль милектәге җир кишәрлекләрен яисә Фондның җир кишәрлекләрен эконом класслы торак төзелеше өчен мондый җир кишәрлекләреннән түләүсез вакытлыча файдалану яисә аренда шартнамәсен төзү хокукына аукционнар (алга таба – аукцион) уздыру максатында сайлап алу буенча Фонд гамәлләрен уздырганда Фонд белән хезмәттәшлектә тора;

6) әлеге Законны гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан билгеләнгән бүтән вәкаләтләрне дә башкара.

3 статья. **Исемлекләр төзү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләре**

1. Муниципаль берәмлек башлыгы:

1) исемлекләрне раслый һәм Федераль законда каралган очракларда аларга үзгәрешләр кертә;

2) исемлекләр, шулай ук аларга үзгәрешләр басылып чыгарга тиешле рәсми массакүләм мәгълүмат чараларын билгели;

3) исемлекләрне һәм аларга үзгәрешләрне шушы исемлекләр расланган һәм аларга үзгәрешләр кертелгән датадан соң биш эш көненнән дә соңга калмыйча рәсми массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгаруны һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә муниципаль берәмлекнең рәсми сайтында урнаштыруны тәэмин итә.

2. Җирле үзидарәнең вәкаләтле органы:

1) Федераль законның $16^6$ статьясындагы 35 өлеше нигезендә Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан билгеләнгән гражданнарның аерым категорияләре һәм аларны исемлекләргә кертү нигезләре исемлегенә (алга таба – исемлек) кертелгән гражданнар турында мондый гражданнарны исемлекләргә кертү өчен нигезләр булуны билгеләү максатында белешмәләр җыюны гамәлгә ашыра һәм муниципаль берәмлекнең эконом класслы торакка кертү шартларына туры килерлек торак урыннарының минималь гомуми күләменә (шул исәптән тиешле бүлмәләр саны белән кирәкле торак урыннарының минималь гомуми санына һәм торак урыннарының гомуми мәйданының минималь күләменә) ихтыяҗын билгели;

2) теркәү кенәгәсен һәм гражданнарның исәпкә алынган гаризалары исемлеген алып бара, аларны алып бару тәртибе нигезендә шулардан өземтәләр бирә;

3) булган очракта, вәкаләтле органга түбәндәге тәкъдимнәрне җибәрә:

а) муниципаль берәмлек территориясендә урнашкан торак пунктлардагы эконом класслы торакка кертү шартларына туры килерлек торак урыннарының минималь гомуми күләменә ихтыяҗ турында (торак төзелешенең күз алдында тотылучы төрен, тиешле бүлмәләр саны белән кирәкле торак урыннарының минималь гомуми санын һәм торак урыннарының гомуми мәйданының минималь күләмен күрсәтеп);

б) эконом класслы торак төзелеше өчен аукционнар уздыру мөмкинлеге булган федераль милектәге һәм муниципаль берәмлек чикләрендә урнашкан җир кишәрлекләре турында;

4) Россия Федерациясе Хөкүмәте раслаган рәвештә исемлекләр төзи, шулай ук мондый исемлекләргә үзгәрешләр әзерли.

4 статья. **Фондның җир кишәрлекләрендә төзелгән яисә төзелеп килүче эконом класслы торак сатып алу хокукына ия гражданнарның гаризалар бирү һәм аларны исәпкә алу тәртибе**

1. Исемлекләргә кертү турындагы гаризаларны (алга таба – гаризалар) бирү хокукына Татарстан Республикасы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән яисә төп эш (хезмәт) урыны булган, исемлеккә кертелгән гражданнар категорияләренә караган Россия Федерациясе гражданнары ия була.

2. Гариза граждан тарафыннан шәхсән яисә вәкиле аша турыдан-туры йә дәүләт хезмәт күрсәтүләренең һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең региональ порталыннан файдаланып электрон рәвештә дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрнең күп функцияле үзәге аша яисә кәгазьдә, исемлеккә кертелә торган Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган белешмәләр составы белән каралган документларны кушып, яшәү урыны яисә төп эш (хезмәт) урыны буенча җирле үзидарәнең вәкаләтле органына бирелә.

3. Гаризаны вәкил аша тапшырган очракта, гаризага Россия Федерациясе законнары нигезендә рәсмиләштерелгән ышанычнамә кушып бирелергә тиеш.

4. Граждан, документлар дәүләт органнары, җирле үзидарә органнары карамагында һәм дәүләт органнары яисә җирле үзидарә органнары буйсынуындагы оешмаларда, шулай ук Фондта булса, әлеге статьяның 2 өлешендә каралган документларны гаризага кушып бирмәскә хокуклы. Бу очракта документлар җирле үзидарәнең вәкаләтле органы тарафыннан ведомствоара йә бүтән рәвешләрдәге хезмәттәшлек тәртибендә мөстәкыйль соратып алына.

5. Гаризада гражданның үз гаризасындагы шәхси белешмәләрне Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә эшкәртүгә ризалыгы күрсәтелә.

6. Мөрәҗәгать итүчегә (аның вәкиленә) мөрәҗәгать итү көнендә гаризаны һәм аңа кушып бирелгән документларны алу турында, шушы документларның исемлеген һәм аларны алу датасын, шулай ук ведомствоара хезмәттәшлек тәртибендә алыначак документлар исемлеген күрсәтеп, расписка бирелә.

7. Әлеге статья нигезендә кергән барлык гаризалар теркәү кенәгәсендә хронологик тәртиптә (гариза бирү датасы һәм вакыты буенча) теркәлә.

5 статья. **Фондның җир кишәрлекләрендә төзелгән яисә төзелеп килүче эконом класслы торак сатып алу хокукына ия гражданнар гаризаларын карау тәртибе**

1. Җирле үзидарәнең вәкаләтле органы тарафыннан гаризалар һәм аларга кушып бирелгән документлар каралганда, гражданнарны исемлектә күрсәтелгән затлар категорияләренә кертү өчен нигезләр, шулай ук исемлеккә гражданнарны кертү өчен исемлектә каралган нигезләр тикшерелә.

2. Гаризаны һәм аңа кушып бирелгән документларны карау нәтиҗәләре буенча җирле үзидарәнең вәкаләтле органы гаризаны кабул итеп алган көннән соң 10 эш көне эчендә гражданны исемлеккә кертү өчен аның гаризасын исәпкә алу турында йә мондый исәпкә алудан баш тарту турында карар кабул итә.

3. Җирле үзидарәнең вәкаләтле органы мөрәҗәгать итүчегә гаризаны исәпкә алудан түбәндәге нигезләр буенча баш тарта:

1) граждан исемлектә күрсәтелгән гражданнарның бер категориясенә дә туры килмәсә;

2) гражданны исемлекләргә кертү өчен исемлектә каралган нигезләр булмаса;

3) мөрәҗәгать итүче бирергә тиешле документлар бирелмәсә яисә тулы күләмдә бирелмәсә;

4) дәүләт хакимияте органының, җирле үзидарә органының йә дәүләт хакимияте органы яисә җирле үзидарә органы буйсынуындагы оешманың ведомствоара гарызнамәгә җавабы сорап алына торган документның һәм (яисә) мәгълүматның юклыгын дәлилләсә, әгәр тиешле документны мөрәҗәгать итүче үз теләге белән бирмәсә, моңа сорап алына торган әлеге документның яисә мәгълүматның шундый органнар яисә оешмалар карамагында булмавы тиешле гражданнарның исемлеккә кертү хокукын раслаган очраклар керми;

5) граждан һәм (яисә) аның гаилә әгъзалары турында йә исемлекләргә кертү нигезләре турында дөрес булмаган белешмәләр тапшырылса.

4. Әлеге статьяның 2 өлешендә каралган карар кабул ителгән көннән алып өч эш көне эчендә җирле үзидарәнең вәкаләтле органы гражданга кабул ителгән карар турында һәм, гражданның гаризасын исәпкә алу турында карар кабул ителгән очракта, мәгълүмати

хәбәрнамәдә күрсәтелгән срокта шартнамә төзүгә гражданның ризалыгын бирү зарурлыгы турында язма хәбәрнамә җибәрә.

5. Гражданның ризалыгы шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә күпфатирлы йортларның, торак йортларның (шул исәптән индивидуаль торак төзелеше объектларының) (алга таба – торак йортлар) проект документациясе расланганнан да иртәрәк булмаган вакытта, граждан шартнамә төзеячәк торак урынны бердәйләштерү мөмкинлеге бирә торган индивидуаль билгеләнгән характеристикаларны күрсәтеп, рәсмиләштерелә.

6. Исемлеккә кертү өчен граждан гаризасын исәпкә алудан баш тартуга карата мөрәҗәгать итүче тарафыннан Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә шикаять белдерелергә мөмкин.

7. Граждан, баш тарту өчен нигезләр бетерелгәннән соң, җирле үзидарәнең вәкаләтле органына гариза белән кабат мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

8. Гражданнарның исәпкә алынган гаризалары турындагы язмалар исемлектә теркәү кенәгәсе нигезендә хронологик тәртиптә урнаштырыла.

6 статья. **Аукцион нәтиҗәләре турындагы беркетмәдә билгеләнгән шартларда эконом класслы торак сатып алуга ризалык биргән гражданнар исемлекләрен төзү һәм исемлекләргә үзгәрешләр кертү кагыйдәләре**

1. Аукцион нәтиҗәләре турындагы беркетмәдә билгеләнгән шартларда эконом класслы торак сатып алуга ризалык биргән гражданнарның исемлеген төзү максатларында җирле үзидарәнең вәкаләтле органы эконом класслы торак төзелеше өчен Фондның җир кишәрлекләрен түләүсез вакытлыча файдалану яисә аренда шартнамәсе төзегән датадан биш эш көне дәвамында, мондый шартнамәнең нәтиҗәләре турындагы беркетмәдәге белешмәләрне, шулай ук шартнамә төзүгә гражданның ризалыгын җибәрү срогын күрсәтеп, аукцион нәтиҗәләре турында мәгълүмати хәбәрне рәсми массакүләм мәгълүмат чараларында бастырып чыгара һәм «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә муниципаль берәмлекнең рәсми сайтында урнаштыра.

2. Исемлекне төзү һәм раслау максатларында Фондның эконом класслы торак төзү өчен түләүсез вакытлыча файдалану яисә аренда шартнамәсе буенча тапшырылган җир кишәрлеге урнашкан территориядәге муниципаль берәмлек җирле үзидарәсенең

вәкаләтле органы муниципаль берәмлекләрдән шартнамә төзүгә гражданнарның ризалыгы белән бергә гражданнарның исәпкә алынган гаризаларының әлеге Законның 5 статьясы нигезендә төзелгән исемлеген соратып ала.

3. Аукцион нәтиҗәләре турындагы беркетмәдә билгеләнгән шартларда эконом класслы торак сатып алуга ризалык биргән гражданнар исемлеге Фондның эконом класслы торак төзү өчен түләүсез вакытлыча файдалану яисә аренда шартнамәсе буенча тапшырылган җир кишәрлеге урнашкан территориядәге муниципаль берәмлек җирле үзидарәсенең вәкаләтле органы тарафыннан, гражданнарның гаризаларын теркәүнең хронологик тәртибе сакланган килеш, бирелгән исемлекләр нигезендә муниципаль берәмлекләрдә гаризалары исәпкә алынган гражданнар арасыннан төзелә. Берничә муниципаль берәмлектә гаризалары исәпкә алынган граждан исемлеккә теркәлү датасы элегрәк булган гаризасы буенча кертелә.

4. Аукцион нәтиҗәләре турындагы беркетмәдә билгеләнгән шартларда эконом класслы торак сатып алуга ризалык биргән гражданнарның гомуми саны шәһәр төзелеше эшчәнлеге турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә расланган торак йортлар проект документациясе нигезендә Фондның җир кишәрлегендә төзелергә тиеш эконом класслы торакта торак урыннарының гомуми санынннан артып китсә, җирле үзидарәнең вәкаләтле органы гражданнарны исемлеккә хронологик тәртиптә гариза бирү тәртибе буенча түбәндәге чират белән кертә:

1) беренче чиратта исемлеккә яшәү өчен яраксыз дип билгеләнгән тәртиптә танылган торак урында йә билгеләнгән тәртиптә авария хәлендә һәм сүтелергә яисә реконструкцияләнергә тиеш дип танылган күпфатирлы йорттагы торак урында яшәүче гражданнар, били торган торак урынның зурлыгына карамастан, кертеләләр;

2) икенче чиратта исемлеккә социаль наем шартнамәләре буенча бирелә торган торак урыннарга мохтаҗ буларак исәптә торучы гражданнар кертелә;

3) өченче чиратта исемлеккә өч һәм аннан күбрәк балалы гаиләдә ата-ана булып торучы гражданнар кертелә.

5. Бер кешегә исәпләгәндә кереме алты яшәү минимумыннан артмаган һәм әлеге статьяның 4 өлешендәге 1 – 3 пунктларында каралган чиратлылык нигезендә категорияләргә кертелгән гражданнар исемлеккә беренче чиратта кертелү хокукына ия.

6. Фондның эконом класслы торак төзү өчен түләүсез вакытлыча файдалану яисә аренда шартнамәсе буенча тапшырылган

җир кишәрлеге урнашкан территориядәге муниципаль берәмлек башлыгы исемлекне раслый һәм күрсәтелгән исемлекне Фондның җир кишәрлегендә аукционда җиңүче тарафыннан төзелергә тиешле торак йортлар төзелешенә рөхсәт бирү көненнән дә соңга калмыйча аукционда җиңүчегә җибәрә.

7. Муниципаль берәмлек башлыгы раслаган исемлек Федераль законның $16^6$ статьясындагы 22 өлеше нигезендә бастырып чыгарылырга тиеш.

8. Муниципаль берәмлек башлыгы тарафыннан ул раслаган исемлеккә гражданнарның шәхси составы һәм (яисә) торак урыннарының саны һәм (яисә) бүлмәләрнең саны турында күрсәтелгән капиталь төзелеш объектларының расланган проект документациясе белән билгеләнгән торак йортларның гомуми мәйданы күләме чикләрендә түбәндәге очракларда үзгәрешләр кертелергә мөмкин:

1) үзен исемлектән төшереп калдыру турында гражданнан гариза алыну;

2) исемлеккә кертелгән гражданның вафат булуы яисә аны суд тарафыннан үлгән дип игълан итү;

3) әлеге өлешнең 1 яисә 2 пункты нигезендә мондый исемлектән төшереп калдырылган гражданны теркәү кенәгәсендә исәпкә алынган гаризасы булган башка граждан белән алмаштыру.

9. Исемлеккә үзгәрешләр Федераль законның $16^6$ статьясындагы 32 өлешенең 2 пунктында каралган мәгълүматны «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә Фондның рәсми сайтында урнаштырган көннән алып 12 ай чыкканчыга кадәр әлеге статьяда каралган тәртиптә кертелә.

10. Исемлектәге үзгәрешләр Федераль законның $16^6$ статьясындагы 25 өлеше нигезендә бастырып чыгарылырга тиеш.

7 статья. **Йомгаклау нигезләмәләре**

1. Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

2. Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты әлеге Законны гамәлгә ашыруны тәэмин итә торган норматив хокукый актларны әлеге Законның үз көченә кергән көненнән алып өч ай дәвамында кабул итәргә тиеш.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 елның 28 декабре
№ 95-ТРЗ

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗАКОНЫ

**1888. «Җир асты байлыклары турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында**

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2012 елның 24 декабрендә
кабул ителде

**1 статья**

«Җир асты байлыклары турында» 1992 елның 25 декабрендәге 1722-XII номерлы Татарстан Республикасы Законына (1999 елның 6 декабрендәге 2486 номерлы Татарстан Республикасы Законы редакциясендә) (Татарстан Югары Советы Җыелма басмасы, 1992, № 11 – 12; Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2000, № 2 (2); 2001, № 12; 2004, № 7 (I өлеш); 2005, № 4 (I өлеш); 2008, № 3; 2009, № 9 – 10; 2012, № 1; Ватаным Татарстан, 2012, 24 июль) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) $35^2$ статьяның беренче өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Әлеге Законның $35^1$ статьясындагы беренче өлешендә күрсәтелгән максатларда җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукын алуга аукционда катнашу өчен шул аукционда катнашуга дәгъва кылучы (әлеге статьяда алга таба – мөрәҗәгать итүче) җир асты байлыкларының дәүләт фонды идарәсе органына Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты тарафыннан расланган рәвеш буенча гариза бирә, шулай ук түбәндәге документларны тапшыра:

мөрәҗәгать итүченең гамәлгә кую документлары күчермәләрен (әгәр мөрәҗәгать итүче юридик зат булса);

Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан (Индивидуаль эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан) өземтәне;

салым түләүченең идентификация номерын күрсәтеп, мөрәҗәгать итүчене салым органында исәпкә кую турында таныклыкның күчермәсен;

салымнар һәм җыемнар түләү буенча бурычы булу яисә булмау турында салым органнарыннан белешмәне;

мөрәҗәгать итүченең һәм җәлеп ителүче подрядчикларның җир асты байлыклары кишәрлекләреннән файдалануга бәйле эшчәнлек төрләренә лицензияләре (алар булса) күчермәләрен;

соңгы хисап датасына мөрәҗәгать итүченең бухгалтерлык балансы күчермәсен, аңа кабул ителүе хакында салым органы билгесе куелган булырга тиеш;

мөрәҗәгать итүченең аукционда катнашуга гариза бирелгән датага кадәрге ай эчендә счетлары буенча акчалар йөреше турында банк учреждениеләреннән белешмәләрне;

заем яисә кредит шартнамәләренең (алар булса) күчермәләрен;

подряд шартнамәләренең (алар булса) күчермәләрен;

кулланыла торган технологияләр турында, аларның тасвирламалары белән, белешмәне һәм бораулау, тау эшләрен башкару өчен кирәкле техник чараларның, аларның мөрәҗәгать итүчегә йә җәлеп ителүче подрядчикка каравын раслый торган документлар белән, исемлеген;

мөрәҗәгать итүченең йә җәлеп ителүче подрядчикларның штат расписаниесе күчермәсен;

эшләр башкарачак квалификацияле белгечләрнең дипломнары күчермәләрен.»;

2) $35^3$ статьяның бишенче өлешендә «лицензия бирүдән» сүзләрен «җирле әһәмияттәге җир асты байлыклары кишәрлегеннән файдалану хокукы бирүдән» сүзләренә алмаштырырга;

3) 92 статьяның икенче өлешен түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Файдалы казылмалар яткан мәйданнарда төзелеш алып бару, шулай ук алар яткан урыннарда җир асты корылмалары урнаштыру җир асты байлыкларының дәүләт фонды идарәсенең федераль органы яисә аның территориаль органы рөхсәте нигезендә федераль законнар белән рөхсәт ителә. Мондый рөхсәтне бирү дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге аша башкарылырга мөмкин.».

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән соң 10 көн узгач үз көченә керә.

**Татарстан Республикасы Президенты Р.Н. Миңнеханов**

Казан, Кремль
2012 елның 28 декабре
№ 96-ТРЗ